**Алмаз Хәмзин**

# ОЗАК ЯШИСЕГЕЗ КИЛСӘ...

Юмор һәм сатира

*Казан*
*Татарстан китап нәшрияты*
*2007*

УДК 821.512.145-7
ББК 84 (2Рос=Тат)-7
Х88

**Хәмзин А.Н.**

Озак яшисегез килсә...: юмор һәм сатира / Алмаз Хәмзин. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. — 175 б. — 2000 д. — ISBN 978-5-298-01572-1

Бу китапка танылган сүз остасы Алмаз Хәмзиннең дистә еллар буе сәхнәләрдә яңгыраган һәм укучыларга таныш булмаган юмористик һәм сатирик әсәрләре тупланды.

ISBN 978-5-298-01572-1
© Татарстан китап нәшрияты, 2007
© Хәмзин А.Н., 2007

## Бер килсә килә бит ул

Турысын язсаң — бастырмыйлар, кыегын язсаң — атканың үзәгенә туры килә, «сыер кебек өстенә баскансың» диләр. Үземнең дә авырткан бармак гел бәрелеп тора. Чуанны да сытып китәләр. Менә бүгеннән гел әйбәтне язам.

Путин яхшы Президент булып чыкты. Бер дә тик тормый. Рәхмәт.

Кичә ипинең бәясе тагын күтәрелде. Ул шулай булырга тиеш икән, телевизор белән радиодан шулай дип әйттеләр. Әйтәм җирле, өченче көн картларның пенсиясен ун сумга арттырдылар. Пенсионерлар тагын: «Аллага тапшырдык», — диделәр. Ярый әле Аллаһы Тәгалә бар тапшырырга. Аңа да рәхмәт.

Узган ел кырларда уңыш тагын мул булды. Түкми-чәчми җыеп алдык. Кырып-себереп дәүләткә тапшырдык. Молодец та инде үзебез. Мактадылар. Әле хәзер дә мактап торалар, чөнки яңадан чәчү җитә, чәчәчәкбез, чөнки үткән ел җыйган уңыш акчасын һаман алмаган. Хи-хи, дәүләтне безгә бирәсе бурычка батырып бетердек. Әле Чубайсның ваучерларга кеше саен икешәр «Волга» машинасы бирәсе бар. Хөкүмәтнең туксан икенче елны яндырган әҗәте запаста. Әй, нәрсәгә соң безгә акча, инде ансыз да яшәргә өйрәндек. Болай әйбәт яшәсәк, тагын әллә нәрсәләргә өйрәнербез әле.

Хәзер армиягә бармыйча качып йөрүчеләр бетеп бара. Яшьләр: «Монда ачтан үлгәнче, лутчы армиягә китәм, бәлки, исән калырмын», — диләр. Әйбәт бит инде, ашарларына биргәч.

Вузларга керү дә җайланды. Элек шыр надан булсаң, шиш керәдер идең укырга, ә хәзер акчаң булса, диплом — кесәңдә. Безнең заманда бу бәхет төшкә дә керми иде. Хөррият!

Әле ул гынамы, хәзер теге «өч тиенлек» трамвайларга утырып йөрмибез инде, алар хәзер сигез тәңкә! Юк ул хәзер уналты тиенлек очсыз ипиләр, унбер сумлыгын ашыйбыз! Аракысы нинди бит әле, аракысы!.. Кемгә рәхмәт әйтергә белмичә, үлеп беткәнче яратып эчәбез.

Ул колбасалар! Мең төрле. Мөселманча әзерләнгән дуңгыз колбасаларына хәтле бар.

Ул наркоманнар! Без аларның элек кем икәннәрен дә белми идек. Менә күрү бәхетенә дә ирештек.

Ул фахишәләр! Элек ишеткән булсак та, күргән булмады.

Ул ришвәтчелек! Сүзе генә ни тора! Башка заманда туган булсаң, ишетер идеңме мондый матур сүзләрне?!

Ул җинаятьчелек! Хәзерге җәмгыятьтә яшәмәсәк, без аны белер идекме? Димәк, без бәхетлеләр!

Коммунизмда яшәдек, күрдек. Капитализмда яшибез, белдек.

Зарланырлык түгел тормышка. Өстеңдәге элеккеге алтмыш тәңкәлек кәчтүмне дүрт меңлек дип әйтүе үзе ни тора! Аллага шөкер, бар әле ул кәчтүмнәр шкафларда. Яшәсен иске кәчтүмнәр яңа шартларда!

Һәркемнең аяк табаны астыннан газ чыга, нефть ага. Ага да ага, кая ага?.. Җиребез май урынына ипи өстенә ягып ашарлык. Урманнарыбыз куе. Кырыйдан миңа шулай күренә. Суларыбыз чиста, һавабыз саф кебек шикелле сыман бугай. Халкыбыз сабыр, халык шәп! Депутатлар яхшы! Ил зур! Җә, тагын ни кирәк?! Бәхет дигәнең бер килсә килә бит ул! Хәйран матур мәкалә килеп чыкты бит әле, әй. Берәүне дә сүкмәдем, мактадым гына. Бәйләнмәгез миңа!

## Юлларга кемнәр чыгар...

ГАИ турында җыр язу шатлыгыннан хисләнеп, үз машинамда Казаннан авылга кайтып барам. Юлым Чистай аркылы. Кама елгасыннан күпер салынгач, Чаллы аша йөрүләрем бетте хәзер. Дөрес, көн бераз ямьсезрәк, ләкин күңел күтәренке. Әлеге җырга текстны Фирзәр сораган иде. «Алмаз абый, ГАИларга бер матур җыр кирәк, әйдә, бергәләп шуны башкарып чыгыйк әле!» — дигәч, ризалык бирдем. Менә укып карагыз әле:

Күзләр — юлда, йөрәк, тыңла:
Хәвеф-хәтәр була күрмәсен!
Юлчы дустым, оныта күрмә
Өйдәгеләр сине көтәсен!

Дуслар юлларда сынала —
Дусны юлда табыгыз!
Юл дуслары — ГАИларга
Сәлам биреп калыгыз!

Үземчә көйләп тә караган булам. Шәп җыр чыгарга тиеш.

Мин юлда бик ашыгып чапмыйм. Җайлап кына, нindidер көйләр көйләп, сызгыргалап, табигатькә хозурланып барам. Мыштырдап баруым, бәлки, кайбер калай этәчләрнең эчен дә пошырадыр. Юл кагыйдәләрен үтәп, кисәтү-күрсәтү билгеләренә игътибар итеп картларча йөрим. Теге, сайлап кына алынган номерлы джиплар, иномаркалар выжылдап кына үтеп китәләр. Безнең шикелләләр алар янынннан тараканнар кебек юл читенә сибеләләр. Аллам сакласын, бәреп китүләре бар. Юлдагы инспекторлар да андыйларга честь биреп кенә калалар. Ә без — «шестерка»-лар, «девятка-десятка»лар — ГАИ машинасы кырыенда утарга япкан маллар кебек өелешеп торабыз. Безне иснәп карыйлар, тентиләр.

Бу юлы тагын да саграк кайтам. Егерме ел стажы бар шофер абзагызның, шиш тоттырыр! Яуширмә борылышына җитәрәк, пычрак сибеп баручы «КамАЗ» артыннан манчылып кайту туйдыргач, каршыга килүче машиналарның «күз кысуына» игътибар итсәм дә, юл кырыенда бернинди кисәтү билгеләре күрмәгәч, узарга булдым. Нигә узмаска!.. Кайда узарга ярамый дип язган? Юлны урталай бүлгән сызыгы да юк, алдагы юл күз күреме кадәр километрлап ачык. Кайчан кайтып җитәм мин авылга бу кырык километр тизлек белән? «КамАЗ»ны узуым булды, берәү ГАИ машинасыннан атылып килеп тә чыкты. Туктарга куша. Бөтен кагыйдәләрен туры китереп туктадым мин болар янына. Билгеле, праваны сорый. Машиналарына кереп утырырга куша. Кердем. Утырам эндәшмичә. Әй әйләндерә праваны, әй әйләндерә капитан дигәне. Ни өчен туктатканнарын әйтми. Бер өч минутлап әйләндергәннән соң, мин түзмәдем: «Народный артист Хамзин!» — мәйтәм. Беләм инде «народный» ни, «заслуженный» ни бу урыс малайларына. Үзем бит әле «заслуженный» да түгел. Болай гына әйтәм инде, халык болай да «народный» дип йөрткәнгә, җибәрмәсләр микән дигән уй белән. Башкаларның шундый исемнәр белән кизәнеп йөргәннәре истә. Юк, җибәрми, әлеге дә баягы капитан дигәне һаман әйләндерә праваны. «Ну и что народный артист! — ди бу миңа, кашын җыерып. — Да фига вас таких!» Шуннан психланып праваны мине туктаткан прапорщикка ыргытты. «Сам поймал, сам пиши!» — ди. Хәзер монысы әйләндерә праваны. Әй әйләндерә, әй әйләндерә... Үземә гөнаһ аласым килми — әллә акча көтәләр инде?.. Юк, мәйтәм, болайга киткәч өмет итмәгез, егетләр, сезгә шиш тоттырам мин акча, лутчы хөкүмәткә түләрмен! Прапорщик аптыраушта калды, әле һаман беркетмәсен тутырмый, һөҗүмемне көчәйтеп: «Рифкать Нургалиевич Миңнехановны беләсезме?» — дим, үземнең шундый зур кеше белән таныш булуыма ишарәләп. «Знать не знаем!» — диләр болар. Әй, мәйтәм, болар үзләренең патшаларын да белмиләр икән.

Ниһаять, прапорщик беркетмәсен язып бетерде. Миннән кул куюны сорый. Укыйм: «Выехал на встречную полосу» диелгән. Мин шауламадым. «Никаких правил не нарушил», — дип, отказ яздым да, болар белән тагын нәрсә сатулашасың инде, үз начальникларын да белмәгән кешеләр белән дип, праваны калдырып, вакытлычасын алып, яңадан юлга кузгалдым.

Менә Кама Аланына кереп киләм. Борылма да борылма. Туйдырды «поворот»ны яндыру. Җәяүле тизлеге белән күпер астына керәм. Иң өстенә сала торган куркынычсызлык каешын да ычкындырып аттым. Буылып йөрмим әле!

Шалт!.. Борылмадан ГАИ килеп чыкты. «Стой!» «Товарищ Хамзин, вы нарушили правила безопасности дорожного движения. Поворотники не включали, ремень безопасности не застегнут!» — ди. Бернәрсәгә бәйләнеп булмый. Алар күргәнчә барысы да дөрес. Штраф. Шул вакыт мин кыюланып сүземне турыдан ярдым: «Егетләр, — мәйтәм, русчалап, — коллегаларыгыз әле генә бер гаепсезгә беркетмә язып праваны алып калдылар, ә сез мине дөрес тоттыгыз. Мин гаепле. Штраф икән — штраф түлим, әгәр җибәрә алсагыз — җибәрегез!» Карап-карап тордылар да болар миңа, бер сүз дә әйтмичә, «вакытлы» правамны кире биреп, машиналарыннан чыгарып җибәрделәр. Рәхмәт, егетләр! «Бар икән болар арасында да җүнле кешеләр», — дип уйлап куйдым шул чакта. Югыйсә болары да урыс малайлары иде бит.

Менә шундыйрак могҗизалар белән авылга кайтып килгәнгә бер айлап вакыт үтте. «Ак Барс» банкына биш йөз сум түләп праваны барып алдым да кичен Фирзәр Мортазин концертына киттем. Ялгыш ишетәмме дип торам, Фирзәр теге җырны сәхнәдән җырлый:

Борчу белән үтә юлчы
Буранлы көн, кышкы челләдә.
Хәерле юл теләп кала
Юл сакчысы аңа төннәрдә.

Дуслар юлларда сынала —
Дусны юлда табыгыз!
Юл дуслары — ГАИларга
Сәлам биреп калыгыз!

Шәп килеп чыккан. Халык гөрләп кул чапты. Тәнәфескә чыккач, бу уңышлы җыр белән мине дә котладылар. Рифкать Нургалиевич Миңнеханов та килгән икән. Ул нык итеп кулымны кысты. «Әле бу җырга клип та төшерәчәкбез», — диде. Рәхмәт.

Шулай. Тормыш булгач төрлесе очрый. Әлеге дә баягы капитаннары да, прапорщиклары да... Андыйлары искә төшкәндә, минем юл уртасындагы тоташ сызыкны юри кисеп чыгасым килә, ә Кама Аланындагы ГАИ егетләре искә төшсә, ул ялгыш уемнан кире кайтам.

Халыкта бит «Юлларыңа ак җәймә» диләр. Чыннан да, юл ул ак һәм пакь булырга тиеш. Аңа пычрак ятмасын, шул исәптән...

## Минем кыйблам

Мин татар артисты! Шуның белән үземнең гражданлык позициямне аңлаттым кебек, ләкин...

Башкортстанда Президент сайлаулары башлана дигәч тә, күп кенә татар артистлары, үзләре дә сизмичә, Мәскәүнең сәяси болытларына ияреп, көнчыгышка агылдылар. Циклонның тәэсире зур иде: кесәләргә коеп-коеп акчалар явачак, тәти-тәти исемнәр, өермә-өермә бүләкләр, текә-текә машиналар, лабиринт-лабиринт фатирлар бирeләчәк. Берәүләре — Сафинны, икенчеләре Рәхимовны яклаячак. Берсе — Президент, икенчесе — магнат. Ә артистка нәрсә аңа? Түләсеннәр генә.

Циклон булгач, антициклоны да килә инде аның. Башкортстандагы милләттәшләребезнең безгә таба искән җилләр белән юллаган тугандашлык тойгылары безне һәрвакыт җылытып торды. Без алар белән горурланып яшәдек. Ә үзләре Татарстаннан изгелекләр көтеп гомер кичерделәр. Бу сайлаулар аларның хыялларына канат куйды дигәндә, менә сиңа мә... Уйламаганда-көтмәгәндә, сөекле артистларыбызның кайберләре, циклонга ияреп, Башкортстанга юнәлделәр.

Концертына фәлән хәтле акча тәкъдим итеп, миңа да чыктылар. «Җүләр син!» дисәләр диярләр, бармадым. Гражданлык позициям кадерлерәк бит. Ничек инде мин тоташ башкортлаштыру сәясәте алып барыла торган республикада шул сәясәтнең башында торучы юлбашчыны мактап йөрим ди?

Ә бит киттеләр. Монда, Татарстанда, «газиз халкым» дип концерт куеп йөреп, «халык артисты», «атказанган» исемнәрен алган артистларыбыз бу эшкә алынды. Кайберләрен сез аларның, хөрмәтле укучым, үзегез дә беләсез. Телевизор карасагыз, Татар конгрессында — алтынчы рәттә, Башкорт корылтаенда дүртенче рәттә утыралар алар. Һәрвакыт түрдә. Безнең иң югары дәрәҗәдәге җитәкчеләребез янында да ышкылып йөрүчеләр шулар. «Тәфтиләү»не җырлыйлар да Тукай премиясен таләп итәләр, Камал театрында өч-дүрт концерт куялар да «халык артисты» исемен сорыйлар.

«Халык» исеменә лаек булганнар гаять талантлылар, алар Ходай кешеләре диярсез. Әйе, мин дә аларның талантлары каршында баш иям, ләкин гражданлык позициясе юкларының миләрен төртеп тишәсе килә. Үз карашың, үз фикерең юк икән, сине кем хөрмәт итсен?!

Нишлисең, аттан ала да туа, кола да туа, диләр. Әле кайчан гына үзебезнең милләт горурлыгы булган берәү Тукай бүләген алалмаганнан соң «бүтән» дингә дә күчеп йөрде. «Кызыллар» килсә, кызыл түбәтәй, «аклар» килсә, ак түбәтәй киючеләр дә аз түгел бездә.

Әйе, татар артисты булып яшәү һәм иҗат итү аеруча кыен. Базар заманында артистлар үзләре дә товарга әйләнәләр. Артистларның «колхозы» таралды. Кем ничек булдыра, үзен шулай сата. Яшәргә кирәк. Туйларга чакырсалар — анда барабыз, юбилейларга йөреп көн күрәбез, тамак туйдырабыз. Артист байның ялчысына әверелә. Ә ялчыдан нәрсә көтәсең? Шуңа күрә аның сәнгате дә трамвай, троллейбус, автобусларга кереп җырлап йөри торган таҗик чегәннәре хәленә калып бара.

Ә Башкортстанда хәзер шәп түлиләр. Сайлауларга берни дә жәл түгел. Кайбер артистлар өчен җәннәттәй вакытлар.

Башкортларның бер җыры искә төшә:

Башкортлар китте
    сугышка,
Озатып калды
    киң Урал.
Ат уйнатып
    алда бара
Шәйморатов —
    генерал!

Изге эш. Безнең бабаларыбыз, әтиләребез уртак Ватаныбызны бергәләп сакладылар. Инде соңгы елларда татар-башкорт мөнәсәбәтләренә чөй кагып маташмаска, андагы татарларыбыз мичкәсенә дегет тамызмаска иде. Шуларны уйлыйм да, яңа куплет туа:

Артистлар китте
башкортка,
Озатып калды
киң Идел.
Алар баеп
кайтачаклар,
Ләкин мин генә түгел.

Әйе, бармадым. Акча да юк, дәрәҗә дә... Ярый әле көчле позициям бар, ха-ха-ха! Рөхсәт итәм, көлегез миннән!

## «Язмагыз әле!»

Хөрмәтле «Татар яшьләре» газетасы хезмәткәрләре!

Бәлки, ишетеп беләсездер, артист Алмаз Хәмзин булам мин. Сезгә берничә үтенечем бар иде.

Әле күптән түгел генә үзегезнең бер саныгызда сез, җырчы Резеда Төхвәтуллина Гарәп Әмирлекләренә ял итәргә китте, дип язгансыз. Язмагыз әле шулай, пожалысты! Хатын котыра. Кешеләр ял итәләр, ә син мине ындыр артына да алып чыкканың юк, ди. Ник, мәйтәм, Биектауда хатыны белән бер маньяк йөри дип язып чыктылар бит «Татарстан яшьләре»ндә. Кыяфәте Алмаз Хәмзингә охшаган, дип.

Габделфәт Сафин үзе турында китап бастырып чыгарды, дип язгансыз. Тоже әйбәт булган. Хатын: «Йөрисең инде, хәсрәт капчыгы, илле икегә җитеп бер китап чыгара алмыйча. Кызыңның дәфтәрләрен куярга урын юк шкафта, чыгарып атам кәгазьләреңне», — ди.

Зөфәр Хәйретдинов хатынына да иномарка алып биргән, дип язгансыз. Шулай язалармы инде, кеше котыртып? Зөфәр куян куа дип, мин дә... Булмый бит инде алай итеп.

Газетагызда анекдотлар язмагыз әле. Шамкай, шуларны сөйләп, фатир сатып алды. Минем хатын котыра. Ә Шамкайныкы Шамкайның фатир алганын белми. Рәхәтләнә Шамкай яшәп тегендә.

Равил Шәрәфинең «Делаю депутатом любого, цена договорная. Автомобиль «Оку» не предлагать» дигән белдерүен бастырмаска иде. Хатыннан авыру ясыйсыз бит инде.

Кайвакытта Ирек мәйданында ачлык игълан итүчеләр турында язасыз. Язмагыз әле шуларны, пожалысты! Хатын: «Бар, син дә шунда чык, алар бер дә юкка утырмыйлар, бераз өйдәге бәрәңгегә дә экономия булыр», — ди.

Бәрәңге дигәннән, үткән көз: «Президент районнарда бәрәңге басуларында йөреп кайтты», — дип яздыгыз. Язмагыз әле шулай! Үтерде бит хатын: «Шунда менә аның вертолетына бер-ике капчык бәрәңге салып җибәрәләр инде бушка», — диеп.

Аннан соң бервакыт сез Клинтон белән Левинская турында күп яздыгыз. Шуннан соң йөдәтте бит хатын Мөхәммәтшин кем белән йөри икән диеп. Язмагыз әле, пожалысты, ул турыда! Хәзер үземнән дә гел шикләнә. Күлмәк-ыштаннан таплар эзли. Левыйда булгансың, ди. Юк, мәйтәм, булмадым Левинская белән. Точнымы, ди. Мин әйтәм, точно Левинская түгел иде.

Аннан соң бер саныгызда, пеләш ирләр азартный була, дип язгансыз. Үтерде инде хатын миннән азарт эзләп. Тегеләй итеп карый, болай — юк азарт. Язмагыз әле, пожалысты, андый юк-барны!

Хәния Фәрхинең «Бәхеткә түзеп кара» дигән җырын газетагызда бастырмаска иде. Хатын: «Әнә кайбер кешеләр бәхеткә чыдый алмый башлаганнар, ә син!..» — ди.

Ә мин нәрсә? Мин бәхеткә чыдыйм анысы, михнәткә чыдау гына авыррак. Ә инде минем белән бергә барысына да түзеп яшәгән өч балалы хатыныма ничектер — аңа Ходай үзе сабырлык бирсен!

Хөрмәтле редакция! Язмагыз әле, пожалысты... Хәер, языгыз, яз! Ни уйласагыз, шуны языгыз! Сездә — тормыш, сездә — без үзебез!

## Нинди прогрессия буенча яшибез

Прогресс латинча алга таба хәрәкәт дигәнне аңлата. Арифметик һәм геометрик прогрессияләр бар. Әйтик, саннар белән аңлатканда, арифметик прогрессия — бер, ике, өч, дүрт, биш, геометрик прогрессия — биш, ун, егерме, кырык.

Без нинди прогрессия буенча яшибез икән, шуны исәпләп карыйк әле. Коммунистлар чорында «начар яшәгән» вакытларны күзаллыйк. Хезмәт хакы — йөз тәңкә. Ипи уртача унбиш тиен тора иде, димәк, йөз тәңкәгә уртача алты йөз алтмыш алты «кирпеч» ипи сатып алырга мөмкин иде. Хәзергесен исәпләп карыйк, өч мең тәңкәгә якынча өч

йөз утыз өч ипи тия икән. Аннан соң, теге вакыттагы мең граммлы ипи хәзер җиде йөз сиксән генә грамм, үзем үлчәп карадым.

Фатир мәсьәләсенә туктыйк. Әллә тукталып тормыйкмы? Чөнки ул элек, йөз сум алып эшләгәндә, хезмәт хакының дүрттән берен тәшкил иткән, ә хәзер яртысын йота. Әле моңа газга түләү керми.

Транспорт мәсьәләсенә дә тукталып китик инде. Теге вакытта трамвайга — өч тиен, автобуска-троллейбуска биш тиен түлисе иде. Димәк, теге хезмәт хакына өч мең өч йөз утыз өч тапкыр трамвайга, ике мең тапкыр автобуска утырып йөрергә мөмкин булган. Ә хәзер ничек? Ә хәзерге хезмәт хакы алты йөз тапкыр теге хәерче автобуска, өч йөз мәртәбә «Газель»гә утырып йөрергә җитә.

Тагын нәрсәне исәпләп күрсәтим? Концертлар карыйсыгыз, театрларга барасыгыз киләме? Ничә тапкыр? Әйдә, елына ике мәртәбә барабыз! Берсе — Салаваткa, икенчесе — Хәниягә. Юк, дисезме? Ник? Салаватка барсак, Хәниягә акча җитми, дисезме? Юк инде, җәмәгать, сез кеше аермагыз! Парлашып барыгыз! Икегезгә алты йөз генә сум бит ул.

Ә-ә! Концертка йөрү өчен хатыныгызга яңа күлмәк, үзегезгә кәчтүм дә кирәкмени? Аңлашыла. Хәлегезгә керәм. Хезмәт хакы һаман шул өч мең тәңкә генә дисезмени? Ә-ә! Укый торган ике балагыз да бармыни? Ник, хатыныгыз эшләмимени? Мең ике йөз тәңкәгә, дисезме? Әйтәм аны, хезмәт хакы йөз тәңкә булган елларда ук алган пәлтәсен киеп йөри. Яңаны алган идек, дисезме? Ә-ә! Кич белән эштән кайтканда салдырдылармыни? Нигә соңга калып кайта соң ул эштән? Иртәрәк кайтсын! Яисә бөтенләй бармасын. Эшкә йөрмәүнең файдасы күбрәк бит хәзер. Җитмәсә, икешәр транспорт белән йөри, дисең. Аңа барырга-кайтырга да бит утыз-кырык тәңкә акча кирәк. Ашый торгандыр бит, бир әбәтенә кырык тәңкә, кеше арасында ач йөрмәсен. Менә исәплә: егерме ике эш көненә шушылар өчен мең биш йөз кырык тәңкә. Әле эшләп тә хатының сиңа өч йөз кырык сум бурычка бата. Бу бит синең теге өч мең тәңкәңә дә керү дигән сүз.

Менә бу, җәмәгать, безнең яшәү шартларының артка геометрик прогрессиясе. Бу, бер сүз белән әйткәндә, хәерчелек дип атала.

Прогрессив прогрессия бармы? Бар. Ул чиновникларга ришвәтчелек белән шөгыльләнмәсеннәр өчен хезмәт хакын тагын да арттыру. Егетләр, бу күп урлаган өчен бүләкләү кебек булып чыга түгелме соң?

Әллә мин аңламаган тагын берәр төрле прогрессия бармы?

## Сәгыйрьләр сагындыра

Тормыш мизгелләре гыйбрәт булып гел кабатланып торалар. Без кечкенә чагында, җәй җиттеме — авылга шахтадан Сәгыйрь абый кайта иде. Ап-ак кәчтүмнән. Һай, малай, кем күргән мондый хәлне? Ул аның ап-ак «Волга»да, урам тузаннарын туздырып, авыл уртасындагы кибет төбенә туктауларын күрсәң!.. Әй аның масаебрак, җәлт кенә машинадан чыгулары! Әле бик вакланмыйча гына шоферга егерме бишлекне төртеп, ыздачасын алмаган булып кылануын күрсәң! Исең китәр! Ул да булмый, барлык ирләрне җыеп, кибеткә алып керә дә «сыйлап» чыга. Китә сөйләшү: дөнья, шахта хәлләре. Тагын йөзәр грамм. Әле үзе эчми дә икән тагы.

Менә ул урам буйлап үзләренә төшә. Капка саен хатын-кыз:

— Исәнме, Сәгыйрь! Әйбәт кенә кайттыңмы?

— Исән әле, Кәримә апа. Үзең ни хәлләрдә?

— О-о! Мәликәтти! Саулармы, безгә төшеп утыр. Сөйләшербез.

— О-о! Кемне күрәм, карале, Сәкинәтти, синме бу?

Без кырыклап урам малае аның артыннан ияребез. Алар түбән очта торалар. Ул ак кәчтүмнең җилфердәүләре! Минем гомеремдә дә аннан ак әйбер күргәнем булмады кебек. Менә ул кулындагы зур чемоданын ачып, безгә конфет чәчә. Без җиргә сибеләбез.

Юмарт та, булдыклы да кеше иде инде Сәгыйрь абый. Ай буе печән чаба, утын әзерли, кешеләргә булыша, һәр кич авыл ирләренә бәйрәм ясый иде. Инде үзе дә тора-бара «тамак чылатып» йөргәнгә күрә, акчасы бетеп, яңадан китәр вакыты җиткәч, ак кәчтүмен сатып, җитмәгәненә бөтен авыл халкы юлына акча җыеп озаталар иде.

Авыл элеккечә тыныч хәленә кайтып тормыш итә башлый. Менә тагын бер ел үтеп, җәй җитә. Олы юлдан тузан туздырып, Сәгыйрь кайтып керә. Тагын ап-ак кәчтүмнән. Ул аның атлаулары, ул кыяфәт, шул ук ыздачалар алмау, сыйлаулар, кунак итүләр... Тач шул Сәгыйрь, грамм да үзгәрмәгән. Тагын шул башта эчмәгән булып маташулар. Үтә көннәр, отпускылар... Акчалар бетә, кәчтүм дә сатыла, өй борынча акча җыялар. Сәгыйрьне озаталар. Китә абзый. Авыл тынычлана.

Тагын җәй җитә. Олы юлның тузанын туздырып, яңгырлы көнне пычрагын чәчрәтеп, ак «Волга»да тагын Сәгыйрь кайта. Тагын ап-ак кәчтүмнән. Төягән күчтәнәчен. Өй саен кереп, бүләкләрен өләшеп Сәгыйрь йөри, апа-әбиләр белән күрешеп. Инде һәр өйдә китәренә акча җыелган, кайтсын гына, исән генә булсын, бигрәкләр әйбәт кеше шул безнең Сәгыйрь. Тагын «сыйлады», тагын бәйрәмнәр ясады. Үткән ел кәчтүмен үзе белән биреп җибәрделәр, бәлки, быел шул кәчтүме белән кайтыр...

Менә көтәбез... Шул киткәннән кайтмады Сәгыйрь абый. Авыл ямансулады, без сагынабыз. Минем күңелгә ул ничек тә бер кайтып керер төсле. Әле дә олы юлга күзем төшкәч, тузан күтәрелгәнен күрсәм, өметләнеп куям...

Хәзергеләр машиналарында чажылдап кына үтеп китәләр. Кая ул туктап исәнләшү?! Өйләренә чабалар. Җәяүлеләр ындыр артыннан йөриләр. Күпләре төнлә кайта. Ак кәчтүмнәрне түгел, саф хисләрне дә күрмим. Сәгыйрьләр юк хәзер авылларда, Сәгыйрьләр сагындыра...

## Кепка бәласе

Һөнәрең артист булгач нишлисең инде? Концертлар куясың. Өйдә утырсаң, берәү дә тиктомалга акча китереп тоттырмый. «Бүрене аяклары туйдыра» диләр. Без дә шулай: чыгабыз да китәбез, шулай гомер итәбез. Күпме авылларда булдык, күпме шәһәрләрдә!.. Кемнәр белән генә очрашмыйсың, танышмыйсың икән ул! Соңрак, инде таныла башлагач дип әйтимме, күрешүләр, үбешүләр дә ешайды. Ярый әле мактаулы исемнәрем юк, кочып-кысып үтерерләр иде. Шулай авылларга килеп төшәсең дә, хуҗалык рәисен күреп: «Ни хәлләр!» — дип ялкынланып хәл сорашасың. «Әйбәт! — ди бу. — Быелгысы елны гектарыннан кырык-илле центнер белән чыктык». Мин дә, шаярып: «Концертыннан уртача икешәр банкет белән чыгып киләбез!» — дим.

Арча халкы концертларны күп караган халык. Мәдәниятле. Аның җитәкчеләре дә гомер-гомергә сәнгатьне яратучан. Шуңа күрә Арча халкының йөзендә нур, күңелендә җыр бар. Хәзер дә шулай, барган гына юк. Күрәсе килә. Әллә инде элегрәк булган сагайткыч хәлләрдән соң чакыру ишетмим. Югыйсә бит эш кепкада гына иде...

Моннан ун еллар элек бер председатель дустым халыкка культуралы хезмәт күрсәтү йөзеннән үземне концерт куярга чакырды. Шәп итеп җырладык, банкеты да йөз кызарырлык түгел иде, авылны чыкканчы озата да барды. Җәй көзгә кереп баргангамы, салкынча, «на пасашок» дигәне дә җыелытмый, башта — кепкалар. «Әйдә алышабыз кепкаларны!» — ди пред берзаман. «Әйдә!» — мәйтәм. Минеке шәбрәк тә бит, нишлисең, саран диярләр җә. Алыштык. Куллар бирештек, таралыштык. Ярый, мактансын: «Алмаз Хәмзин кепкасы!» — дисен. Берничә көннәр үткәч ишетәм: машинасын урлаганнар. Ай начар булган!

Ярый, монысы шул. Икенче атнада концертка башка авылга чакыру бар. Шулай ук таныш председатель. Киттек. Көннәр салкынча, башта — теге пред биргән кепка. Килдек, яхшылап концерт күрсәттек. Банкеты да шәп булды. Озатышабыз. «Әйдә кепкаларны алышабыз!» — ди бу. Алмаз Хәмзин кепкасы белән кемнәргәдер мактанасы килә, күрәсең. Миңа нәрсә: «Мә!» — мәйтәм. Ярый, алыштык. Бераздан ишетәм, хуҗалык рәисләре бер киңәшмәгә җыелгач, район Мәдәният сарае каршыннан машинасын чәлдергәннәр. Ай начар булган!

Атна ярымнан мине тагын Арчага чакыралар. Председатель шулай ук таныш. Концерт кирәк икән. Сүз дә юк, киттек. Барысы да әйбәт үтте, соңыннан — сый-хөрмәт. Эш кепка алыштыруга килеп терәлде. «Әйдә!» — ди бу. Мәйтәм: «Дустым, әйдә алыштырмыйбыз. Минем белән баш киемен алыштырган предларның машиналарын урлыйлар. Хәтерлисеңме, — мәйтәм, — теге ике предны?.. Хәзер җәяү йөриләр». «Ым... да...» — диде председателем.

Кызуы шунда ук сүнде. Ну бу каракларны да әйтер идем инде, тапканнар кемнәрнең машинасын урларга. Хәзер концерт сорап чакырулар бетеп китте. Шул каракларның берсен күрсәм, чыраена төкерер идем.

## Күрешү

Бер елны Казанның бик макталып сөйләнелгән «Каенлык» сабан туена киттем. Автобуслар ташып кына тора халыкны. Килеп төшүем булды, каяндыр машина кортежы пәйда булды. Шәймиев килгән икән. Машиналарыннан төшеп, бер өер важный кешеләр Президент артыннан мәйданга үтә башладылар. Араларында минем белән бергә җырлап йөргән министрлар да бар. Элек бергә кызлар озаткан главалар да, бергә укыган депутатлар да, бергә эчкән начальниклар да. Без кызыксынып кырыйдан карап торабыз. Сизәм, үтүчеләрнең кайберләре мине күрәләр, ләкин күзләр очрашу белән күрмәмешкә салышып, Президент артыннан баруларын дәвам итәләр. Шту син, минем кебек диссидент белән рәҗе ярый күрешергә... Президент ни әйтер?..

Менә Шәймиев бераз гына алга китеп, борылып, халык белән сөйләшә башлады. Ул ярата бит инде шулай иркенләп аралашырга. Минтимер Шәрипович барчабызны да бәйрәм белән котлап алгач, халык арасына качып торган

мине күрде дә: «Менә монда Алмаз Хәмзин дә бар икән», — диде. Килеп күрешеп, бәйрәм белән котлады. Ул күрешкәч, башка министрлар, главалар, депутатлар, начальниклар да килеп кулымны кысып киттеләр. Хәтта өч ел элек сабантуйда бурычка акча алган бер сәрхуш тә әҗәтен түләп, иңемнән сыйпап китте.

## «Кыскарту»

Татар җәмәгатьчелеге сөекле шагыйребез Хәсән Туфанның 70 еллыгын тантаналы төстә үткәргән көннәр. Гадәттәгечә зал шыгрым тулы. Күрше республикадан, Мәскәүдән бик күп кунаклар, делегатлар килгән. Залда бөркү, тамашачылар кулларындагы чакыру билетларын җилпеп утыралар. Менә инде Башкортстаннан килгән олы кунак — әдип Сәйфи Кудаш (Сәйфи аганың күзләре күрми икән) сәгатькә якын Туфан турында якты истәлекләр сөйли. Сәйфи аганың озакка сузылган чыгышы залдагыларны бик талчыктырды, ахрысы, президиумдагылар үзара сөйләшә, кашына башлады. Кемдер борын җонын өзә, кемдер газета укый, кемдер түзә алмыйча сәхнәдән бөтенләй чыгып китә, кайберәүләр ашап та керергә өлгерәләр, ахрысы, чөнки теш арасына кысылган ризыкны чыгарырга берберсеннән шырпы сорарга тотындылар. Әнә берсенең аягы, ә берәүнең уңайсыз җире кычыта. Без тамашачыга барысы да күренеп тора. Залда тынчу булса да, безгә кызык спектакль бара. Ниһаять, тантананы алып баручы, мөнбәрдә сөйләүче Сәйфи аганың чыгышын кыскартып булмас микән дип, башкалар белән фикерләшеп алды. Ләкин ничек кыскартырга?.. Татарстан кешесе янына барып: «Сәйфи ага, кыскарта төшегез әле чыгышыгызны», — дисә, бу әдәпсезлек булыр иде. Килешеп бетмәс безгә башкорт дусларга мондый киңәш бирү. Әһә, уйлап таптылар бугай ситуациядән чыгу әмәлен. Нотыкчыны кисәтүне шунда ук президиумда утыручы Нажар Нәҗмигә йөкләделәр. Үз кеше бит — Башкортстаннан. Нажар абзыкай да аптырашта калды шикелле. Сәйфи агай сөйләп торган трибунага бер генә кеше аркасы утырса да, сигез кешене ерып сулга узды һәм президиум артында уйланып йөргәннән соң, кыяр-кыймас кына янына барып, агайның колагына нидер пышылдады. «Сәйфи ага, кыскарак тот!» — диде, ахрысы. Сәйфи ага аңладым дигән кыяфәттә бераз тынып торды да сүзен дәвам итте: «Шулай итеп, 1917 ел килеп җитте...» — диде.

## Җиде кояш

*(Пародия)*

Хөрмәтле тамашачылар! Сезнең игътибарыгызга бу атнаның «Җиде кояш» хит-парадын тәкъдим итәбез. Ниһаять, беренче җиделектә халкыбыз өчен кырык биш елдан артык җырлаган мәшһүр җырчыбыз Илһам Шакиров пәйда булды. Сөенәбез, Илһам абый! Сөекле җырчыларыбыз Лилия Хәмитова, Гөлнара Тимерҗанова, Сәгыйть Гыйбашев арасына керү үзе бер дәрәҗә ул! Ләкин бик борыныгызны күтәрмәгез. Әлфия Авзалова узган атнадагы алтынчы урыннан төшеп калган кебек, сезнең дә төшеп калуыгыз ихтимал. Шулай итеп, хит-парадыбызның җиденче баскычында Илһам Шакиров!

Берни сорама, тор тын гына,
Күземә кара, ярым...

Җиде кояш! Шулай итеп, хит-парадыбызның җиденче баскычында Илһам Шакиров булды. Дәвам итәбез. Күпсанлы тамашачыларыбыз халкыбызның атаклы җырчысы Габдулла Рәхимкулов язмаларын бирүне үтенгәннәр. Шуны исәпкә алып, алтынчы урынны Сәгыйть Гыйбашевка бирәбез. Шулай итеп, хит-парадыбызның алтынчы баскычында Сәгыйть Гыйбашев.

Әниемнең туган көне бүген,
Ярар инде, әни, елама...

Җиде кояш! Шулай итеп, «Әниемнең туган көне» дигән композициясе белән алтынчы баскычта Сәгыйть Гыйбашев. Хәзер инде хит-парадыбызның бишенче урыны турында сүз йөртик. Гафу итегез, баскычы турында. Бу баскычта үзенең «Трамвай» турындагы җыры белән Асаф Вәлиев! Молодец, Асаф, синнән троллейбус турында да җырлар көтәбез. Бер уңайдан шунысын да әйтеп үтәргә кирәк, беренче урынга чыгар өчен күчерелгән акча трамвай депосыннан әле килеп җитмәде.

Шулай итеп, бишенче баскычта үзенең «Трамвай» дигән композициясе белән Асаф Вәлиев!

Трамвай үтеп китә, трамвай килеп җитә, ишекләре шап итә...

Дулкыннарыбызда үзенең «Трамвай» дигән композициясе белән Асаф Вәлиев булды.

«Җиде кояш» хит-парадының дүртенче баскычын моңа кадәр гел беренче урында булган Салават Фәтхетдинов били. Гел-гел «Салкын чәй» дә туйдыра, ахрысы. Шулай итеп, дулкыннарыбызда Салават Фәтхетдинов «Салкын чәй» белән.

Гомерем шулай үтәрме, суынган чәйләр эчеп...

Җиде кояш! Кайнатып алырга кирәк, Салават, кайнатып. «Тефаль»еңне тыгып ал әле розеткага.

Шулай итеп, хит-парадыбызның дүртенче баскычында Салават Фәтхетдинов. Үзенең «Салкын чәй» исемле композициясе белән булды.

Ниһаять, беренче өчлек!

Беренче өчлекне төгәлли үзе концертлар куеп, үзе шуларны кичектереп йөрүче җырчы егетебез Айдар Хәлимов.

Куркам, куркам, үз-үземнән куркам,
Шул халәттә яшим күптәннән...

Хит-парадыбызның өченче баскычында «Куркам» дигән композициясе белән Айдар Хәлимов булды. Бутамагыз, Айдар Галимов түгел.

Җиде кояш! Беренче өчлекнең икенче баскычында су коенып җырлап йөрүче кызыбыз — Гөлнара Тимерҗанова! Яшьлек, чибәрлек. Икенче урынны бирми булмый.

Һаман да шул ук бит
Йолдызлар яңгыры.
Үтмәгән, үтмәгән
Мәхәббәт давылы.

Җиде кояш! Хит-парадыбызның икенче баскычында үзенең «Йолдызлар яңгыры» дип исемләнгән композициясе белән Гөлнара Тимерҗанова булды.

Ниһаять, хит-парадыбызның иң югары баскычы турында сүз алып барыйк. Бу урынны ныклы рәвештә, ул шулай булырга тиеш тә, Владимир алып тора. Беренче урынга җегәрлеләр, калын кесәләр генә лаек. Акча булмаса, милләт тә юк, җыр да. Шулай итеп, хит-парадыбызның беренче баскычында Владимир Пресняков. Киләсе атнада Шура була — теге тешсез урыс җырчысы.

## Бакча кыйссасы

Быел күрше Рәлиф үз бакчасына ике сыерчык оясы куйды. Берсен — өй кыегына, икенчесен — колга башына. Биек тә инде колгасы! Анысына сыерчык ияләшмирәк торды, ә өй кыегындагысында Рәлиф ояны кагып баскычтан төшеп җиткәнче үк тормыш башланды, ләкин андагы сыерчыкларның сайраганын бер дә ишетмәдем. Әллә эшләре бик тыгыз иде, базарга әйбер сатарга йөргән кешеләр кебек, тыз-быз нәрсәдер ташыдылар, сайрарга вакытлары җитмәде, ахрысы. Ләкин мин казыган җиргә төшеп, суалчан алмадылар. Бәлки, аларга күрше Рәфыйк Афзалович җире ошагандыр? Ни дисәң дә, профессор бакчасы бит! Ояларының шулар ягына карап торуы үзе бер дәрәҗә! Тиресләре дә күп, суалчаннары да симез, Исмәгыйльләр бакчасына исә барып та йөрисе юк. Алар күбрәк чәчәк утырта. Сыерчык бал корты түгел — гөл үбеп кенә тамак туймый.

Беркөнне сыерчыклар депутат Миңнуллиннар ягыннан йон ташый башладылар. Кичә: «Ул тирәдә кемнеңдер бакчасына кереп, әйберләрен апчыкканнар, урын-җирләрен тузгытканнар», — дигән хәбәр таралган иде, әллә шуннан чәлдерәләр инде. Ташысыннар... Безгә нәрсә. Язучы Кәримов белән журналист Гыйлемхановлар ягыннан берни дә ташымыйлар бит менә. Чөнки алыр нәрсә юк. Рәссам Зарипов бакчасына да туктап тормыйлар. Нәрсәгә аларга гипс яки буяу, карлыгач түгел бит алар.

Охшаса да охшар икән кеше тормышы сыерчыкныкына! Беркөнне көтмәгәндә колга башындагы ояга да бер сыерчык килеп кунды. Тирә-юньне бик җентекләп күзәткәннән соң, ояга кереп чыкты. Бераз сайрап алды. Аннан очты. Ошатмады, ахрысы. Сайланып йөри. Инде башкалар күптән күкәй өстендә утыра, ә бу һаман эзләнә. Ялгыз калырсың әле. Юк, бераздан болар икәүләп күренделәр. Әһә, мәйтәм, йөргән нәрсәсе яки икенче хатыны инде бу. Бик шикле кылана. Әй керәләр, чыгалар, сайрыйлар, ул үбешүләр, ул мәхәббәт куертулар! Гаҗәп инде. Берничә көннән тынды болар, сайраулар сирәгәйде. Гаиләдә ызгыш-талаш күбәйде, характерлары туры килмәде, ахрысы. Бу талашып яши торган сыерчыкларның кайсысыдыр күрше ояга кереп, анда тавыш куптарып чыкты. Ул оядагы гаиләдә дә тынычлык бетте. Әнә хәзер андагы ата сыерчык та оя өстендә моңаеп каткан. Мондагысы да уйда, берүзе басып - тора.

Карап торалар болар безгә: берсе өй кыегыннан, икенчесе колга башыннан. Карамагыз! Безнең дә тормыш шундый. Мең мәшәкать өстенә менә мең дә беренчесе — бакча!

Тыкрыктан «КамАЗ» килә, тирес тәкъдим итәләр: «Кемгә тирес, кемгә тирес, мең тәңкә генә!»

Ник сызгырдың, сыерчык?! Шулай хәзер: тирес — алтын бәясе. Димәк, тора-бара безгә анысы да эләкмәс, чөнки һәр сыерның койрык астына кемгә тиешле — шуларның исемнәрен язып, чиләк асып куялар. Гаҗәпләнерлек нәрсәләр күп. Инде ничә көн бертуктамый казынуыма шаккатасың. Менә берәр нәрсә үстереп булмас микән дип маташам. Булмаганын да беләм. Әйбер үсә торган җирне колхоз кешегә бирә димени? Менә шуның өчен ел саен сутыйга биш йөз тәңкә түләп торам әле мин.

Бүген бакчага тагын берүзем килдем, барыбыз да килсәк, юлга ике йөз тәңкә акча кирәк. Елына унбиш-егерме мәртәбә киленсә, өч-дүрт мең дигән сүз бит ул.

Саф һава дисеңме? Котыпта гына түгелме соң ул хәзер? Суы, елгасы дисеңме? Әйе, дөрес әйтәсең, уринотерапиягә шәп. Физик ял дисеңме? Карчыкларның: «Бакчаларда эшләп кенә бетте минем билләрем», — дигән иң яхшы җыры шул инде.

Менә чутлап кара: мең сумы — тирес, биш йөзе — җир өчен, бару-кайту — дүрт мең, страховкасы — биш йөз, кара исәп белән җәмгысы — алты мең. Ул хәтле акчага ни кирәк, шуны өеңә китереп бирәчәкләр бит: җиләк-җимешме ул, яшелчәме. Тик сине генә китермәсләр, сыерчык. Ләкин син дә бит ай ярымнан бакчаны ташлап урманга китәчәксең. Ә без һаман калабыз казынып.

Карале, җылы якларда сез мондагы кебек тагын күкәй салып, бала чыгарасызмы? Юкмыни? Ә мин чыгарасыз дип торам. Кешеләр бит моннан Анталиягә барып кайткалыйлар, мин шуның өчен баралар дип уйлаган идем. Ул яклар бәрәкәтсез икән.

Карале, сыерчык, сезнең президентларыгыз бармы дип сорамакчы идем, ярар инде сорамыйм, кирәкми, иркен яшәвегездән билгеле. Думагыз да юк, шунысына шөкер итеп яшәгез!

Җә, бар, ояңа кер, җәмәгатең белән татулаш! Миңа да кайтыр вакыт җитте. Бар инде, бар. Кер ояңа! Хатыныңны кереп кочакла! Мин дә кайтып шулай итәм.

Вәт, молодец, сайрап та җибәрдең. Рәхәт бит сайрашып яшәве. Их, җәмәгать, сыерчык сайравын ишетер өчен генә дә яшәсәң ярый икән бу дөньяда!

## Әйбәт саубуллашабыз

Дәүсовет бинасына елына өч керәм бугай мин. Кергән саен Роберт Миңнуллин очрый. «Син без эшләгән көннәрне сессиягә генә киләсең», — дип, мине үзләренә тиңләпме, зурлабракмы шунда әйтеп куйды. Кешегә әҗәткә сүзгә кергән юк бит инде. «Без сезнең кебек сессияләрдә генә эшләмибез, ел буе эшлибез», — дим Робертка, үпкәләмичә генә.

Сөйләшеп киттек.

— Беләсеңме, Роберт, синең «Әнкәй» дигән җырыңны иң беренче мин җырладым бит.

— Ничек алай? — дип шаккатты бу.

— Берзаман Сара апа Садыйкова белән дуслашып киттек. Минем студент чак. Ул мине Тинчурин урамындагы фатирына чакырып, яңа җырлары белән таныштырды. Ара-тирә телефоннан шылтыратып, кешеләр белән яртышар сәгать сөйләшеп ала иде. Мин шул арада аның нотага төшерелгән күпсанлы җырларын күзәткәләп утырдым. Араларында күңелгә яткан бер җыр барын сизәм бит. Көе дә матур, сүзләре дә әйбәт. «Әнкәй безне Сөннән алып кайткан, Сөн суында юган иң элек». Кәгазьнең бер почмагына Роберт Миңнуллин сүзләре дип тә куелган. Сара апа күрмәгәндә тиз генә күчереп алдым моны нотасы-ние белән. Теге «Әллүки» дигән студентлар әдәби берләшмәсендә йөрүче Роберт дип беләм бит инде сине, студент тулай торакларында чыгышлар ясаганыгызны күргән бар иде.

— Әйе шул, без йөри идек инде ул, — дип җөпләп куйды Роберт. — Шуннан?

— Шуннан кесәгә тыгып куйдым мин бу җырны. Сара апа иртәгесе көнне Укытучылар йортына концертка чакыра. «Килеп кит әле, шунда үзең белгән бер җыр да җырларсың»,— ди. Сынап карыйсы килде микән минем ничек җырлавымны? Миңа бер генә яңа җыр да бирмәде.

Икенче көнне киттем Укытучылар йортына. Бераз соңлабрак барырга туры килде, дәресләрдән качып булмады. Залга килеп кердем, Сара апа үзе концертны алып баручы да икән: «Әнә Алмаз да килеп җитте. Кил әле монда, нинди җыр җырлыйсың?» «Әнкәй», — мәйтәм. «Кемнеке ул?» — «Сезнеке, Роберт Миңнуллин шигыре».

Сара апа тамашачыга борылды да: «Минем җырны җырлыйм дип әйтә, белмим, тагы нинди җыр икән ул, минем бит «Әнкәй» дигән җыр язганым да юк». «Бар, — мәйтәм, — менә тыңлап карагыз!» Үзем белән килгән баянчы дустым Ринат Илаев уйнап җибәрде. Җырны игътибар белән тыңладылар, аннан халык гөрләп кул чапты. Яңадан сорап җырлаттылар. Сара апа: «Бу бит әле минем язылып та бетмәгән җырым иде. Син аны кай арада урларга өл-

герден? Мин бу җырны берничә вариантта язган идем, менә Алмаз җырлаганы бик уңышлы күренә, шунысын калдырырмын, ахрысы»,— диде. Менә шулай, Роберт туган, җырыңның бәхетле язмышы башы. Ул — хәзер дә әнкәйләргә багышланган иң күркәм җырларның берсе.

Куллар бирешеп, Дәүсоветтан чыгып китәр алдыннан тагын бер нәрсә искә төште.

Инде баскычтан өскә күтәрелгән Робертны туктатып:

— Роберт, ачуланма, бер нәрсә әйтәсем калган, гел онытам шуны. Җәй көннәрендә бакчаңда да бик күренмисең, карале, бакча кешеләре сиңа зур рәхмәтләрен белдерәләр, җиткер әле, күрсәң, безнең шатлыкларны, диләр. Бакчага сазлык өстеннән син салдырган асфальт юлны хәзер «Миңнуллин юлы» дип йөртәләр. Әй рәхәтләнде, малай, халык. Интегә идек бит. Үзеңнең үткәнең бармы ул юлдан? Син үт әле аннан, үт! Бакчаңда йортыңны да төзеп бетерәсең бардыр. Депутат башың белән мунча кадәрле йортта яшәмә инде!

— Пока!

— Пока!

## Минем дә күңел тыныч

Казан шәһәренең «Комсомолец» клубында директор булып йөргән чаклар. Клуб тирәсендә төзүчеләрнең тулай тораклары урнашкан. Җыр сөючеләр, биергә теләүчеләр, театр яратучылар, әдәбиятка мөкиббәннәр өчен җаның никадәр тели, шулкадәр түгәрәкләр эшли. Кино карыйсың, гайрәт-егәр арттырасың килсә, штанга күтәрәсең, сәламәтлегеңне җиңелчә генә кайгыртасың килсә, волейбол, футбол, теннис уйныйсың. Бар иде бит, җәмәгать, шәп чаклар: җәй буе клуб каршындагы «пятачок»та типтереп биюләр, типтереп җырлаулар. Шунда бер хулиган, бер исерек күрмәссең. Ул кызлар! Татарча аралашып, танышып дуслашып йөри идек. Күпләребез үзләренең хәләл җефетләрен шунда таптылар.

Хәер, сүзем бу турыда түгел. Шулай клуб шаулый, гөрли. Мин шул тирәдә яшәүче төзелешләр белән очрашуга атаклы язучыбыз Гариф ага Ахуновны чакырырга ниятләдем. Күрешеп ризалыгын алдым, көнен билгеләдек. Ярый каршы килмәде. Аннан барлык китапларын укып чыктым һәм шунда бер кызыклы фактка тап булдым. Гариф абый минем белән бер көнне — 18 сентябрьдә туган икән бит. Шәп! Очрашуда уйнатырмын мин бу әйберне. Әсәрләре белән ныклап танышкач, бик күп язма сораулар әзерләдем: тамашачыларым килгәч, аларга өләшермен, очрашуда залдан үзләре бирерләр дидем.

Килде Гариф абый. Сәхнәне үземчә чит илдәге кебек итеп кордым. Складта нинди музыка коралы бар, шуларны сәхнәгә тездем, арткы планга күтәребрәк, галәмәт күп барабаннар урнаштырдым, алда бихисап микрофоннар. Буш урын тик торачак журнал өстәле һәм ике урындык өчен генә калды. Тугыз микрофонның берсе генә эшли, ул да булса Гариф абыйга карап торганы гына. Залдагы гомуми ут сүндерелгәч, ян-яктан яктыртып торучы ике ут, киномеханик будкасындагы кинопроектор прожектор яктысында, түшәмдә бөтерелеп тора торган шар гына җемелди. Гаҗәп! Менә Гариф абый белән сәхнәгә чыгабыз. Халык хәйран калып кул чабарга тотынды. Әле бит бер сүз дә әйтмәгән. Вокаль-инструменталь ансамбль уйнап җибәрде. Мин: «Хөрмәтле тамашачылар, бездә бүген кунакта Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты, сөекле язучыларыбызның берсе — Гариф Ахунов!» — дип әйтергә өлгермәдем, кул чабулар тагын тавышымны күмеп китте. Халыкны көчкә тынычландырып, Гариф абыйга сүз бирдем. Рәхәтләнеп сөйләде Гариф абый: әй күкләргә чөя кулын, әй атлап китә як-якка — урын гына тар. Сәхнәгә диван куйсам, ятып та сөйләр иде, газизем. Җитлекмичә тууы турында да сөйләде, әнисенең аны күәс калагына куеп, җылы мичкә тыгып алуларын да — әйтерсең үзе күреп торган. Сәгать ярым сөйләгәч: «Инде хәзер сорауларыгыз бармы?» — диде. Тотындылар, малай, минекеләр кәгазьләп сорау яудырырга. Шакката Гариф абый. «Нинди укымышлы, нинди зыялы, нинди мәшһүр сездә тамашачы! — дип тә җибәрә.— Мондыйны гомеремдә күргәнем юк иде, — ди. — Тагын сораулар бармы?» — дигәч, «Гариф абый, минем сорау бар иде», — дидем. Карап тора миңа бу озын чәчен артка ташлап, бөекләр хәрәкәте белән. Мәйтәм: «Сез 18 сентябрьдә туганнарга ничек карыйсыз?» Секунд эчендә минем карашны җентекләп өйрәнгәч, сүзен башлады: «18 сентябрьдә туганнар алар иң беренче Кеше булалар, бөек булалар, даһи булалар, ким дигәндә минем кебек язучылар булалар!» «Рәхмәт, — мәйтәм, — Гариф абый, минем адреска шундый җылы сүзләр әйтүегезгә, мин дә бит 18 сентябрьдә туган кеше». Зал «урра»лап кул чапты. Кичәбез тәмамланды. Гариф абыйның күзләрендә канәгатьләнү хисләре яшь булып мөлдери иде. Ул миңа: «Рәхмәт, энем, мине бик зурладың, минем бүген иң шатлыклы көнем», — диде. Рәхмәт, Гариф абый, үзеңә. Инде якты дөньядан китсәң дә, син яраткан тамашачың, укучың күңелендә якты нур булып калдың.

Мин ул тамашачыларны хәзер дә еш очратам. Клублар хәзер элекке кебек гөрләми. Яшьләргә күңелсез. Ә теге вакытта сиңа записка биргән тамашачылар китапларыңны соңыннан укыдык диделәр. Минем дә синең алда хәзер күңелем тыныч.

## Бәйрәм белән!

Өйдән урамга чыгуым булды, подъезд төбендәге сәрхушләр: «Бәйрәм белән, күрше!» — дип сәлам бирделәр. Үзем дә берни аңламыйча җавап сәламемне ыргыттым. Эчтән генә: «Нинди бәйрәм икән?» — дим. Беләм тегеләрнең тел төбендә бер яртылык акча кирәклеге ятканын. «Ниме, күрше?..» — дип сүз башлаулары булды: «Юк шул», — дип җавап бирдем. Чырайлары сытылды. Мин алга ыргылдым. «Халыкара наркоманиягә каршы көрәш көнендә жмутлана», — дигән сүзләре янына әллә нindиләрен өстәп сүгеп калдылар.

Үтә гомер. Менә 8 Март — Халыкара хатын-кызлар көне дә килеп җитте. Әйбәт бәйрәм. Язның беренче бәйрәме. Ир кеше булсам да, бәйрәм белән котладылар, рәхмәт яугыры!

Беркөнне базарда кирәк-ярак эзләп йөрим. Берәү мине күрде дә: «Бәйрәм белән, кордаш!» — диде. Нинди бәйрәм икән инде тагы, мәйтәм. Аптырап торганымны күргәч: «Русиянең Эчке эшләр гаскәрләре көне», — дип өстәп куйды. «Ә-ә, беренче апрель белән котлыйсың дип торам», — мәйтәм. Вәт кешеләр әллә нинди бәйрәмнәр беләләр, ә мин сабантуйны да Яңа елны гына. «Әйдә, бераз», — дип, тамагына чиртеп күрсәткән иде дә, мин: «Юк шул...» — дигәч, аерылыштык.

Бер ай чамасы каты-коты кимереп, тишек-тошык ямап, тормышның очын очка ялгап, бәрелеп-сугылып йөри идем, берәү: «Сәлам, Алмаз, бәйрәм белән!» — дип кычкырды. Таныш та түгел бугай. Алдым сәламен, үзенә җибәрдем. Май бәйрәме белән котлавыдыр инде. Ул да, мин дә хезмәт ияләре бит — безнең бердәмлек көне. Безне бит шул хәерчелек берләштерә. Алай түгел икән. «Нинди бәйрәм?» — дигәч, «Радиация һәлакәтләрендә һәлак булганнарны искә алу көне. Мин генә исән калдым бугай инде», — диде. «Чернобыльдәгеме?» — мәйтәм. «Әйе, көнгә бер стакан «кызыл» кабып кына исән йөрим, синең юкмы?» — ди. Бирми нишлисең шундый каһарман кешегә. Бирдем дә сыздым.

Атна үтмәде, эштәге Нәсим: «Сәлам, брат, бәйрәм белән!» — ди. Иртүк өйдән чыгып китәр алдыннан үземә акча бары тик транспортка гына дип установка куйган идем. «Син сержантмы әле? Бүген бит Русия Федерациясе Кораллы көчләре оешкан көн. Һәй, брат, шуны да белмисең», — дип, мине оялта башлады Нәсим. «Кит аннан! — дип гаҗәпләнгән булам. — Нинди зур бәйрәм! Ләкин акча юк шул!» «Эх, — диде Нәсим, уфтанып, — шундый яхшы бәйрәм иде, боздың». «Ә мин сине Җиңү бәйрәме белән тәбрик итәсең дип торам бит, кардәш, 9 Май белән». «Аның белән дә ярый», — ди Нәсим. «Менә аның белән булса, мин дә сине бәйрәм белән тәбрик итәм. Әйдә, билгеләп үтәбез. Әтинең дә сугыш ветераны икәнен искә алабыз. Аның исәнлеге өчен чәкештерәбез».

Ул көнне лычкылдап өйгә кайтып кердем. Менә, ичмасам, бәйрәм! Икенче көнне махмырга берсекөнгә булачак Кара диңгез флоты бәйрәмен дә билгеләп үттек. Бәйрәм атна буе барып, 19 май СПИДтан үлгәннәрне искә алу көнен дә онытмадык. Чик сакчылары көне дә шунда керде, бу бәйрәмнәр сабантуйларга ялганып, ай ярым дәвам итте. 22 июнь сугыш башланган көнне айнымакчы идек тә, Хәтер һәм кайгы көне икәнен белеп, тагын баш төзәттек. Июль ахырларында гына аңга килдем. Берәү 27 июль көнне Хәрби диңгез флоты көне дип, бәйрәм белән котлап, сәлам биреп калды, алмадым сәламен. Ишетмәмешкә, күрмәмешкә салышып киттем. Ике ай буе бәйрәм итеп йөрүләр колакка да, күзгә дә, башкага да зыян китергәндәй тоелды. 1 августта Кораллы көчләрнең тылда хезмәт итүче гаскәрләр көнендә урамга чыкмадым. Күршеләр минем тәрәзәләргә сәлам биреп йөрделәр йөрүен. Нигә дисәң, бер чыксаң, 1 август 4 числодагы Һава десанты гаскәрләре көне белән ялганып китәргә мөмкин. Аннан 12 се — Хәрби һава көчләре көне килеп җитә. Җәй айларындагы кебек онытылып «бәйрәм итәргә» ярамый. 30 августтагы Татарстан Республикасы көнен күреп каласы килә. Аннан соң 4 сентябрь Аеклар көне икән бит. Язучы Мөдәррис 1 сентябрь — Белем көнен яхшылап билгеләп үтәргә тәкъдим ясады. Тәкъдимен бертавыштан кабул итеп алдык та шул ук көнне берочтан Бөек Октябрь социалистик революциясен дә искә төшердек. Күп «төшерелгән». Милиция көне дә, Ракета гаскәрләре һәм артиллерия көне дә, Диңгез пехотасы көне дә, Русия хәрби даны көне дә, Стратегик юнәлештәге ракета гаскәрләре көне дә. Әллә каян гына Яңа ел килеп җиткәнен дә сизми калганбыз. Ураза да онытылган.

Җитәр. Туктарга вакыт. Яңа елны яңача яши башларга кирәк. Кирәкми бәйрәмнәр!

Яңа елның беренче ундүрт көнен өйдә әвәрәләнеп үткәрдем. Ике атна буе мәҗбүри ял иттерделәр. Эшләтмиләр. Яңача яшибез. 27 гыйнварда бер танышым: «Киләчәк бәйрәмнәр белән!» — дип караган иде дә, эндәшмәдем. «Чирлисеңме әллә?» — ди. Корбан бәйрәме белән котлаган икән. Рәхмәт. Инде бәйрәм белән тәбрик итүчеләрдән кот

чыгып тора. Менә 23 февраль җитте — Ватан саклаучылар көне. Иртүк — кыңгырау. Куркып кына ишек ачсам, фатирга түләргә счет-фактура тотып, берәү: «Берүк егыла күрмәгез, бәйрәм белән! Фатирга арткан!» — диде. Күзләр маңгайга менде. Мең тәңкә!

Да-а! Хәерчеләр тагын бер сугыш чыгарып «бәйрәм» ясамасалар ярый инде.

## Ничә градыс?

Уйланып йөрим. Бабай исән чагында кисәк кенә, гаҗәпләнеп: «Бәрәч, туры почмак 100 градус түгелмени?» — дип куйган иде. Мин: «90 градус», — дим. Ул: «Гомер буе 100 дип йөрдем, чутлаганда беркайчан да ялгышмадым», — ди.

Кызык бит. Ул туры почмакны 100 градус дип яшәгән. Гомер юлының җиде чатында күп икеләнеп торырга туры килгәндер аңа, тормыш түгәрәген йөз кисәккә бүлеп кайсысын сайларга белмичә газаплангандыр...

Безнең ил кешесе һәрвакыт сәер шартларда яшәде. Берзаман, революция ясап, байларны кудылар да, нэп оештырып, яңаларын тудырдылар. «Колхоз» дип мал җыйдылар, инде хәзер анысын да җуйдылар. Сугыш дип миллионлаган кеше кырдылар, сугышмыйча ГУЛАГларда һәлак булдылар. Тик торганда Американы узып китәргә уйладык. Ындыр артындагы чәчүлекләрне ташлап, җәһәннәм тишегендә чирәм җирләр сөрдек. Иген иктек — черек бәрәңге ашадык. Галәмне иңләдек — шәрә йөрдек. Нефть саттык — акча булмады. Байыйсыз дип ваучер бирделәр — бөлдек. Коммунизм төзедек — капитализм килеп чыкты. Монда 90 градуслык туры почмагың бабайныкы төсле 100 ләнергә түгел, 99 ланырга мөмкин.

Башта бер сыердан бер пот сөт алу турында сүз барды. Берзаман кайсыдыр колхозның сыер савучысы, 17 литр сөт алам, дип мактанып җибәрмәсенме! Аңа: «Ике пот сава аласыңмы?» — диделәр. Ул: «Алам!» — диде. Шулай итеп, 17 литр сөт 2 пот сөт күләменә әйләнде. Калганына нәрсә кушадыр, анысы билгесез — нәтиҗәсен ашказаны язвасы әйтер.

Шулай шаукым өстенә шаукым өстәлеп яшәгәндә, Стаханов дигән кеше шахтада бер норма урынына ике норма план үтәячәге турында шапырынып җибәрмәсенме! Аннан — өч, аннан — дүрт, әй китте, китте... Баксаң, аның өчен бөтен бригада эшләгән икән. Кемдер кирәк бит халыкны котыртып җибәрергә. Шулай итеп, «литр» гына түгел, «көнлек норма» да алдауга әйләнде.

БАМ төзеп, километрларда буталдык. Хөкүмәт бишьеллык, җидееллык планнарында чуалып бетте. Хәзер чын демократиянең нәрсә икәнен белми. Акча алыштыралар шалт та шалт. Кичен — фолт, иртән — дефолт! Ничек ышанмыйсың түгәрәкнең 400 градус булмасына!

Берочтан мәгълүм бер гыйбрәт тә сөйләп китим инде. Элегрәк бер колхозда җыелыш үткәрәләр. Иң башта райкомның беренче секретаре сүз ала.

— Җәмәгать, сез Ватаныбыз даны өчен күп тырыштыгыз, шуның нәтиҗәсе булып, каршыгызда алдынгылар байрагы җилферди. Ләкин клубыбыз булмау бик борчый. Шуңа күрә концертлар да карый алмыйбыз. Бу двор өендә кеше көлдермәгез. Мин сезгә акча җыеп клуб төзергә тәкъдим кертәм. Ризамы?

— Юк! Юк! — диләр колхозчылар.

Секретарь үпкәләп урынына утыра. Сүзне райисполком рәисе ала.

— Җәмәгать, мин сезне аңлыйм, уңышлардан башыгыз әйләнгән, ләкин шунысын онытмагыз, партия сезгә авылыгызның культурасын күтәрү юлын күрсәтә. Ә сез каршы килеп маташасыз. Җыябызмы акча клуб төзергә?

— Юк! Юк! — дип җавап бирәләр колхозчылар.

Ниһаять, колхозның партком секретаре кулын күтәреп сүз сорый.

— Авылдашлар, сез оныгы кияүгә чыкканда Мәүлидә әбинең аның колагына нәрсә дип әйткәнен хәтерлисезме?

— Хәтерлибез, хәтерлибез! — дип җавап бирәләр барысы да.

Һәм «Җыябыз! Җыябыз!» диләр гөр-р итеп.

Җыелыштан соң, гадәттәгечә, өстәл әзерләнгән, беренче секретарь партком секретареның иңбашын дусларча кагып мактый башлый.

— Сине югарыга күтәрергә кирәк булыр. Ә бит Мәүлидә әби оныгына нәрсә дигән инде?

— Әй, аны безнең авылдагылар бөтенесе дә белә. Кияүгә чыгар алдыннан Мәүлидә әбинең оныгы килгән дә аннан киңәш сораган. «Ничегрәк, кайсы ягы белән ятсам, иремә җайлырак булыр икән?» — дигән.

— Теге нәрсә дип җавап биргән?

— Ә тормыш тәҗрибәсе җыйган Мәүлидә әби әйткән: «Ничек кенә боргаланма, кызым, ул барыбер үзенекен таба», — дигән.

Дөрес әйткән Мәүлидә әби. Законның үз туксаны туксан, ә тормышның үзенеке. Ә сезнеңчә ничек, хөрмәтле укучым? Сезнеңчә туры почмак ничә градыс?

## Без ничә тиенлек?

Мин инде яшем буенча малай-шалай түгел, күп нәрсәне аңлыйм, төшенәм, тормышның күп кенә сорауларына җавапларым да бар, ләкин җавап таба алмый изаланганнары да юк түгел. Менә шуларның берсе — «Хезмәт хакының күләме фәлән хәтле булырга тиеш» дигән киртә-чикне кем уйлап чыгарган? Әйтик, нигә укытучы — ике мең чамасы, табиб — ике ярым, китапханәче — мең биш йөз, колхозчы — тугыз йөз сум, пенсионер мең ике йөз алырга тиеш? Артист сәдака исәбенә яши.

Тагын бер сорау: «Нигә фатир яки йорт-җир өчен түләүләр шулкадәр күтәрелде?» Биш кеше яши торган өйгә мең ярым — шалт, Мөхәммәтҗан! Ә ике мең алып эшли торган, дүрт баласы студент булган укытучы Нурҗамал апа ничек яшәргә тиеш? Ул фатирга түләү бәясен кайсы шүрлектәге законнан алып куйганнар?

Аннан, хөрмәтле пенсионерлар, сездән сорыйм: «Аллага шөкер» дисез дә (анысы әйбәт. Ходай Тәгаләне онытмыйсыз, зурлыйсыз), ничек шул песи пенсиясенә яшисез? Кайсы аять-сүрәләрдә яки карарларда билгеләнгән ул ай саен бирелә торган хөкүмәт хәер-сәдакалары. Әллә «өстәгеләр» менә монысы — халыкка, калганы үзебезгә дип чамалап бүлеп куялармы? Нинди чыбыклардан үрәләр икән ул тариф челтәр-ятьмәләрен? Сезнең чит илдәге кордашларыгыз, лаеклы ялларына чыккач, илләр гизеп, кәеф-сафа корып йөриләр. Ә сезгә аларның кыска чалбар киеп безнең Кремльне карап йөрүләрен күрү өчен шәһәр автобусларына утырып килергә дә акчагыз җитми.

Безнең илнең сиксән өч миллиард сумлык алтын-финанс ресурслары бар. Финанс министры Кудрин бу турыда һәрвакыт Путинга килеп мактанып тора. Кеше баеган саен саранлана бара, диләр. Элегрәк кайбер кешеләрнең байлык җыеп та гомер буе сәләмә кием киеп йөргәннәрен язалар иде. Үзләре үлгәч, чүлмәк-чүлмәк алтын-көмеш табылу фактлары күп булды. Безнең ил дә шундый халәттә түгелме?

## «Шалтыраулар дәвам итә»

Кайвакыт матур-матур тапшырулар карыйсы-ишетәсе килә, әмма эфирдан яңгыраган бер үк сүзләр теңкәгә тия: «Безгә шалтырату бар, сезне тыңлыйбыз», «Сез тапшыруны бик матур алып барасыз. Без сезне яратабыз», «Әниемнең туган көне иде, берәр матур җыр тапшыра алмассыз микән?», «Пейджерга килгән хәбәрне укып китәбез: «Рамил, мин сине яратам!», «Бу араларда минем концертым була, рәхим итегез, менә кассетам чыкты», «Тапшыруыбыз ахырына якынлашып килә», «Безнең белән калыгыз!».

Нервы чыга башлый. Юкмыни соң бүтән сөйләшеп утырырлык җиңелрәк сүз, ә?.. Сөйләшә белүче кайда да, сөйләштерүчесе кайда? Сөйләштерүчесе «шундыйрак» булгач, аның рәтләп сөйләшеп утырырга теләүчесе дә булмаячак бит. Без кечкенә чагындагы колхоз радиосының сөйләве искә төшеп китте әле. Авыл Советы рәисе булып хөрмәтле Нурҗамал апа торган чак. Махсус белеме юк иде, фермада эшләп дан казанган кеше булгач, күтәрделәр үзен. Иртәнге җыелыш-нәрәдне радио аша гына бирә:

— Җәмәгать, ирешкәннәргә куанып, кул кушырып утыра торган чак түгел. Партия бездән яңа җиңүләр көтә. Әле кичә генә Ташлык авылы буенча сөт тапшыру күрсәткечләрен тикшереп утырдым. Әйбәт, ләкин тагын да әйбәтләп була. Менә Әсма апаны гына алыйк. Әсма апа, сөтең синең әйбәт, куе. Ә бит син аны тагын да күбрәк тапшыра аласың. Уйла әле, Җәвәһирәгә дә әйт, балалар бар дип сөт кысып ятмагыз!

Бу ни хәл бу? Мотыйк абый, карале, күрми дә торам, җон тапшырмагансың бит син, ә! Җонның бар бит синең. Давай, ничек итсәң ит: йолкып җыясыңмы, кыркып җыясыңмы, анда минем эшем юк, хөкүмәткә җон планыңны тапшыр. Штубыто башка сүз чыгарлык булмасын.

Тәк, күкәй планы турында. Наилләрнеке әйбәт, Фәхерләрнеке дә ярыйсы, Шәйхразыйныкы түзәрлек, Миңнурныкы чыдарлык. Хәсәнша абый! Карале! Күрми дә торам, оят түгелме сиңа? Ир башың белән бер күкәй дә тапшырмагансың. Хәсәнша абый, авылның почетный кешесе дип тормам, бар халык алдында рисвай итәчәкмен үзеңне. Давай, күкәеңне китереп бир! Дәлше бу турыда сөйләшмибез.

Шәңгәлчә авылы буенча... А-а! Юк, җәмәгать, сезнең белән радио аша гына сөйләшеп булмый, бүген җыям собрание, крупный разговор кирәк. Или собраниегә хәтле сөтегезне, җоныгызны, күкәегезне как положено здавать итегез, или миннән пащады көтмәгез! Бүгенгә бетте. Саубуллашасым да килми.

Нурҗамал апаның сүзен бетереп, радиоузелдан чыгып китүе була, микрофон алдына колхозның алдынгы шоферы Бәгъде абый килеп, белдерү укый башлый:

— Белдерү тапшырабыз! (Кыштыр-кыштыр кәгазь тавышлары килә, өстәлдән әйберләр ишелеп төшкәндәй була, әллә микрофон да мәтәлә инде.) Ах, чукынды, б... Нәрсә дип язган идем соң әле мин анда? Камил, дим, белдерү тәрәзәдән очып чыгып китте, алып кер әле! Вәт авызын... Булмады инде... Тот, тот, суга төшкәнче. Җебегән!

— Син үзең җебегән! Дундук! Кулыңдагы белдерүне дә тотып тора алмагач, ни пычагыма радиоузелга кердең соң, анаңны сельсоветка чакыртасы нәрсә.

Шул вакыт радиоузелга, боларның сүгенүен радио аша ишетеп, председатель килеп керә.

— Сез нәрсә анда, анагызны... микрофонны сүндермәгән килеш сүгенеп йөрисез. Ну-ка ычкыныгыз әле моннан яппашумайтлар! Икегезне дә печәм хәзер.

Радиоузелда эшләүче Камил, безгә радио аша күренмәсә дә, нәрсәдер әйтергә тели бугай, тик ярсыган предны инде һич туктатып булмый.

Ә микрофон эфирга «матур-матур» сүзләр таратуын һаман дәвам итә:

— Анагызны... денегезне!..

Ул колхоз радиосы гына булса да, тапшырулары кызык иде. Ә хәзер халык эфирга карап үзе сүгенеп утыра. Анда һаман шул бер үк «җыр»: «Кодагыема җыр тапшырсагыз икән. Бәхетләре гомерле, гомерләре бәхетле булсын иде...»

## Бухгалтер

Атаклы «Саз» ансамбле Бөтенсоюз күләмендәге лауреат исеменә лаек булган чак. Мин — «кинопленка» клубында директор урынбасары, ә ансамбльнең җитәкчесе Рифкать Гомәров — минем шеф. Урынбасар булгач, җырдан тыш мәшәкатьләрне дә миңа тапшырдылар: ансамбльнең һәрбер җырчысы өчен юл, ашау-эчү, куну-тору, акча чыгымнарын минем өскә йөкләделәр. Менә Мәскәүдә биек үрләр яулап, киерелеп, Казанга кайттык. Тегендә шимбә, якшәмбе көннәре туры килү сәбәпле, командировочныйларга печать сугар кеше таба алмадык. «Һәй, — диделәр, — мондый дәрәҗәләргә ирешкәч, кем сездән печать сорап торсын! Телевизордан да күрсәттеләр бит!»

Менә, кайткач, хисап ясап йөрим. Профком бухгалтеры Роза апа — урысча сөйләшүе безнеке шикелле — карап-карап торды да: «Пичәт бит ниту», — диде. Әйе, мәйтәм, печать суктыра алмадык, чөнки ял көннәре туры килде. Мин бит инде шуны суктырыр өчен тагын ике көнгә кала алмыйм. «Чыгыш ясаганыгызны, лауреат булганыгызны бөтен ил күрде, шуңа күрә печать сорап тормаслар әле», — диделәр.

— Күрдегезме, Роза апа?

— Күрдем.

— Соң, шулай булгач, отчетымны кабул итеп алыгыз!

— Пичәт бит ниту...

Мин яңадан аңлатам:

— Без булдыкмы? Булдык. Генсек Брежнев кул чабып утырганын күрдегезме?

— Күрдем.

— Без лауреат булдыкмы?

— Булдыгыз.

— Соң, болай булгач, безнең Мәскәүдә булуыбыз сезгә мәгълүмме?

— Мәгълүм.

— Отчетны алыгыз!

— Пичәт бит ниту.

Мин яңадан башлыйм:

— Роза апа! Сез кешеме, юкмы?

— Кеше.

— Алай булгач, алыгыз!

— Җә, ярый, калдыр инде.

— Рәхмәт.

Җиңеләеп, иңемнән тау төшергән кебек, клубка кайтып китәм. Рифкатькә, ниһаять, отчет ясадым, дип мактанып утыра идем, телефон шылтырый, Роза апа тавышы:

— Алмаз, пичәт бит ниту.

Ах, сүгендерәсез инде...

## Директор һәм сәнгать җитәкчесе

Төзүчеләр трестының «Комсомолец» клубында худрук, ягъни, безнеңчә әйткәндә, сәнгать җитәкчесе булып эшләгән вакытта минем авторитет күкләргә чөелгән иде. Клубның даны бөтен шәһәргә гөрли. Монда төрле кичәләр, концертлар, дискотекалар, яшьләр уеннары, төзүчеләр өчен ял вакытларында күңелле очрашулар оештырыла. Трест башлыгы иптәш Иванов, урамның икенче ягыннан минем якка чыгып, күрешеп китә торган чаклар булды. Шулай эшләдем. Берзаман мине директор итеп куйдылар. Эшләр шулай ук дәвам итә, клубның даны яңгырый. Тик минем элекке эшләргә хуҗалык мәшәкатьләре дә өстәлгәч, ягъни колхозга бәрәңге алырга баручыларны җыю, пионерлагерьга матрас кагучыларны туплау, өмәләр үткәрү, файдаланырга тапшырыласы йортларны чүп-чардан чистарту, колорадо коңгызы җыю, чебен үтерү, бет сыту кебек эшләр дә тапшырылгач, иптәш начальнигым юлны аркылы чыгып күрешү түгел, исәнләшми дә башлады.

Ярый, анысы үзенә булсын, безнең үзебезнең эш бар. Безнекен берәү дә эшләмәс. Ул вакытлардагы «Праздники советской семьи» бәйрәмнәре турында языйм әле. Ул бәйрәмне кибетләрдә сатыласы прәннек-печеньеларны анда саттырмыйча клубка алып килеп, кеше сугыштыра-талаштыра оештыралар иде. Чәйләр сатабыз, шикәр, зефир — бөтенесе дефицит. Шул печенье-прәннек янында җырлыйбыз, бииебез. Менә карагыз, без нинди бәхетле! Нинди күркәм илдә яшибез!

Берзаман клубка райкомның идеология буенча секретаре — матур ханым (билгеле сәбәпләр буенча исемен язмыйм, җә үпкәләр) килеп керде. Бардак бит инде. Ызгыш, талаш — товар җитми. Теге матур ханым әйтә: «Что за безобразие?!» Мин аңлатам: «Ул булмаган печеньены, клубка алып килмичә, кибеттә дә сатарга була бит. Сезгә килешми, кеше алдында шауламагыз!» — дим. «Где ваш кабинет?» — дип ысылдый бу миңа. Мин, аны-моны уйлап тормыйча, ирләр бәдрәфенә күрсәтәм. Керсен, анда безнең районның җыен хулиган малайлары шырпы яндырып, түшәмгә ябыштырып яталар. Бер тапкыр да клубка килеп карамаган район җитәкчесенең юлы шунда. Ә кычкырырга оялмый.

Әй атылып килеп чыкты бу кирегә, малай! Бер сүз дә әйтмичә «Волга»сына утырып шылды.

Бер сәгать тә үтмәгәндер, мине бик тә хөрмәт иткән профком председателебез Геннадий Васильевич чакыра: «Нәрсә булды, сине «теге» уволить итәргә куша бит!» Мин аңлатып бирдем. «Йә, ярый, — диде Геннадий Васильевич, — минем сине җибәрәсем килми. Кабат худрук булып кал! Акчаңны да арттырырбыз!..»

Чыннан да әйбәт булды: трест начальнигыбыз иптәш Иванов та урамның теге ягыннан чыгып минем белән кабат исәнләшә торган булып китте, клуб эшенә дә зыян килмәде.

Ә теге әлеге дә баягы матур ханым хөкүмәт концертларында зур оркестрларга кушылып җырлаганымны күргәч, кыенсыныбрак булса да, гафу үтенде.

Миңа рәхәт, чөнки минем бернинди дә гаебем юк.

## Патриот

Бала чак. Без ул вакытта урамнан кайтып керми идек. Нинди генә уеннар юк: кыш керсәк — кәшәкә белән каткан ат тизәге куу дисеңме, кардан крепостьлар өеп, аклар-кызылларга бүленеп, яки «безнекеләр»гә һәм «немесләр»гә аерылып, атышып йөрү дисеңме... Без аны «кыхлы» уйнау дип атый идек. Җәйгә чыксак, бүтән уеннар. Уйнап кына бетер! Уйнарга кышын уку комачауласа, җәен эштән арынып булмый: печән әзерләү, утын ташу, кисүяру, каз карау, сыер, сарык көтү. Авыл җирендә эш бетә торган түгел. Көзен бик уйнап булмый: укудан соң дәрес әзерлисе бар, бәрәңге аласы. Язын да шулай ук мәшәкатьнең очы-кырые күренми. Шуңа карамастан без «кыхлы»ны елның һәр көнендә уйнадык. Ләкин шунысы бар: «немесләр» булып беребезнең дә уйныйсы килми. Нишлисең, кемнәрдер булмыйча, уен килеп чыкмый — чиратлашып булабыз.

Шулай бервакыт, язга табан, әти миңа өр-яңа пәлтә алып бирде. Мин шуны киеп «кыхлы» уйнарга чыктым. Элек яз көне авылда кар эрү икенче төрлерәк иде бит ул, хәзерге кебек түгел. Хәзер кар иң элек уртада эреп бетә, аннан соң урам кырыйлары. Ә без үскән заманда, ат-чана таптый-таптый тыгызланган кар уртада кала иде. Җитмәсә бит әле, ул салам, печән чүпләреннән биегәя бара. Менә шулай язның бер көнендә, авыл урамының бер кырыеннан гөрләвек акканда, икенче кырыенда тузан чыгып торганда, без клуб, мәктәп, колхоз идарәсе тирәсендә пыр тузып сугышлы уйныйбыз. Мин «безнекеләр» булып сугышам. «Безнекеләр»не кырып бетерделәр, инде берүзем генә калдым. «Дошман»ның дзотын шартлату өчен бер генә юл бар — анысы да урам уртасындагы ат юлы. Мин шуннан

яңа пәлтә белән шуышам. Торырга ярамый, торсам — аталар, пуля тия, үләм, җиңеләбез. Ә «без» җиңелергә күнекмәгән.

Шул вакыт колхоз идарәсеннән Исмәгыйль абый белән әти килеп чыктылар. (Ул вакытта алар колхоз һәм авыл Советы рәисләре иделәр.) Әти мине күрде дә аңа: «Карале, Исмәгыйль абый, кичә алган пәлтә шуыша», — диде. Китереп тә типте арт якка. Моны күреп торган «дошман»нар алдында мин: «Чур, атарга ярамый!» — дип кычкырдым да клуб нигезендәге тузанлы дзот тишеген гәүдәм белән томаладым. Шуннан торып барлык «нимесләр»не кырып бетердем. «Безнекеләр» җиңде.

Җиңде җиңүен, өйгә кайткач нәрсә булганын үзегез дә сизәсездер инде, хөрмәтле дусларым.

Көчле иде безнең заманнарда патриотик тәрбия. Ә хәзер син шиш шуыштырасың минем кебек малайны «Ватан өчен!».

## Вафирә

*Вафирә Гыйззәтуллина дигәч, минем күз алдыма гастрольдә йөргән тузанлы юллар искә төшә.*

Әле дә хәтеремдә: элекке Апас районына кергән Чүти авылыннан район үзәгенә кайтып килешебез. Инде ничә көннәрдер җиргә бер тамчы яңгыр төшмәгән, юлларны тузан каплаган. Ялгыш берәр машина үтеп китсә, качып калам димә, тузан йотып тончыгачаксың. Ярый әле урамдагысы кайчан да булса тарала, ә автобуста чыдарлык түгел. Автобуска бер көтү халык, без — артистлар төялгән. Вафирә каяндыр марля табып, авыз, борын, колакларын томалап бәйләгән дә күзләрен генә чепелдәтеп бер ярыктан миңа карап бара. Маңгаеннан аккан тиренә кара тузан ябышкан. Күрәм, сизәм, аңлыйм. «Алла каргаганмы әллә бу артист тормышын» дия сыман ул. Юллар Вафирәне әле тагын кайларга илтер, ниләр күрсәтер? Әйе, җырындагы кебек:

Юллар, юллар, авыр булса булсын,
Тик соңгысы гына булмасын!

Тик соңгысы гына булмасын, дигән идең дә... Кукмара юлларындагы һәлакәт искә төшә. Анда да исән калган идең бит югыйсә. Һәлакәтләрдән исән-имин чыккач, без һәрвакыт шаярабыз. Утсыз, сусыз, салкын Балтачның элеккеге «данлыклы» кунакханәсенә кайткач, минем шигырьне кабатларга ярата идең. Ничек әле? Ә-ә, менә болай:

Потомушты су да юк,
Потомушты ут та юк,
Потомушты без бу илнең
Бәхетле балалары!..

Шулай, Вафирә, безгә әле бу илдә бәхетле булып һаман яшәргә туры килә. Синең җырыңдагыча булса, әйбәт булыр иде дә бит.

Минем белән бергә бәхетем туган —
Өлешемә тигән көмешем.
Шул бәхетемне эзләп юлга чыктым,
Шул бәхетемне эзләп килешем.

Ә синең гомер юлда өзелде. Артист тормышы тәгәрмәч өстендә, диләр, тәгәрмәч астында икән шул.

Әле сине уйлап утырам һәм берничә шаян истәлек тә күңелемдә калган.

## Йөзенче тамашачы

Балтач районының Сосна авылындагы иске клубны ул авылдагылар гына түгел, кайбер артистлар да хәтерлиләрдер әле. Тәбәнәк кенә, җиргә сеңгән, ни клуб алды юк, ни сәхнә арты дигәндәй. Тамаша залын урамнан җир белән тигезләнгән бусага гына аерып тора.

Вафирә Гыйззәтуллина белән гастроль юлларыбыз шунда килеп терәлде. Көз җитеп килә — яңгыр да яңгыр, бертуктаусыз ишә дә ишә. Юллар пычрак. Гел явып торгач, халык та клубларга чыгарга куркып тора, ахрысы. Тамашачылар концертка бик аз йөри. Шуңадырмы, Вафирәнең дә кәефе юк. Менә бит әле Сосна халкы да бик күренми, җыелса җыелыр туксан кеше. Вафирә: «Йөзгә тулмасагыз, башламыйм», — ди.

Мин ишек төбендә контрольдә торам, ягъни билет ертучы булып эшлим. Концертны башлар вакыт та җитте. Вафирә һаман үзенекен тукый. «Йөзгә тулмасагыз, башламыйм». Халык белән бер-беребезгә карашып торабыз... Аптыраш. Мин үзем дә шикләнә башладым, нужәли концерт куймас!.. Юк, юри генә кыланадыр. Вафирә андый түгел.

Ачык ишек төбендә байтак борчылып торганда кисәк караңгыдан бер каз килеп чыкты да, курыкмыйча озын муенын эчкә сузып: «Ка-а-ак!» — дип каңгылдап куйды. Мәйтәм: «Никак!»

Халык гөрселдәп көлеп куйды. Вафирә, нәрсә булды дигән сыман, минем янга чыгып, ник көлүебезне сорады. Мин әйтәм: «Менә син концертны йөз кешегә тулмыйча башламыйм дигәч, бер каз килгән. Әгәр казны кешегә чутласаң — ул йөзенче. Башла!»

Вафирә ул көнне гөрләтеп концерт куйды. Тик мин генә чыгыш ясый алмадым. Чөнки халык мин сәхнәгә чыккач, теге казны искә төшерә дә чыдый алмый көлә башлый. Мин дә аларга кушылам.

Бер барып кайтам әле Сосналарга.

Җырым калды.

## Вафирә сөт эчә

Шулай авылларда гастрольләрдә йөрибез. Элегрәк, бер чыгып киткәч, атналар, айлар буе йөрелә иде. Арып, йончып бетәсең. Шулай да авыл кешеләре тарафыннан артистка карата күрсәтелгән хөрмәт безнең «чегәнлек»не онытты ра иде. Хәзер менә уйлап утырам, карале, мәйтәм, ул вакытта халык беркатлырак та булган ич.

Җәйге эссе көннәрнең берсендә Вафирә Гыйззәтуллина иҗат төркеме белән нинди дер авылга килеп төштек. Йә «Белорусь» арбасында, йә машина әрҗәсендә булгандыр инде — тузанга баткан идек. Өс киемнәребезне каккалыйкаккалый клубка кердек. Безне көтеп торучы бик тә кызыксынучан апалар бер-берсенең колагына пышылдашып алдылар. Кем ничек киенгән, сәхнәдә ничек тә, урамда нинди безнең килеш-килбәт?.. Үзләренең безнең янда буталулары безгә уңайсызлык тудырыр дип уйламыйлар да. Аптырагач, Вафирә: «Их, бер туйганчы яңа сауган сыер сөте эчсәң иде!» — дип әйтеп салды. Шунда әлеге апаларның берсе: «Әй, җаным, нигә аны башта ук әйтмисең?» — диде дә чыгып йөгерде, озак та тормый, эмальле чиләк тотып, килеп тә керде. Сөт китергән. Вафирә, өстәлгә күз төшерде дә, башкаларның стакан яки чокыр биргәннәрен көтмичә, чиләкне күтәреп кенә эчәргә тотынды. Эчте дә эчте, йотлыгып, голтылдатып эчте Вафирә. Без авыз суларыбызны ялап утырдык. Шул вакыт теге апа: «Эч, җаным, эч! Бозаудан гына калган иде ул», — диде.

Вафирәнең ике күзе тонды, авызына тулган сөтне пошкырып җибәрде. Күрәсең, Вафирәкәй шушы ук чиләктән сөт эчкән бозауны күз алдына китергәндер.

## Менә бездә шулай инде

«Саз» җыр ансамбленең бик популяр чагы. Ансамбльнең җитәкчесе, атаклы Рәфкать Гомәров якларына — Чирмешән районы авылларына концертлар белән кайттык. Кышның салкын, җитмәсә, буранлы көннәре иде. Беренче концерт — Рәфкатьнең авылы Кара Чишмәдә. Катып, туңып килеп төшүебез булды, безне җылы өйгә алып кереп, чәй эчерергә тотындылар. «Әй, җаныкайларым, канаткайларым, туңгансыздыр инде, әйдә, чәй эчә торыгыз, җылынырсыз», — диделәр. Рәфкать буш өстәлгә карап торды да, калын тавышы белән: «Бездә шул булыр инде...» — дип уфтанып куйды. Башка ризык булмагач, нишлисең инде, чәй эчәбез. Менә берзаман өстәлнең ике башына зур тәлинкәләргә өеп ит чыгардылар. Безне сыйлаучы апалар үзләре дә кабаланалар: «Менә, менә ит тә пешеп өлгерде. Җитешегез, җитешегез! Белмәдек бит, белмәдек бу вакытка килеп җитәсегезне, вакытына өлгертә алмадык, гафу итегез инде!» Итен авыз итәргә өлгермәдек, табак-табак пилмән чыгара башладылар. «Әй, өстәлгә ипи куярга онытканбыз бит», — дип, калын итеп кисеп, өстәл уртасына ап-ак җылы телемнәр өйделәр. Ул да булмады: «Менә бәлеш тә өлгерде», — дип, өстәлгә куярга көчкә урын табып, ике бәлеш чыгарып куйдылар. Татарча сөйләшә белми торган татар малае, биюче Сашка йөрәк өзгеч тавыш белән: «Предупредить надо было», — дип куйды. Бәлеш тә ашыйсы килә, ләкин корсакта урын юк. Ул гына җитмәде, бәлеш ашалып бетәрәк: «Онытканбыз...» — дип, биш ярты аракы утырттылар. Менә сиңа мә! Рәфкать: «Менә бездә шулай инде!» — дип канәгать тавыш белән кикереп куйды.

Ярар, тамак тук, тән җылынды. Хуҗабикә — Рәфкатьнең җиңгәсе: «Мунча да яккан идек, кереп чыкмыйсызмы?» — диде. Рәфкать, шуны гына көткән кебек, миңа: «Әйдә, Алмаз, мунча керәбез, бездә мунчаны шәп ягалар, чыдарсың микән эссесенә, бияләй, бүрекләр киеп керәбез без», — диде. Киттек. Мунчалары алагаем зур. Ләүкәләре биек. Мин керү белән бераз шикләнеп тордым. Менсәм, төшеп җитеп булыр микән. Чишенеп ыргыттык. Рәфкать ишек төбендәге чиләккә куйган чүмечне алып, ташка сибәргә су чамалап торды да ярты чиләк суны җымытып җибәрде. «Иел!» — ди бу. Иелеп байтак торганнан соң мунча ташы: «Пе-е-с!» — итте. Рәфкать: «Бездә шул булыр инде, саран тәре», — дип, мунча ягучы абыйсын сүгеп ташлады. Катып, туңып, җылымса су белән юынып чыктык. Чыксак, безне кунакка дәшәргә Рәфкатьнең туганнары җыелган. «Әйдә безгә дә, сезгә атап ат суйдык». Менә шун-

нан соң көн дә кунак, көн дә сый-хөрмәт. Кичләрен концерт куябыз, әй шәп тә булган иде ул гастрольләрдә. Рәхмәт Чирмешән халкына. Рәфкать инде үзе якты дөньядан китсә дә, аның өчен: «Менә бездә шулай инде!» — дип горурланасы килә.

## Безнең кебек бул, Салават!

Искитмәле зат бит син, Салават! Кайсы яклап тикшерсәң дә, килешмәгән җирең юк бит синең. Менә гәүдәңне генә алыйк. Кеше төсле түгеллегең әллә кайдан күренеп тора. Кеше төсле кешегә бит аңа игътибар бирмисең. Ә сиңа шундук күз төшә. Буең — килбәтсез озын түгел, миниатюрный, тәбәнәк. Йөрешең дә кайбер кешеләрнеке кебек төсле түгел, кая инде ул синең аякларга аларныкы кебек төсле итеп атлау — настоящий кавалерист — атлан да атка — чык та чап далага!

Чәчләр бөдрә. Туктале, дигәндер Ходай, болай ярамый, бар җире дә әйбәт булмасын, хет чәче бөдрә булсын, дигәндер. Ник дисәң, настоящий мужик пеләш булырга тиеш. Кешене хайваннан аерып торган бердәнбер сыйфат ул — пеләшлек. Менә, мәсәлән, мин, Хәмзин абыең. Кем мине хайван белән бутый ала? Кайсы хайванның пеләш булганын күргәнең бар? Хайваннар арасында пеләшләр юк, пеләшләр арасында — хайваннар! Тәндә җон күп булу ул кешенең хайванлыкка якынрак булуын раслый. Хәер, синең дә бу теориягә каршы килерлек компраматларың бар ич. Синең күкрәгең шәрә — җонсыз. Әйтәм ич, синең дә кешенеке төсле җирләрең бар, дип. Ну сөйкемлелекне ишкән дә биргән инде Ходай... Күпме ишкәнен үзе белмәгән, күрәсең. Иманым Камил Кәримов, битеңдә кызлар үпмәгән бер генә күзәнәгең дә калмагандыр инде. Бигрәк тә борыныңны ялады инде хатын кыз халкы. Шуңа күрә кечкенә калган да инде ул синең. Бу яктан мактанырлыгың юк, кәнишне, зато телең яхшы. Синең тел каршында сокланып баш ими булмый. Ләкин Фирзәрнеке кебек үк түгел. Фирзәрнең теле «тегенди-мондый» сүзләргә баерак булып, бизәкләнә төшә, шуңа күрә ул сине узып китә һәм артта калдыра. Фирзәргә мондый алым белән сөйләшү номинациясе буенча беренче урын — акчалата иң зур сумма һәм «алтын тел» чегы бирерләр дип өмет итәм әле мин үзем... Ул аңа чыннан да бик лаек. Ә син, Салават, «көмеш тел» чегы яуларсың. Шамкай исә «бакыр тел» чегы белән генә канәгатьләнер.

Салават, синең айлар буе тоташтан шыгрым заллар тутырып концертлар куеп ятуың да кешечә түгел. Идәннәргә утырып, балконнардан коелып, сәхнәләргә ятып карыйлар бит концертыңны. Театрга ни алдан, ни арттан кереп булмый: этеш-төртеш, сугыш-талаш, елаш-җыртыш. Биш сәдәп белән киләсең —берсе белән кайтып китәсең. Рәзве бу нормально?! Башка җырчыларның концертына кеше төсле киләсең дә кеше төсле кайтып китәсең. Менә, мәсәлән, минекенә. Тамашачы ашыкмый гына килә. Иркенләп чишенә. Этешүче, төртешүче юк. Бераздан соң концерт була микән соң дип шикләнә башлый. Аптырагач залга керә. Иркен. Рәхәт. Теләсә кайсы урынга сайланып килеп утыра. Артына карый. Алдына. Урыннар күп, ятып ала. Өскә карый. Балкон буш. Кеше коелып төшү куркынычы юк. Тагын рәхәт. Концерт булмый, дип әйтмәсәләр ярар иде дип уйлап куя. Отменять итмибез — куябыз. Тамашачыга рәхәт, чөнки ул ял итә. Ул үзен кеше итеп хис итә, чөнки без аны зурлап берүзенә концерт күрсәтәбез. Безнең концерттан кеше үзен бөек итеп тоеп кайтып китә. Сәдәпләре исән. Кара янган җирләре юк... Юк, юк, синең концертларың да кешенеке төсле түгел. Яшәү рәвешең дә. Рәзве кеше төсле яшәсәң, гонщик булыр идең син?! Әллә баш миеңнең ярыш саен селкенеп алуы нормальный хәлме? Анда бит селкетәсең килмәсә дә селкетәләр. «Бах!» арттан берне... Вәт сиңа сотрясение. Соңгы тапкыр «бах» булгач, утыз тугыз яшең тулган көнне юбилей итеп үткәрүеңне дә шул сотрясениедән килеп чыккан әкәмәт дип аңладым. Анысын да бит кеше төсле итеп үткәрә белмисең... Ул өстәл! Ул ризык! Ак балык, сары балык, кызыл! Ул шәраб: агы, сарысы, кызылы, ул икра: агы, карасы, кызылы! Тәлинкә өсте тәлинкә! Кылчык куйсаң да алып китәләр, апельсин төше атылып төшсә дә алыштыралар, ашасаң, ашамадың диләр. Ник бер генә корсак алып килгәнеңә үкенеп утырасың, билләһи. Уң кулда өч пычак, сул кулда өч чәнечке. Кистеңме бер — алып китәләр пычакны, чәнечтеңме бер — алып китәләр чәнечкене. Второйга ит. Ул итнең мускулларын сүтеп, кабат дөрес итеп җыеп, ниндидер тәмләткечкә манып биргәннәр. Чәйгә тәлинкә белән җиде төрле җимеш, җидесенә җиде төрле төш тыгып, берсенә — бал, икенчесенә — ширбәт, өченчесенә — джем, дүртенчесенә — мин аны белмим, бишенчесенә — күргәнем юк, алтынчысына — күгәрчен сөте, җиденчесенә туже белмим — телеңне йоткычлар тамызганнар. Айдар Фәйзрахманов белән өстәлдәге озынча фарфор савыттан, бу нәрсә икән дип, бер сыекча эчтек, сок дип, ул второй ашый торган соус булып чыкты. Күп эчтек, күргән нәрсәмени!.. Юк, юк, синеке кешенеке төсле булмас инде. Син гади кеше төсле яши алмассың. Кабынып күкләрдә җемелдәрсең, артыңнан озын юл калдырырсың. Син атылганда да яңа йолдызлар кабызып калдырырсың. Ә без йолдыз атылган саен теләктә торабыз: Салават та безнең кебек бәхетле булса иде. Амин!

## Соң түгел

Сызгырма, җил чыгарасың, дисеңме? Мин, ичмасам, сызгырып җил чыгарып йөрим, ә синең нәрсә кырганың бар?! Һич югы, минем кебек сызгырып җил чыгара белсәң иде син. Менә болай: ыш-ыш-ыш-ыш яки менә болай: фью, фью, инде болай да барып чыкмаса, дүрт бармак белән: фьют!!! Кулда чыбыркы, авызда беләк буе тәмәке, качып баручы сыер артыннан әнкәсен исенә төшереп сызгырып җибәрәсең... Сыер сез түгел ул, яшьләр, аңлый, кире борыла. Ә сезгә әйттең ни, әйтмәдең ни... Сүгенеп йөри беләсез анысы, ә менә сызгыруга килгәндә... Моның өчен өч көн булса да көтүче кыяфәтенә керергә кирәк. Үпкәли күрмәгез тагын. Инде сызгырырга өйрәнеп карыйк: фью, фью...

Безнең ярты гомер сызгырып үтте, яртысы коммунизм «төзеп». Без сезнең белән коммунизмда яшәргә тиеш кешеләр идек югыйсә. Күрәсең, безне яхшы сызгыртканнар. Үзегез беләсез, безнең кайбер хөкүмәт башлыклары коеп куйган көтүчеләр иде бит. Нинди оста сызгыртырга өйрәттеләр алар. Әйтик, «чирәм җир»не үзләштерү, «Американы куып җитеп узып китү», «эчүчелеккә каршы» сызгырып йөрүләр, «Әфганстандагы» сызгырулар һәм менә «перестройка» сызгырулары. Соңгысында хәтта без генә түгел, кибет киштәләре дә, безнең буш кесәләребез дә сызгыра башлады. Ә сез, яшьләр, һаман сызгыра белмисез. Әйдәгез әле, тагын тырышып карыйк: фью, фью, фью...

Безнең ярты гомер сызгырып үтте, болай барса, калганы да сызгырыр! Кая безнең өметле яшьләребез? Алар хәзер, селәгәй агызып, секс карап яталар. Без яшь чагында хатын-кызны эчке күлмәктән күрсәк тә сокланып туя алмый идек. Ә болар...

Безнең ярты гомер сызгырып үтте, ә яртысы...

Без сызгырып иген игә идек, без сызгырып көйләр көйли идек, без сызгырып утка кердек, сулар кичтек! Ә хәзер сызгырып та тормыйлар, чишендереп китәләр, каласың... сызгырып. Милициясе дә сызгырып кына үтеп китә. Аларга нәрсә, акчаларын арттырдылар, ныграк сызгырталар. Гади халыкны кем генә сызгыртмый: спекулянтлар, кооператорлар, партияләр, хөкүмәт сызгырта.

Шулай, яшьләр, сезгә дә сызгырырга өйрәнергә кирәк!

## Чегән монологы

Абый җаным, бирсәнә кулыңны, багыйм инде, ә? Билләһи, бушлай багам. Чегән дигәч тә, әллә син мине аңламый дисеңме? Мин бит хөкүмәт түгел, халык хәленә керә беләм. Юк, юк, бер тиенең дә кирәкми. Сизәм, кесәң тишек, эчең буш. Менә гадәтем кычытып тора. Берәрсенең уч төбендә тормышын сырлап күрсәтмәсәм, сагыз да чәйни алмыйм. Абый җаным, бир инде уч төбеңне? Әстәгенәм!!! Мондый уч төбе була димени? Үләсең бит, абый җаным! Бүлнискә бар! Шулай канга батып эшлиләрме хәзерге заманда, җүләр! Бер син генә эшләп бетерә торган түгел ул эшне. Татар кешеседер әле. Әйтәм бит... Эшләргә кирәк, эшләмичә ярамый, дисеңме? Ә без?.. Ә без — чегәннәр?! Әйтмә, әйтмә, беләм ни диясеңне. Алай димә инде, абый җаным, рәхәт тормыштан түгел бит инде ул, помада сатып, багып йөрүләр. Бир әле сул кулыңны? Әстәгенәм!!! Тирләп беткән бит монысы. Үзең дә пешеп утырасың. Температураң бар мәллә? Градусың, дим. Нишлисең соң син, абый җаным, бик калтырыйсың? Китәм, китәм. Йә үләрсең.

Килмим, килмим яныңа, матур егет. Кесәңне томалап утырма! Үтеп кенә китәм.

Апа җаным, балаларың бармы? Бир әле уч төбеңне. Бераз акча тамыз, үзем әйтеп бирәм. Менә күренә башлады. Балаларың бар, ләкин... Кемнән?.. Балалар үстерә торган заман түгел, дисеңме? И-и, сез дә шулай дигәч инде. Чегән баласы җен кебек, теләсә ничек үсә, дисеңме? Нигә шулхәтле бала табасыз, дисеңме?

Мужик бит, давай, давай, ди. Менә шул давайдан соң табасың инде. Әнә вокзалда алтысын бер камерага бикләп калдырдым. Нумерын табып качмасалар ярый инде.

Үзегезнең дә чегәннән артык җирегез юк. Ыштансыз йөрсәгез йөрисез, һаман, Аллага шөкер, дисез. Әнә уч төбендәге юлларың да әллә нинди бормалар ясап бетергән, багып булырлык түгел. Нәрсә дисең?.. Өстә бераз!.. Очына чыгарга тырышырмын. Сузма миңа тиеннәреңне, кирәкми. Менә бу юллар бик күп ирләр яныннан үтеп китәләр, ләкин берсе янында да тукталып калмыйлар. Карале, нишләп куасың син мине? Мин бит синең акчаңны талап алмадым, үзең бирдең. Мин сине хөкүмәт кебек алдап, күрәләтә таламыйм. Бирсәң бирәсең, бирмәсәң — юк. Йөз тәңкәңә елыйсың. Әнә нефтеңне суыралар, һаваңны агулыйлар, суыңны пычраталар, иманыңны корыталар. Ә сез эштә кабарып канаган кулларыгызны миннән яшереп, газиз балаларыгызның язмышы өчен куркып утырасыз.

Ә шулай да, абый җаным, апа җаным, учыгыздагы юлларда өмет бар. Анда татар халкының үткәндәге ачы язмышы һәм алдагы шатлыклы көннәре күренеп тора. Киләчәге бәхетле ул халыкның. Ышаныгыз!

## Кемгә кыстыбый?

Сагынырсың социализмны... Бар да җайга салынган кебек иде. Ошатмадык бит. Капитализмга күчтек. Күчтек тә олы юл кырыена чыгып бастык. Апалар кызганыч, милләтебезнең гүзәл затлары... Аларга карап йөрәк әрни... Кыстыбый саталар... Сатылалар...

— Абый җаным, ал инде, пажалысты, ә?! Кап-кайнар кыстыбый! Нуршания, кызым, бар йөгер, әнә Казаннан автобус килә. Гимадиягә махы бирмә! Гел ул гына димәгән монда... Абый җаным, кыстыбыйны машинаңа илтеп биримме? Хатының бигрәкләр чибәр икән!.. Безнең татар хатыннары матур шул. И балаларың, күзләр тимәсен! Тфү, тфү! Абый җаным, ничәне төрим, балалар ул кыстыбыйны бик ярата. Әйе шул, әйе, өйдә пешерсәң, кабып та карамыйлар, ә монда, ә монда шудыралар гына.

Мөҗидә, нәрсә карап каттың шул әрмәнгә? Әнә автобусың килеп туктады, Гимадиягә хәтле илтеп тык кыстыбыеңны берәрсенең авызына! Мөҗидә, дим, Мөҗидә, кая кирегә чабасың, әнә Чаллы автобусы, шунда йөгер! Беренче бул!

Абый җаным, ал инде, пажалысты, ничәне төрим? Бүгенге, бүгенге, әле генә пешереп китерелгән. Ирем ташып тора. Абый җаным, и абый җаным! Юлларыңа ак җәймәләр сиңа, борма саен бәхет көтеп торсын, сикертмә саен шатлыгың артсын, син узган урманнарда сандугачлар сайрап озатып калсын, каршы искән җилләрдән сөенечле хәбәрләр килсен, уңай искәннәре сөйгәнең белән күрештерсен, хатыныңа әйбәт ир телим, балаларың зимагур була күрсен!

Бик майлы, дисеңме? И җаным, гәҗит бар бит, гәҗит нәрсәгә?..

Майлы нәрсә ярамый, дисеңме? Нишләп май булсын, үз парында үз юеше генә ул. Ничәне төрим? Әни пешерә, әйе, әни пешерә! Әти булыша, әйе, әти булыша! Әйе, әйе, сыерыбыз бар. Бар, бар! Җиде сыерыбыз, җитмеш сарыгыбыз бар, абый җаным!

Врачлар кайнар кыстыбый ашарга кушмыйлар, дисеңме? Шулаймыни? Әй, абый җаным, ничекләр кайнар булсын ул иртүк килгән кыстыбыйлар. Суынып беттеләр инде алар күптән. Көне дә суык бит. Врачларга каршы килергә ярамый, врачлар белеп әйтә. Менә мин үзем, менә мин үзем, абый җаным, беркайчан кайнар әйбер ашаганым юк. Кайнардан бит, абый җаным, теге «кысла» авыруы, әйе, әйе, рак авыруы барлыкка килә, ди. Менә мин шул авыруга каршы сарымсак ашыйм. Кыстыбыйга да кушып җибәрәм. Абый җаным, ничәне төрим?

Нуршания, Гимадияне тыгылдырма алдыңа! Нахал! Болай да ике машиналары бар бит инде, трактор алабыз дигәч тә, ул хәтле... Төрт, төрт, төртеп җибәр, кертмә алдыңа!

Салкын кыстыбый түже бик ярамый шул, дисеңме? Ничек инде салкын? Нишләп салкын булсын ди алар? Төреп кенә тотам. Кыстыбыйларым менә дигән. Алсуланып, кызарып пешкәннәр. Салкын кыстыбый сатарга кем дип белдең син мине. Аллам сакласын, гөнаһым юк Ходай каршында. Минем әле оҗмахка керәсем бар. Кешегә салкын кыстыбый сатарга... Тамакка яман шеш үстерергә... Менә, менә төптәнрәк алып бирим әле, җып-җылы. Абый җаным, ничәне төрим?

Мин сиңа абый да түгел бугай, дисеңме? Абый җаным, бездә әйбәт кешегә һәрвакыт абый дип эндәшәләр. Абый җаным, иң өстеңә чүп кунган. Абый җаным, борыныңнан җон чыгып тора, өзеп алыйм әле. Ату ямьсез! Үзең бик матур бит син, абый җаным. Чалбарыңның төймәсен төймәләмәгәнсең, абый җаным, үзем төймәлимме, әллә үзең төймәлисеңме?

Чалбарыңда синең, ай, бер төймә,
Нигә төймәләмисең?..

Абый җаным, биеп тә күрсәтимме? Абый җаным, ал инде кыстыбыемны, ничәне төрим?

Мөҗидә, Мөҗидә, аяк чал, аяк чал Гимадиягә, түгелсен, чукынсын сөте! Бас, бас, кыстыбыена бас!

Абый җаным, ничәне төрим? И абый җаным, безнең мөселман кыстыбый ярата шул. Иртәгә шешәләргә тутырып сөт тә алып киләм әле. Кыстыбыйны безнең якта сөт белән ашыйлар. И тәмлелекләре шуның... И тәмлелекләре шуның... И тәмлелекләре шуның!!! Абый җаным, бармы синең җаның? Ничәне төрим?

Гимадияләрнең сыерлары чирле аларның. Сөтен ала күрмә! Үзләре дә эчмиләр. Монда чыгарып саталар. Кыстыбыйларын да ала күрмә. Камырын да шул сөттән баскан бит инде аның. Аларның сыерларында теге английский психушкалы сыерлар чире бар, ди. Абый җаным, ничәне төрим?

Артыгын көеп киткән, ашказаныма андые ярамый, дисеңме?

Нишләп көйсен инде ул, өстәге берсе генә әләккән, калганнары әле чиле-пешле дә!

Пешмәгән ризыкны ашау куркыныч, дисеңме? Бик беләсең килсә, абый җаным, ризыкны пешереп җиткермәскә кирәк икән, витамины күп сакланып кала. Мин әле кыстыбыйны Әмрикә президентына да тыгып җибәрмәкче булам. Җибәрәм, җибәрәм, әллә син аны кыстыбый ашаган кеше дип беләсеңме? Торалар ди аңа андый кыстыбый пешереп безнең кебек җүләрләр юл кырыенда катып-туңып җил-давылда көне-төне эсседә-челләдә. Бик беләсең килсә, жаныкаем, кыстыбый ашамаган кеше ул — дөньяда иң бәхетсез кеше. Мин шуңа күрә Әмрикә президентын да, ничек әле исеме, Бушны да, юк, юк, кыстыбый бушка түгел, бик бәхетсез кешегә чутлыйм. Абый җаным, ничәне төрим?

Иснәп кенә карале! Исе нинди бит! Исе! Монда тирә-юнь урманнарның шифалы дымы, чәчәкләрнең иң ләззәтле балы сеңгән. Камырын кара, камырын — коймак оныннан, өстәп Ирак күркәсе күкәе сытылган, эче голландский бәрәңгедән, мае — ландыш чәчәкләре генә ашап йөргән үзебезнең сыердан. Сыерыбыз Аргентин токымлы! Үгезебез шведский! Абый җаным, ничәне төрим?

Нуршания, ташла әле шул әрмәнеңне. Автобусның эченә үк кер! Мөҗидә, үткәрмә Гимадияне, үткәрмә, тарт итәгеннән! Җыртылса соң, җыртылсын!

Бәрәңгеле ризык белән генә тамак туймас, дисеңме? Иснәп карале син, иснәп карале! Син бит әле иснәмәдең! Парланып пешкән бозау ите исләре! Их, абый җаным! Иснәле син, иснәле!

Итле кыстыбый булмый, дисеңме? Карале, шаяртырга да ярамый икән тагы! Нишләп кыстыбыйда ит булсын ди инде. Сездә генә ул кыстыбыйны ит белән пешерәләр. Әле ул, жаныкаем, бездә өчпочмакка да итне бик чамалап кына салалар. Гимадияне өчпочмакка ит салган дип уйлыйсыңмы? Шиш сала ул өчпочмакка ит! Тот капчыгыңны! Өчпочмакка ит түгел, кыстыбыена бәрәңге дә салмый әле ул. Абый җаным, ничәне төрим? Төрим инде, ә?

Бер кыстыбый ничә сум тора, дисеңме? Ун сум, абый җаным, ун сум. И-и, абый җаным, ал тизрәк, әнә тагын бер «Жигули» килә.

Нуршания, Мөҗидә, нәрсә күзегезне тондырып һаман шул әрмәнгә карап торасыз? Борын кемдә дә борын инде ул. Әрмән, уйди отсюдово! Абый җаным, ал инде, ничәне төрим? Абый җаным, бөтен гаиләгә берүзем, ирем эчә, эти эчә, әнә ике кызым әрмәнгә карап баккан, тыңламыйлар, бөтен авылга бер җүнле мужик юк. Әрмән, дим, уйди отсюдово, ни глэди на мой девушка!!!

Абый җаным, әйдә вакыт уздырма, ничәне төрим?

Ун тәңкәгә лутчы булка ашыйм, дисеңме? Соң, алай булгач, ни пычагыма башымны катырып торасың!

Пес итәргә туктаган идем, дисеңме? Минме мишәйтлим? Минме юлыңа аркылы төшәм? Бик кирәгең бар иде. Сигәк! Саран! Ун тәңкәсен жәлләгән кешене мин мужикка да санамыйм. Бар, бар, баруыңны бел куак арасына. Урман саргайтучы! Әнә синең кебек ашамас борын эче китүчеләргә бәдрәф җиткереп куйдылар. Машинада утыручы килбәтсез марҗа хатының да түгелдер әле. Йөрисеңдер әле кеше балалары үстереп. Юлларыңда тәгәрмәчеңә кадак кергере! Белдеңме! Пес итәргә туктаган ул... Туктамаска иде...

Әй, кемгә кыстыбый, кемгә кыстыбый!.. Мөҗидә, Нуршания!..

## Төш

Бер төш күрәм: кайсыдыр патша Хуҗа Насретдингә тәхетен биреп торган кебек, миңа да Минтимер Шәймиев бер сәгатькә президент постын тапшырып торган, имеш. Тотындым эшләргә. Путинга шылтыратам: «Татарстан Президенты Хәмзин», — мәйтәм. «Какой-такой Хамзин, почему я не знаю?» — ди бу. «Беләсез, беләсез, — мәйтәм. — «Алмаз-Холдинг» компаниясе — мин бит инде ул. Властька крупный капитал килә!» — мәйтәм. «Ә минем доля?» — ди аңгәмәдәш. «50 гә 50, — мәйтәм, — нефть тә шулай». «Ә безгә нишләргә?» — ди Путин. «Сезнең турыда да уйладым, — мәйтәм. — Чукотканы ун елга Америкага биреп торасыз. Алар анда төзиләр, халык та канәгать булачак, Чукотка чәчәккә күмеләчәк. Русия шул аренда акчасына рәхәтләнеп, берни эшләми ашап ятачак». «Ә ун ел үткәч нишлибез?» — ди бу. «Ун ел үткәч, Камчатканы сатарсыз япунга. Тагын ун ел рәхәтләнеп, кәеф-сафа корып ятыш була. Тегеләр төзиләр, халык канәгать, тамаклары тук». — «Ә аннан соң нишләргә?» — «Аннан соң тагын бер ун елга Сахалинны, Курил утрауларын сатасыз». — «Япунгамы?» — «Япунга. Алар анда җәннәт ясыйлар. Утыз ел рәхәтләнеп яшәдегезме? Халык сезне утыз ел буе Президент итеп тотачак». «Ә сез нишләячәксез?» — ди бу. «Ул утыз ел эчендә инде безнең Татарстан, башка планеталар белән дуслашып, кунакка йөрешәчәк. Мәскәүгә барып та карамаячак безнең татар, татар күрергә тилмерәчәксез, яратмадыгыз бит шул татарны», — мәйтәм. «Ә безгә нишләргә?» — ди Путин. «Ну бит әле сезнең җир күп, — мәйтәм. — Ерак Көнчыгыш бар — анысын кытайларга сатарсыз, Урта Себер, Көнбатыш Себер — беткәнмени Русиядә сатар җир. Әгәр сатар җирегез бетсә, кабат яулап алып сатарсыз, вам не привыкать. Бу вакыт эчендә әллә ниләр булып бетәргә мөмкин: җир тетрәүләр, су басулар — бер

генә империянең дә мәңге яшәгәне юк, сат», — мәйтәм. Тегене тәмам уйга батырдым. «Якут алмазларыннан, алтыннарыннан котылырсың, урларга әйберең калмас. Себер газыннан котылсаң — Чубайстан котылдың дигән сүз. Нефтең булмаса, коррупциягә җай калмый. Маташма ул Мәскәүне туендырып. Аны Лужковка калдыр йә әйт үзенә, сатсын Мәскәүне Израильгә. Болай да инде андагы халыкның яртысы Израильдә яши».

Уйланды Президент, уйланырлык та шул. Башында зур борчу шул аның, болай да какча гәүдәле иде, инде бөтенләй кечерәеп калды. Кара инде син: бер илдә урысы, татары, башкорты, чуашы, чукчасы, якуты, акчалысы, акчасызы, башлысы, башсызы, чукрагы, саңгыравы, сукыры, «мерседес»лысы, «запорожец»лысы, коляскалысы, кайсысы — баш, кайсысы — муен, әтисе кем, әнисе кем — кыскасы, базар-вокзал!

«Ризамы син, — мәйтәм, — мин әйткәнчә яшәргә?» «Риза! — ди Путин. — Ә Минтимер Шәрипович үзе кайда соң?» «Минтимер Шәрипович мондасын монда, ләкин минем хакимлек вакыты бетте, әнә үзе килә», — мәйтәм.

Шул вакыт уянып киттем. «Ах, булмады, — мәйтәм, — Путинны әйбәтрәк яшәргә күндергән идем бит...»

## Мин ничек телгә кердем?

Шулай бервакыт авылга кайттым. Үзебезгә. Студент вакыт. Ялга. Өйгә килеп керүем булды, абый белән җизни: «О-о! Менә Алмаз да кайтты, хәзер мунча керәбез!» — диделәр. Беләм инде мин аларның ничек кергәннәрен. Башка — бүрек, кулга бияләй киеп, икешәр себерке болгап чабыналар. Минем дә сынатасым килми. Сыкранып кына кереп киттем болар артыннан. Сиздермим, чыдарга кирәк. Менә ләүкәгә абый менеп китте. Ташка бер-ике чүмеч су сипкәннән соң, мин идәннән бусагага таба шуыштым. Ухыра-ухыра чабына, малай, абый. Чабына-чабына да тагын су чажылдата ташка. Идәндә ятып колак пешә. Әйе, мәйтәм, абый таза! Әле бит җизни менмәгән!.. Нишләргә? Менә абый ләүкәдән төште дә, өстенә бер чиләк су коеп, өйалдына чыгып китте. Мен әйдә, җизни! Абыйның чабынуы чүп кенә икән. Менә, ичмасам, җизни чабына! Ике себеркене ташка куйды да, бүрек-бияләйләрне киеп өстенә су бөрки башлады. Син нишлисең дип сорагыз! Мин идән ярыгына кереп китәрдәй булдым, аннан салкынча һава килгән кебек. Шуны исним. Куллар белән колакны капладым — пешә. Җизни үзе чабына, үзе су сибә, үзе су сибә, үзе чабына. Әллә юри кылана инде. Алай дисәң, бу хәтле кызуга кыланып булмый ул. Бер биш минутлап ухырганнан соң, җизни, себеркеләрен миңа ташлап: «Мә, чабын!» — диде дә абый янына чыгып ятты. Нишләргә? Чабыну түгел, торып та булмый. Тегеләр сөйләшә: янәсе, мин нишләрмен икән? Сынатырга ярамый. Яткан килеш кенә чүмечне үрелеп алдым да идәндәге чиләктән ташка су бөркеп җибәрдем. Тавышы әйбәт чыкты, эссе дә галәмәт. Кул пешә. Себеркеләрне алдым да стена белән мичне төяргә тотындым. Үзем анда-монда «эх!» дип куям. Тагын су сибәм, тагын стена тукмыйм. Байтак шулай кылангач, тегеләр янына чыгып егылдым. Куа чыккан кызу күт битләрен пешереп алды. Абый: «Молодец, безгә охшагансың, тазалык бар», — диде. Җизни: «Нәселегез шундый, әле җүнләп кызармаган да», — дип өстәп куйды. Абыйның бер җайлы философиясе бар. «Ныгытып чабынгач, сабынлап юынырга кирәкми», — янәсе. Ул шулай итте дә, киенеп чыгып китте. Җизни әле тагын бер мәртәбә чабынып алды, аннан ныгытып юынып, миңа җиңел пар теләп, трусигын гына киеп, калган әйберләрен кочаклап, өйгә шылды. Мин аның артыннан: «Тагын бер-ике мәртәбә чабынасым бар», — дип калдым.

Өйгә чыкканда минем геройлык инде бөтен авылга таралган иде. Чөнки мин мунчада чагында безгә Нурдидә килгән булган, абый белән җизнинең: «Безнеке чабынумыни ул, менә, ичмасам, Алмаз чабына ул», — дигәннәрен авыл буйлап таратып та йөри башлаган.

Абый белән җизни минем хәйләне инде күптән белделәр, ләкин бу хәлнең мәзәге кызык. Миңа шулай тоела.

## Хәбил хикмәтләре

Самарада Хәбил Бикташев исемле бер пәһлеван бар. Гәүдәсе филнеке кадәр, Фән Вәлиәхмәтов аның янында беренче класска кергән укучы кебек кенә. Аның аяк бармаклары да балта белән юнып ясалган сыман, кайберләре уелып та бетмәгән. Атаклы көрәшче җиде ел рәттән Европа чемпионы булып калган кеше.

Менә шуның авылына кунакка кайттык. Мунча якканнар бит инде. Мунчалары безнең кебек вак килькиләр өчен түгел, Хәбилдәй кит, кашалот хәтлеләргә исәпләнгән. Мунча җиһазларының барысы да алагаем зурлыкта. Ләүкәсенә бездәйләрнең буе җитми, су баклары безнең өчен бассейн. Без дә мунча кердек, Хәбил кырыенда бөтерелеп йөрибез. Теге, мин сиңа әйтим, бер чиләк суны вулкан кратерына җибәргән сыман җымпымасынмы!.. Без, дүртәү, кызудан куырылып, өлгермәгән кишер шикелле идәнгә сибелдек. Теге, мин сиңа әйтим, бер кулына — ике, икенчесенә тагын ике миннекне тотып, ләүкәгә менеп басты. Үзе өчен чабыну булгандыр инде ул, ләкин безнең өчен кайнар торнадо котыруы булып тоелды. Чыдадык чыдавын, ләкин байтак чинадык. Хәбил, чабынып туйгач, идәнгә төште,

бер «бассейн»ның суын күтәреп өстенә койды да ял бүлмәсенә чыгып китте. Аның артыннан идән такталары күтәрелеп, без салда йөзеп калдык. Исән калсам, башка керәсем юк аның мунчасына дип үз-үземә сүз бирдем һәм әлегә кадәр сүземнән чыкканым юк. Әмма бакчасындагы бассейнда коенганым булды.

Шулай артистлар белән чупырдатып ятабыз Хәбилләрдә. Бу тик торган җирдән безнең өскә ташланды. Бассейнның суы океанда була торган «прилив»мы шунда, «отлив»мы кебек аркылы чыгып, астагы бакчаның өен агызып китте. Хәбил безне култык астына кыстыргалап уйнады да бассейннан чыгып шылды. Без, әлеге дә баягы килькиләр кебек, төптә калдык. Торып бассак — су тездән. Мәсхәрә булдык кунакта! Кемдә диген? Хәбилдә!

## Хәйлә кирәк

Мунчага төрлечә керелә. Шулай бервакыт филармониядә эшләгән чаклар, концертлар куеп йөрибез. Мин әле администратор да. Концертлардан соң кассадагы акчаны җыеп йөрим. Акчаның байтак тупланган чагы. Мамадышта мунча керәбез. Кунакханәдә бүлмәгә бикләп калдырырга ярамый, андагы администраторга ышаныч юк, шуңа күрә бер букча акча үзебез белән йөри. Егетләр чишенеп мунчага кереп китәләр, ә мин шәрә килеш букча күтәреп йөрим. Парнойга керсәм, анда алып керәм, юынганда янымда тора, кызык инде. Ярый безнең егетләр аңлый, әле бит башкалар да бар — мамадышлылар. Бик сәерсенеп карап торганнары да булды букчага. Төртеп күрсәтә-күрсәтә сөйләшеп тә алгалыйлар. Анысы ярый, менә битне ничек сабынлап юарга? Егетләргә: «Менә хәзер битне сабынлыйм, сез карап торыгыз әле!» — дип киңәшләшергә дә була үзе. Вакланасы килми. Шул вакыт эчендә генә кем алсын инде букчаны дип тә уйлыйсың. Җаваплылык зур шул — хөкүмәт акчасы. Урлатсаң, гомерең җитмәс түләргә. Җаен таптым, башта ярты башны, бер күзне сабынлыйм да юам, аннан икенчесен. Егетләр көләләр: «Без, — диләр, — сабынлап башыңны юганда букчаңны шаяртып урларга исәпләп тора идек, бик хәйләкәр булып чыктың», — диләр.

## Коктейль

Элегрәк вакытлар: аракының да, кабымлыкның да юк чагы. Казан буйлап ни эшләп йөргән чагым булгандыр — Разил Вәлиев очрады. Авылдаш, классташ бит инде. «О-о! Әйдә минем белән», — ди бу. Дипломатын ачып, тугыз ярты күрсәтте. «Кая?» — мәйтәм. «Сәламәтлек» комбинатына. Мунча керәбез. Анда безне язучылар, композиторлар көтеп тора!» Киттек. Миңа бит алар белән утыруы авторитет! Мунчаның бер бүлмәсенә керсәк!.. Унбишләп шәрә даһи утыра. Уңайсыз булып китте. Миннән өлеш юк бит. Разилгә әйтәм: «Кабымлык кына алып керим». «Бар, алай булгач!» — диде бу. Анда чабам, монда чабам, ник бер җирдә булсын сумса яки шуның ише бер нәрсә. Аптырагач, мунча буфетына кереп коктейльгә заказ бирдем — унҗиде стакан. Подноска төяп, бик җитди килеп керәм, Фасил абый Әхмәтов: «Анасын сатты», — диде. Барысы да аңа кушылып ухылдап куйдылар. Разил: «Безнең авыл егетләре шундый!» — дип тәгәлләде.

Сөт дип белделәр. Рәхәтләнеп эчтеләр.

## «Ә теш пастасы?»

Берзаман вак-төяккә кытлык башланды. Теш пастасы бетте. Юк инде менә! Мәскәүдә дә юк.

Ул елларны Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле чит илләргә гастрольләргә йөрергәияләшеп китте. Шуннан файдаланып, баянчы дустыбыз Әхмәт Кәримов ансамбль җырчысы Извил Салиховтан Япониядән теш пастасы алып кайтуын үтенеп сорый. Тегесе вәгъдә бирә.

Менә берзаман череп баеп йөреп кайттылар болар. Кайтуны юып утырабыз, Извил сөйли-мактана:

— Менә, малай, бөтен гаиләгә: балаларга, хатынга, туганнарга өс-баш, спортивкалар апкайттым.

— Син миңа теш пастасы алып кайттыңмы? — дип сорый Әхмәт.

Извил:

— Туктале, Әхмәт, комачаулама әле, сөйләп бетерим. Аннан соң төсле телевизор алып кайттым. Килегез карарга.

— Ә син миңа теш пастасы алып кайттыңмы? — дип кабатлый Әхмәт.

— Туктале, Әхмәт! Менә, егетләр, видео алып кайттым! Килегез, порнуха карарбыз!

Әхмәт һаман үзенекен:

— Нәрсәгә миңа синең порнухаң, син миңа теш пастасы алып кайттыңмы?

Извилне коткарырга кирәк бит инде, алып кайтмаган ул аңа паста, мин әйтәм:

— Япониядә теш чистартмыйлар! Әйдә, егетләр, эчеп куйыйк әле!

## Куабыз, имеш

Әхмәт белән «Комсомолец» клубында бергә эшләгән чаклар. Ул — баянчы, мин — сәнгать җитәкчесе. Әхмәт эшкә йөреп бик куандырмый.

Беркөнне төзелеш трестының (безнең клуб шуныкы иде) профком рәисе, хөрмәтле кеше Геннадий Васильевич Подтопкин:

— Надоело, к черту, уволим, позови его, как появится! — диде.

Әхмәтнең күренүе булды, киттек Подтопкинга.

Геннадий Васильевич җайлап кына сүз башлады:

— Ахмет, нельзя же так, мы тебя уважаем, а ты даже на работе не появляешься.

Әхмәт үзенең сакаурак акценты белән:

— Как, я же работаю, Геннадий Васильевич! Спроси у Алмаза Наиловича!

Менә сиңа мә, мине китереп кыстырды.

Ни дип җавап бирергә белмичә мыгырданып торам:

— Классный баянист, — мәйтәм.

— Насчет классности слов нет, но ведь на работу ходить-то надо, уволим мы тебя, Ахмет!

Гомер күрмәгәнне Әхмәт кызып китте:

— Если, Генка, честно сказать, шиш ты сыграешь на моем баяне, а я на твоем месте запросто смогу работать, здесь за столом сидеть много ума не надо!

— Подожди, Ахмет, причем тут моя работа? Если ты устроился, будь добр, ходи на работу, никто ничего не скажет.

— Я бы тебе, Генка, конечно, сказал бы, здесь уважаемый Алмаз Наилович есть, не буду говорить. Давай увольняй! Я себе работу найду, а вот ты, Генка, вряд ли сможешь найти такое теплое место.

— Ахмет, не горячись!

Аптырагач, Подтопкин өстәл астыннан бер ярты аракы чыгарып куйды.

Әхмәт:

— Вот, с этого надо было начинать, а ты: «Уволю, уволю!»

## «Сәер» концерт

Бервакыт Әхмәт миңа:

— Алмаз, бер үтенечем бар иде, — диде. — Үзең беләсең, мин бит теге Татарстан урамында яши торган бүлмәм өчен домоуправлениедә дворник булып чутланам, менә шуларга синең белән иртәгә 8 Мартка багышланган концерт куясы иде.

— Нинди сүз булырга мөмкин, Әхмәт, билгеле, куябыз. Син дигәндә, мин...

— Ярый алай булгач, килештек, автовокзал артындагы домоуправлениедә сәгать дүрттә очрашырбыз. Пока!

— Пока!

Бераз киткәч, Әхмәт, кире борылып:

— Алмаз, карале, онытканмын әйтергә, иртәнге сәгать дүрткә иде ул.

Мин аптырап калдым, ләкин сер бирмәскә тырыштым:

— Дүрткә тек дүрткә! Пока!

— Пока!

Икенче көнне иртәнге өчтә торып, берәүне дә уятмый гына өйдән чыгып киттем. Бер сәгать җәяү барасы. Төнлә каян булсын транспорт. Барам, барам, үзем уйлыйм, мәйтәм, кем килсен инде иртәнге дүрткә концерт карарга. Урам тып-тын, эт тә юк, мәчеләр генә әллә каян кайтып баралар.

Килеп керүем булды домоуправлениегә, йөзләгән хатын-кыз умарта күче сыман гөжләп куйды. Әхмәт Салих Сәйдәшев маршын уйнап җибәрде, мин «Дарите женщинам цветы»ны җырлыйм. Китте бүләкләүләр. Бер сәгатьләп концерт куйганнан соң, мин, шәһәр транспорты белән өйгә кайтып, тыныч кына хатынның җылы куенына кереп яттым.

Берзаман хатын уята:

— Тор, хөрәсән, син бит Әхмәткә концерт куярга барырга вәгъдә иткән идең...

— Кайттым бит инде, — мәйтәм.

## Не вижүт инде

Яратып, хөрмәт итеп язам, Әхмәт дус, ачуланма!

Һәвәскәр булып җырлап йөргән чаклар. Бер төркем артистлар белән ул вакыттагы Ленинградка — удар комсомол төзелешенә культуралы хезмәт күрсәтергә бардык. Җәй айлары. Кунакханәдә Әхмәт белән бер бүлмәгә урнаштык. Төнгә таба, концерттан соң, мин йокларга яттым, Әхмәт күрше бүлмәдәге кызлар янына кереп китте.

Байтак вакыт узган, ахры, Әхмәт кире бүлмәгә кергән дә мине уята:

— Алмаз, сәгать ничә соң ул?

— Унике, — мәйтәм.

— Минеке дә унике. Тукта, мин тагын әзрәк кереп чыгыйм әле, — диде дә бу яңадан теге кызлар бүлмәсенә китте. Күпме вакыт узгандыр, тагын чыга бу: — Алмаз, сәгать ничә соң?

— Төнге сәгать ике, — мәйтәм.

— Минеке дә ике.

— Нигә караңгы төшми соң ул?

— Монда бит, — мәйтәм, — ак төннәр, җәйнең бу вакытында монда яп-якты була.

— Эх, жизен, блин, не вижүт (не везет), лутчы авылга кайтып, дояркага гына өйләнгән булсам, хатын Герой Соцтруда, миңа заслуженный механизатор бирерләр иде. Парной сөт эчеп ятсам, бу язвылар булмас иде, — диде дә Әхмәт йокларга ятты. — Төне караңгы булса, ичмасам, подружкасы күрмәс иде, ату күзләрен шар ачып карап ята...

Әхмәт дус әле дә өйләнмәгән, югыйсә бездә караңгы төннәр дә күп.

## Минсез уволить иткәннәр

Әхмәт искиткеч оста баянчы. Аның уйнавын атаклы җырчыбыз Таһир Якупов та бик ярата иде. Җәй көннәренең берсендә Әхмәтнең даһи музыкант икәнен «юарга» Таһир, мин, Әхмәт бер мәктәп ишегалдына кердек. Соңгы «бомба» да эчелеп бетте.

Шулчак Әхмәт, капылт кына:

— Карагыз әле, егетләр, мин бу мәктәптә эшлим бит, акча бирмиләр микән? — диде дә мәктәпкә кереп китте.

— Вәт Әхмәт! — дип, без куанып калдык.

Көтәбез, көтәбез Таһир белән, ниһаять, чыкты да:

— Мине күптән увольнять иткәннәр икән инде, — диде.

## Бу язвылар булмас иде

Берзаман Әхмәт шылтырата.

— Алмаз...

— Әйе, әйе, — мәйтәм, — Әхмәт, акча бирәләр.

— Мин акча сорамадым бит әле.

— Ну бит инде, синең акча биргән көнне генә шылтыратуың миңа билгеле.

— Акча язганнармыни? Үз күзләрең белән күрдеңме?

— Язганнар, язганнар, үз күзләрем белән күрдем.

— Алай булгач, мин хәзер килеп җитәм, янәшәдән генә шылтыратам, рәхмәт инде язганнары өчен.

Биш минуттан акчаларын алып Әхмәт килеп тә керә.

— Эх, жизен, блин, шушы сиксән тәңкә өчен эшләп йөр инде, лутчы авылга кайтып, дояркага гына өйләнгән булсам, хатынга Герой Соцтруда, миңа заслуженный механизатор бирерләр иде. Парной сөт эчеп ятсам, бу язвылар булмас иде.

## Концерт

Быел концертларым тыныч кына үтәр әле дигән идем дә, булмады. Башланырга бер ай кала хатынның ахирәте бишенче рәттән ун чакыру билетына заказ биреп куйды. Беләм инде ул ун чакыру арасында минем күз атып йөргән гүзәл җан да бар икәнен. Шиш утыра ул алар белән бергә. Тагын аның өчен җиденче рәттән бер-ике урын әзерләп куймый булмас. Хатын өчен бер урын, дүртенче рәттә, уртадан булсын, балаларга тагын бер-икене. Бабай да әйбәт кеше, аңа да урын кирәк. Этләрен дә алып киләбез дигәннәр иде дә, анысына рөхсәт бирмәдем. Күршеләре киләбез дигәннәр. Хуш, дүртенче рәтне сызып атыйк. Иллешәр сумнан егерме урын. Мең тәңкә Аллаһы әкбәр! Бишенче рәттән тагын ун урын калдымы әле? Ә юк, калмаган икән. Аларын хатынның эшендәге дусларына бирәбез икән. Шулай итеп, бишенче рәт тә тулы. Иллешәр сумнан егерме урын. Тагын минем кесәдән мең тәңкә!

Җиденче рәттә ике урын сөяркәнеке дидемме әле? Әй, онытып та торам, авылдашларны кая утыртырга соң? Ничәү алар? Төп-төгәл унсигез. Әһә, менә шунда сыярлар. Тагын миннән мең тәңкә дигән сүз.

Үткән концерттан соң классташлар бик үпкәләп йөргәннәр иде. Ничәү әле алар? Егермеләп бит. Ягъни мәсәлән, хатыннары, ирләре белән килсәләр, кырыкка тулалар. Беренче белән икенче рәткә утыртыйм әле аларны. Алдан карап, мактанып утырсыннар. Тагын ике мең тәңкә чаж!

Минем өченче рәтем бар бит әле. Ах, шайтан, ә дусларым — артистларга урын кайда? Бәлки, сәхнә артында гына йөрерләр? Юк инде, йә парлашып килерләр, утыртыйм. Өченче рәтне аларга калдырам.

Тукта, минем әле алтынчы рәт бар бит, гастроном директорына хатыны белән, малай-кызның укытучыларына парлап, кошчылык фабрикасы директорына, ателье директорына ире белән... Булды, алтынчы рәт тә тулды. Тагын иллешәр сумнан. Җиденче рәт шыгрым. Сигезенче рәт хатыны белән хирургка, гастроэндокринолог ире белән, вертеброневролог хатыны белән, уролог ире белән, гинеколог хатыны белән, больничный бирүчегә, аптекарьга, лесникка, военкомга, прокурорга, судьяга... Менә сиңа тагын ике рәт очты. Әй, ялгыш таратып утырам икән бит. Сигезенче элитный рәт, начальствога таратыла икән. Әһә, монысы минем кесәдән чыкмый.

Камил Кәримов та бер-ике рәт алып кал әле дигән иде. Унбер белән унике аңа булыр. Шамкай бер-ике рәт сораган иде, унөч-ундүрт аңа булыр.

Ах, онытып торам, хәтер дигән, сукырлар җәмгыятеннән хәйрия исәбенә ике рәт калдырырга куштылар бит. Тагын ике мең минем өстән чыга инде.

Ватан сугышында катнашкан бер-ике ветеран, өч-дүрт әфган, биш-алты чечен сугышы инвалиды килсә нишләтим? Урындык куеп кырыйга утыртырмын инде.

Ай Аллам, үземнең әти белән әнине оныткანмын бит, аларны кая утыртыйм?

Әти кадерлем, әни бәгырем. Егерме мең тәңкә акча биреп торыгыз әле. Концертка килмәсәгез дә ярый.

## ГБ ЧКБ

Сез мине «путч» вакытында нишләп йөрде икән дип уйлый торгансыздыр инде? «Тегеләр» яклы булды микән, әллә...

Яшерен-батырын түгел, мин «тегеләр» килүенә бик «ш» идем. Дөресен генә әйткәндә «тегеләр» килүенә бөтен кеше «ш» иде. Хәзер генә берсе дә «ш» түгел. Хәзер бөтенесе кар-р-р«ш».

Иртән-иртүк радиода музыка да музыка, музыка да музыка... Әһә, мәйтәм, үлгән!.. Әй, тракторны кабыздым да эшкә киттем. Авыл кешесенә нәрсә инде, эш тә эш, эш тә эш... Давай, давай работай, давай, давай работай! Аңа кеше үлсә ни дә, үлмәсә ни... Давай, давай работай, давай, давай... Какой анда кеше кайгысы!..

Төшке ашка кайтып киләм, каршыга Чулак Нәсимә көянтә күтәреп килә. ГКЧП да ГКЧП, ГКЧП да ГКЧП. Үзе ур-ра кычкыра. Үзе һаман ГКЧП да ГКЧП, ГКЧП да ГКЧП. Нәрсә, мәйтәм, Нәсимәтти ГКЧП түгел, ГБ ЧКБ түгелме соң халыкта? Бутыйсың түгелме соң? Гаепкә Бормагыз, Чәй Куеп Булмады түгелме? «Гаепкә борып чәй куеп тораммы соң сиңа», — диде дә чаж минем башка көянтә белән. Хрыс көянтә урталай. Мин баш дип торам. Гәрәй, Самат, Гыйлаҗ урманга качтылар, хәзер синең дә иманыңны укытам диде дә бу Гарифларга кереп китте.

Әһә, мәйтәм, баш яхшы эшли башлады, көянтә белән суккач. Вообще минем баш көянтә белән суккач яхшы эшли башлый.

Искә төште: илле алтынчы елны Җәй суы бозга тыгылып, авылларны баса башлагач, Казаннан самолетлар килеп бозны бомбить иткәннәр иде. Менә шул вакыт Гәрәй, Самат, Гыйлаҗ Җәй буенда балык тотып йөргәннәр. Теге самолетлар акыра-акыра бозны бомбить итә башлагач, сугыш башланды дип белеп, урманга качканнар. Алар гел

шулай итә: бер-бер нәрсә булса, гел урманга качалар. Ватан сугышын да шунда утырып чыкканнар иде. Димәк, бүген дә шунда инде болар.

Шул вакыт Нәсимәтти Гарифлардан түгел, Фәритләрдән көянтә күтәреп чыкты да: «Атаң зafферма вакытта сөткә су кушкан өчен», — диде дә чаж минем башка көянтә белән. Хрыс көянтә урталай. «Син нәрсә, Нәсимәтти, танымыйсыңмы әллә. Авырта бит». Үзе ур-ра кычкыра.

«Безнең заманнар җитте», — диде дә бу Әхмиләргә кереп китте. Көянтәгә что-ли?.. Әхмиләрдән түгел, Хәмитләрдән килеп чыкты. Ындыр артлатып йөри. «Псих, — мәйтәм, — сиңа укол кадарга кирәк». «Ах, мин психмы әле?» — диде дә бу чаж минем башка көянтә белән. Чаж... Сынмый көянтәсе. Алюминий икән. Суырып алдым да бөгәрләп ыргыттым. «Мине дә үзең кебек чулак калдырасың бит, утыныңны, печәнеңне кем алып кайтыр». «Ах, мин чулакмы?» — диде дә бу безгә кереп китте. Ишегалдындагы эткә тибеп, безнең көянтәне алып чыкты да чаж минем башка көянтә белән. Хрыс безнең көянтә урталай. Минем баш бит инде хәзер кормовой чөгендер хәтле булды. Ачу килә башлады. Ах, мәйтәм, син шулаймы әле, дидем дә, авыл башында калган тракторга чаптым. Таптатам. Дөбер-шатыр өйгә кайтканчыга кадәр Нәсимәтти күренмәде. Югары очта персидәтелне кыйный, диделәр. Хәзер көянтәгә авыл Советына кереп киткән.

Өч көннән соң күрдем мин моны. «Нихәл, — мәйтәм, — Путч Нәсимә?» «ГБ ЧКБ», — ди.

Менә шундый хәлләр, менә шундый эшләр, тора бара нишләр?!

ГБ ЧКБ!

## Медаль турында

Исеммени ул мактаулы исемсез исем? Кешемени ул медальсез кеше? Видал, кәҗәдә и то медаль!

Бездә шулай бит: берәү өрергә куша, өрергә кушучының күңеленә хуш килерлек итеп өрсәң, сиңа сөяк ыргыталар, ягъни медаль тагалар. Мәсәлән, минем күрше Гаптерине Әфганга җибәреп, өстереп йөрделәр. Өсә торгач, егет аяксыз кайтты. Монда да өреп йөрмәсен өчен медаль бирделәр. Хәзер всех посылает...

Тагын сөйлимме?

Менә безнең авылның атказанган атаклы халык сыер савучысы Вәлидә унбер баласы өчен унбер медаль, утыз колхоз сыеры өчен ике Социалистик Хезмәт Герое, каенанасы белән «бик дус» торганы өчендер инде Халыклар дуслыгы ордены белән бүләкләнде. Алар бәдрәфкә почет грамотасы белән йөриләр. Медальләре белән бөтен авыл баласы «Брежневны» уйный. Шәпме? Шәп! Мондый бәхетне кем күргән?! Билләһи, дип әйтәм, әгәр дә немецлар безнең илгә тагын бәреп керсәләр, кырык беренче елдагы кебек булмаячак, Вәлидә социалистик илебезне мәсхәрә иттермәс өчен утар киртәсен суырып алачак та иманнарынмы иманнарын кортачак, тегеләр, артларына да борылып карамыйча Германияләрен узып китеп, Франциягә кайтып егылачак. Билләһи, шулай булачак, һәй, егетләр, пләмәнни үгезне сыер өстеннән алып ыргытканны!

Тагын сөйлимме?

Менә сез безнең авыл сәрхуше Шәрифне белмисез. Аның да бер медале бар. Кырык беренче-кырык бишенче елларда илендә күрсәткән батырлыклары өчен ике меңенче елларны бирелгән. Менә хәзер шуны сата. Син, энекәш, шәһәрдә правительство кырыенда күп йөрисең, берәрсен күрсәң, әйт, безнең авылга килгәч, Түбән очка төшеп йөрмәсеннәр, Шәриф абыегыз сезне бу политикагыз өчен әче балыннан бушаган чәйнүге белән бәреп үтерәчәк, диген, ди.

Ә бит теге вакытта, медаль биргәч, шатлыгыннан елаган иде.

Тагын сөйлимме?

Минемчә, медальле кеше буласың килсә, депутат булырга кирәк. Аннан соң бар да җайлана. Башта халыкны яклаган булып акырган-бакырган буласың, шуннан соң синең акыруыңны басар өчен «служебный» машина биреп карыйлар, син бераз акыруыңны киметә төшәсең, шуннан соң сиңа «заслуженный» исемен ыргыталар, син тагын бераз тынасың, синең «коттедж» дигән сүзләрне катыштырып сөйләшеп йөрүеңне көтүләрен үзең дә сизәсең, «туристический» дигән булып, спонсор акчасына чит илләрне әйләнеп кайтасың да, башкаладан бер-ике фатир эләктергәч, гел өстәгеләр яраткан җырларны гына җырлап йөри башлыйсың. Кайвакытта биеп тә күрсәтергә мөмкин. Шуннан соң сиңа тагын бер медаль бирерләр. Бәлки, икене, бәлки, өчне...

Озакламый үзебезнең медальләр булачак. Татарстан медальләре. Кешеләр шуларны алыр өчен көрәшәчәкләр, җаннарын кызганмаячаклар, гомерләрен бирәчәкләр, үләчәкләр, бетәчәкләр. Сандык төпләре медальләр белән тулачак.

Бер минем генә медаль булмаячак. Бәлки, берәрегез медаль табуның башка төрле ысулларын өйрәтер. Ялагайланырга дисезме, өрергә кушасызмы? Юк, җәмәгать, минем өчен иң зур медаль — сезнең алкышларыгыз, хөрмәтле вә гадел тамашачыларым! Рәхмәт сезгә!

## Астан өскә карап

*(Брежневның халыкка мөрәҗәгате)*

Уважаемые товарищи, друзья! Вот я на вас смотрю первый раз снизу. И для себя сделал большое открытие. Оказывается, если на земле живут одни русские, то под землей живут одни татары. И здесь государственным языком является татарский, поэтому я перейду сейчас на общеподземный государственный татарский язык.

Менә мин сезгә астан карап ятам. Без сезнең белән рәхәт яшәдек. Берәү дә моңа сүз әйтмәс. Хәзер дә мин рәхәтләнеп яшәп ятам. Беләм, сезнең анда эшләр хөрти. Беләм, мине зур хөрмәт белән, ихтирам белән искә төшерәсез. Кабат кайтуымны көтәсез. Тик мин кайтып кына ни эшли алырмын икән соң? Менә шундый сорау бирәм мин үзүземә. Союз юк, дәүләт юк, социализм юк, партия юк, эшләүче юк, ашаучы күп. Шәраб заводларын ябып бетергәнсез. Кая минем өч сум алтмыш ике тиенлек «коленвал»? Ә мин, үзегез беләсез, «коленвал»сыз яши алмыйм. Яшереп маташмыйм, бөтен ил белән эчтек. Аракы булмагач, мин анда кайтып тормыйм, кыстамагыз. Кире китәргә туры килсә, юньләп күмә дә белмисез, тегесендә дә дөбердәтеп төшердегез, әле дә бил авыртып тора. Аннан соң тагын бер нәрсәгә хәтер калды: миннән кысып бер медальне Черненкога биргәнсез. Монда килгәч талап алдым. Бирми маташты, нахал.

Горбачевны беләм. Генсек һәм президент буларак ул сезгә күрмәгәнегезне күрсәтте, рәхмәт аңа. Ату минем кадерне белми идегез. Тик аның аркылы да минем сезгә хәтерем калды. Мине президент итмәдегез. Ярый әле мин үпкәчел түгел, миңа «дорогой» дигәне дә җиткән. Соңгы вакытларда мин андый сүзләрне торган саен азрак ишетәм. Күбрәк «анаңны», «денеңне», «кабер ташыңны», «тегеләй-болай итим» дигән сүзләр ишетелә.

На этом спасибо!

Ельцинны белмим. Тише, көлмәгез! Менә монда миңа Лениннар, Сталиннар, Хрущевлар подсказывают, үлгәч белербез инде, диләр. Ельцинның үзенә әйтегез, ГКЧП белән сугышкан булып маташканда, үлгәч өч кеше өчен алган медален ташламасын, вакыты җиткәч, монда алып килеп миңа бирер.

Карагыз әле, ул «путч» булуы дөресме соң? Әллә болай гына сөйлиләрме? Монда бик тонык ишетелә.

Болтун Горбачевка американнарның яхшы яшәве турында халыкка әйтмәскә иде. Зур ялгыш ясады ул бу нәрсәсе белән. Хәер, аның бәләкәй ялгышлары юктыр, мөгаен. Бәләкәй ялгыш ясарга ул сәләтсез кеше. Карагыз әле, аңа әйтегез, килмәсен ул бирегә, монда президентлар юк. Америкага китеп үлсен!

Мин монда күп нәрсәләрне кабат уйлап баштан кичереп ятам. Ниләр эшли микән минем газиз халкым? Талоннары, купоннары җитә микән? Тамагы тук, өсте бөтен микән? Вау... вау... чер... Ваучер... Нәрсә соң ул? Неправильный текст подсунули. Хет берәр кешегә, депутатлардан башка, льгота калды микән? Өй саен президент, президент түгел кеше бар микән? Сорау өстенә сорау. Күңелегез тулса нишлисез? Елыйсызмы? Еламагыз! Йөз грамм җиппәрегез!

Менә шулай, безнең хәлләргә килгәндә, без монда әйбәт кенә яшәп ятабыз. Ленин шул Ленин урынында, Сталин Сталин урынында. Менә Калинин, Ворошилов, Дзержинский, әйеме, Дима Устинов. Әнә Гитлер коймак пешереп йөри. Мае юк.

Безгә бүтән яулардай җир, ирешер биеклекләр калмады. Рәхмәт совет халкына. Ул булмаса, безне болай зур итеп маршаллар, генеральный секретарьлар итеп кем үстерер иде? Яшәсен бөек совет халкы. Ә коммунизмда сез яшәдегез инде, мин аны намус белән вәгъдә иттем һәм үтәдем. Сезгә хәзер бер генә юл калды — безнең янга килергә. Хәер, эшләрегез болай барса, чакырмый да килерсез. Килегез, кил, бергәләп аста коммунизмда яшәвебезне дәвам итәрбез. Ваш дорогой Леонид Ильич!

## Тутый кош

Әллә нигә тиктомалдан котырды бүген артист Кәримнең тутый кошы Катцо. Сәхнәдә дә тузга язмаган сүзләр сөйли башлады. Болай да яратмыйлар бит инде туры сүзе өчен Кәримне. Менә хәзер Катцо шул ялкынга бензин өстәде.

Концерт беткәч, Кәрим кошына шелтәсен иште:

— Катцо, син — җүләр.

— Син үзең жүл-л-ләр-р!

— Мин үземнең шундыйрак икәнемне беләм. Менә син беләсеңме икән?

— Мин жүл-ләр-р түгел! Катцо — ор-рел!

— Катцо, анысы бөтенебез дә орел.

— Катцо — ор-рел! Катцо — ор-рел!

— Йә, ярый, тынычлан! Эч серемне сиңа сөйләми кемгә сөйлим? Бетәбез бит, әкренләп үләбез. Ярый ла син, Катцо, сиксәнгә хәтле яшисең. Безнең бит гомер хәзер илле сигез яшькә генә калды. Ирләрнең, мәйтәм.

— Др-руг — министр-р!

— Булса соң, аннан ни файда?!

— Др-руг — министр-р!

— Әйе, бергә җырлап йөрдек. Шуннан нәрсә булган?

— Сор-ра, сор-ра!

— Нәрсә сора?

— Тор-рак сор-ра!

— Торырга урыныбыз бар бит инде, синең белән санаганда алты кешегә ике бүлмә. Җитми мәллә? Сине кысмыйбыз, кыерсытмыйбыздыр бит?

— Сор-ра! Дур-рак!

— Мыскыл итмә мине җүләр дип. Бармыйм да, сорамыйм да.

— Нагр-рада сор-ра!

— Нәрсә?

— Нагр-рада!

— Ограда дип торам. Күмәргә җыенмыйсыңдыр бит? Билләһи, вакытыннан алда үтерәсең син мине, Катцо. Бирмиләр миңа ул наградыны, бир-ми-ләр.

— Исем сор-ра!

— Нинди исем? Минем бар бит инде әти-әнием кушкан менә дигән исемем — Кәрим.

— Сор-ра!

— Уф, үләм!

— Сор-ра! Др-руг — министр-р! Икр-ра ашыйсым кил-лә-ә! Икр-ра ашыйсым кил-лә-ә!

— Корсакка узмагансыңдыр бит?

— Дур-рак!

— Уф, тукта, Катцо! Аңла, дусны дус итә торган замана түгел хәзер. Ялагайлар басты дөньяны. Туры сүзне бик яратып бетермиләр. Менә син дә бит турыдан ярасың. Кайвакытта үзеңне дә бәреп үтерәсе килә.

— Дур-рак!

— Әйе, дурак, кәнишне. Алтмышка җитеп җүнле фатирсыз, хөрмәткә лаексыз йөр инде...

— Фер-р-р-динандка бир-р-р-деләр-р!..

— Бирделәр, бирделәр. Берсенә «халыкныкы», икенчесенә «атказанган»ны бирделәр.

— Р-рангуловага бир-р-рделәр-р!..

— Әйе, ул чибәр.

— Р-рәлиф кызына бир-р-рделәр-р!

— Әйе, аның этисенең акчасы күп.

— Бар-рон Шакир-ровка бир-р-рделәр-р!

— Барон түгел, Борын Шакировка. Әйе, хатынына да бирделәр.

— Башкор-ртлар-га бир-рәләр-р!..

— Аларга бирәләр. Айдарга, Идрискә...

— Безгә генә бир-р-миләр-р!..

— Елама, кошым, безнең гомер алда әле, Ходай бирсә, миңа унбиш-егерме еллап яшисе бардыр, сиңа утыз-кырык. Әйбәтләп күмәрсең, яме!

— Катцо — ор-рел!

— Орел, орел!

— Др-руг — министр-р!

— Министр, министр. Дуслар күп лә ул. Кирәк чакта таянычың булырдайлары сирәк. Син кирәк чагында гына алар дус. Үзең беләсең, Катцо. Без эшләмәгән кеше түгел бит инде. Синең белән эстрадада утыз өч ел буе халыкка

хезмәт күрсәтәбез. Яратуын яраталар. Күрәсең, мактаулы исемгә лаек булырлык эшләмәгәнбез. Әнә эшләгән кешене күрәләр бит, бәялиләр дә.

— Р-розалигә бир-рделәр-р!..

— Бирделәр, бирделәр. Чибәрләргә бирәләр.

— Депутат булыр-р-рга кир-рәк.

— Комачауламас иде. Ичмасам, үзеңә-үзең файда китерү өчен булса да. Ну баш синдә, Катцо!

— Син дур-рак!

— Җитте! Карале, синең милләттәшең Вано депутат итеп сайланганнан соң Дәүләт Думасында утыра бит!

— Кор-роль!

— Король. Керик янына.

— Юк, кер-р-мим. Ул мине «кар-р-га» дип үр-р-ти.

— Кит аннан, шулай мыскыл итәмени үз кешесен?

— Татар-р-р-лар-р кебек.

— Мин сезне, яһүдләр сыман, бер-берегезне яклыйсыз, күтәрәсез дип уйлаган идем.

— Евр-рей булыр-рга кир-рәк!

— Кирәк тә бит, ә ничек булырга? Ярты эш эшләгән инде анысы — без сөннәттә. Өйрәт, Катцо!

— Евр-р-рейкага өйләнергә кир-рәк!

— Эш узган — мин бит инде алтмышта.

— Җүл-ләр-р!

— Билгеле, җүләр. Инде шул турыда сәгатьләр буенча тукышабыз бит. Җүләрлектән чыгып булмый. Тарихка күз салыйк. Их, 1552 елны җиңелмәгән, их, инкыйлабтан соң Идел-Урал Штаты төзелгән, их, соңгы тапкыр яуланган бәйсезлекне ычкындырмаган булсак! дигән булабыз. Бер кечкенә генә Татарстаныбыз бар. Ил дисәң — ил түгел, дәүләт дисәң — хәтере калыр, «республика» дигән булабыз, «җөмһүрият» — монысы үзебезчә сүз булгач, канәгать калабыз. Сүзе генә бар. Ә менә яһүдләрнең җәннәттәй җирдә аерым бер дәүләте, аннан тагын бер округлары бар, һәм алагаем Җир шары да алар кулында.

— Ол-лигар-рх булырга кирәк!

— Син, Катцо, ни сөйләгәнеңне үзең беләсеңме соң?

— Кәр-рим — җүл-ләр-р!

— Олигарх булмаган кеше җүләр буламыни? Хәер, синең сүздә дөреслек бар бит, кошкаем. Безнең ваучерларны җыеп баедылар ич алар. Чубайсларны әйтәм.

— Ходар-р-ковский...

— Березовский.

— Абр-р-рамович...

— Гусинский...

— Ф-ью-ю!

— Сызгырма! Ник сызгырасың, Катцо? Бик күп икән болар, дисеңме? Күп шул. Ә калганнары нинди кешеләр, дисеңме? Калганнары да гади түгелләр.

— Кил-лер-р-р-лар-р!

— Әллә нинди сүзләр беләсең син, Катцо! Нинди киллерлар булсыннар — алар хәзер «предприниматель» дип аталалар.

— Төр-р-рмә!..

— Тс-с! Катцо! Телеңне кыс, киләләр бугай. Төрмә дигәннән, кемнедер эзлиләр утыртырга. Синең белән мине түгел микән? Чөнки бүген утыртыр кеше юк, башкалар бөтенесе дә «атказанган»нар...

— Кәр-рим — дур-рак!

— Әйе, әйе, дурак.

— Кәр-рим — дур-ракның дур-рагы!

— Әйе, әйе, дуракның дурагы. Ныграк кычкыр! Чыннан да җүләр дип белсеннәр.

— Кәр-рим — дур-рак, дур-р-р-рак!

— Ныграк кычкыр, җүләрләрне төрмәгә утыртмыйлар, ди.

— Катцо — ор-рел-л! Кәр-рим — дур-рак, Кәр-рим — дур-р-р-а-ак!

— Һәм ул шулай да!!!

## Яшәргә кирәк!

*(Моңсу шаяру)*

Фердинанд! Фердинанд, дим! Кара син аны, борылып та карамый бит. Нимес таныгы. Фердинанд, дим! Нәрсәгә шул адашың Фердинанд Сәләхов белән сөйләшеп торасың? Сәхнәгә чыгасың бар бит. Фердинанд! Ферди! Ул бит бүген җырламый. Ну, малай, киемнәре шәп тә инде адашың Сәләховның. Өстендәге бөтен концерт костюмын үзе тегеп кия бит ул. Үзе бәйли, үзе чигә. Әллә бөтен Фердинандлар да шундый инде...

Фердинанд! Әй, чукынчык! Тагын кем белән сөйләшеп торасың анда? Әйдә, сәхнәгә чык! Чык, дим, Ферди! Инде кемне таптың анда? Ә-ә, Камал театрының композитор-җырчысы Фердинанд Хафизов белән сөйләшәсеңмени? Синең дә адашың кебек композитор, артист, бизнесмен буласың киләдер. Әйе, ул бөтенесенә җитешә торган егет. Әллә бөтен Фердинандлар да шундый инде...

Әйттем бит, әйттем, әйдә исемеңне алыштырабыз, дидем. Беткәнмени татарда матур исемнәр: Фәтхуллалар, Фәйзрахманнар... Әле фамилиясе дә кызык бит аның... Фәттрахманов. Әйдә, мәйтәм, үзгәртәбез. «Фәттрахман» дигән исем татарда юк, бары «Фәтхерахман» дигәне бар. Йәбрәй буласың киләме, мәйтәм? «Фәт»ен алып атып, «Т-рахман» калдырабыз. Фердинанд Трахман булып йөрисең. Йәбрәй дип белеп, дәрәҗәң дә үсәр. Юк, тыңламый. Йөр инде менә хәзер алай булгач простой татар — Фәтхи булып.

Эх, Фердинанд! Әле кайчан гына бака суеп, мәчегә операция ясап йөри торган сабый идең бит! Хирург! Кемнәр кушкан сиңа җырчы булырга! Көне-төне җыр өйрәнеп, шигырь ятлап, эшерелеп, салкын клубларда концерт куеп, ачлы-туклы йөрергә. Югыйсә пычагыңны тотып җылы больницаларда өстәлеңә китереп салган капкорсакларның майларын гына кисеп ятасы, байлык җыеп нервысы тузган бизнесменнарның кесә җепләренә скальпель белән генә сызып җибәрәсе. Югыйсә тузган йөрәк клапаннарын гына алыштырып, кемгәдер яңа бөер тыгып, кемнеңдер бүсерен, кемнеңдер гел уылдык кына ашап тыгылган аппендиксын кисеп, башсызларның ярылган башын ямап, киреләрнең кәкрәйгән муенын турайтып кына ятасы. Юк шул, җырлыйсы килә!

Эх, Фердинанд! Укытучы гына булсаң да, бу хәтле интегеп йөрмәс идең. Кара инде, шул булдымы эш! Арендасына түлә, филармониягә түлә, үзеңә зарплата алыр өчен түлә, пенсия өчен түлә! Түлә дә түлә, түлә дә түлә! Менә шуңа күрә дә инде артистлар вакытсыз үлә дә үлә, үлә дә үлә. Югыйсә бит кулыңнан укытучылык килә иде. Хәтерлисеңме, тугызынчы класста укыганда ыштансыз Хәбри малаена папирус алып килмәгәне өчен күпер астында икеле билгесе куйган идең. Прадавис Җәмилә кызы Сәгыйдәгә конфет алып килмәгәне өчен берле чәпәдең. Персидәтел малае Рудольфка син гел бишле куя идең. Магнитофон алып килгәнгәдер инде. Әйе шул, байтак биедек без заманында шул магнитофонга, байтак җырладык. Ул күпер aслары әле дә сагындыра. Әллә шул магнитофон җене тагылып калды микән үзеңә? Җыр укытучысы гына булсаң да бу хәтле җәфаланмас идең диюем. Югыйсә, җылы классларда көненә дүрт-биш сәгать дәресеңне биреп, егерме-егерме биш елдан пенсиягә чыгып, умырып пенсия алсаң, эчеңне төртеп тишәр идемени?.. Югыйсә ун-унбиш елдан «заслуженный», унбиш-егерме елдан «народный учитель», егерме-егерме биш елдан муллалар шикелле правительственный мәҗлес түрләреннән төшмәс кеше бит син, Фердинанд! Эх! Юк шул, җырлыйсың килә!

Югыйсә бомж булсаң гына да фатирлы булган булыр идең. Әнә хәзер аларга да фатир бирәләр. Тузган торак араларыннан эзләп табып, өр-яңа йортларга күчерәләр үзләрен. Ә син һаман үз концертыңа үзең билет сатып йөрисең.

Әле, җитмәсә, артистны гел тикшереп торалар. Өйләнсәң — ник өйләнгән, кемгә, хатыны нинди, сөяркәсе ничәү? Өйләнмәсәң — ни сәбәп? Әллә чамасы юкмы? Соң, артистның да үзенчә хакы бардыр бит!.. Ә синең, чүтеки, җырчы буласың килә.

Сәнгать корбаннар сорый шул. Сорый, ай күп сорый. Рәшит Ваһаповлар, Габдулла Рәхимкуловлар, Хәйдәр Бигичевлар язмышы күз алдында. Илһамнарга карап, Әлфияләрне күреп тетрәнәм. Мәшһүрләр безгә үпкәләп, рәнҗеп китәләр төсле. Китәләр, китәләр... Юк, мин еламыйм. Мин җырлыйм. Җыр авыр хисләрдән арындыра. Киткәннәрнең җырлары аңлашыларак төшә:

Бәхетләрем булмаса да,
Мин бәхетле диеп җырладым...

Ә син һаман җырлыйсым килә, дисең, Фердинанд!

Әйдә җырла! Яшәргә кирәк! Тавышың матур синең...

## Кайда син, Хәмзин?

Кемгә ничек, җәмәгать, безгә гастрольгә чыкканда Хәмзин очраса, юл уңмый. Бервакыт Пермьгә киттек. Ул җәфаланулар: салкын, юеш, ач-ялангач... Килеп төштек. Ни каршы алучы, ни сәлам бирүче юк. Телевизорда балет та балет, скрипка да скрипка. Брежнев үлгән икән. Биш көн яттык, ятмый нишлисең. Күммичә концерт куйдырмыйлар. Ярый, монысы шулай булды.

Күп тә үтмәде, гастрольгә Оренбургка юнәлдек. Качып кына китеп барадырыек, кайлардан шул Хәмзин очрады! Ни калган соң аңа вокзалларда? Ул җәфаланулар: салкын, юеш, ач-ялангач... Ни каршы алучы, ни сәлам бирүче юк. Телевизорда балет та балет, скрипка да скрипка, прәме өзә үзәкне. Ни булырга может бу? Андропов үлгән икән. Биш көн яттык, ятмый нишлисең. Күммичә концерт куйдырмыйлар. Ярый, монысы да шулай булды.

Кайтып бераз хәл алгач, тагын гастрольләргә китәргә йөрибез. Иртәгә китәбез дигән көнне Хәмзин очрады. Бармадык. Ничек барасың инде күрәләтә торып. Китәсе көнне күрәм: Хәмзин телевизорда. Сурәте генә, мәйтәм, бернәрсә дә булмас дип, Чиләбегә ычкындык. Ул җәфаланулар: салкын, юеш, ач-ялангач... Ни каршы алучы, ни сәлам бирүче юк. Телевизорда балет та балет, скрипка да скрипка, телә үзәкне... Әй, мәйтәм, тагын ниләр булды икән инде? Черненко үлгән икән. Биш көн яттык, ятмый нишлисең. Күммичә концерт куйдырмыйлар. Ну бу Хәмзинне!

Беркавымнан Ижауга барырга кирәк булды. Бер көн качып йөрибез, ике көн — юк Хәмзин. Ниһаять, поездга утырыр алдыннан соңгы тапкыр вокзалга морожный алырга керсәк, Хәмзин чыгып килә. Билет алынган, акча түләнгән, гел начар булмас әле. Ул җәфаланулар: ач-ялангач... Килеп төштек. Ни каршы алучы, ни сәлам бирүче... Телевизорда балет та балет, скрипка да скрипка. Чыда гына! ГКЧП икән. Переворот. Өч көн яттык, ятмый нишлисең. Уен эш түгел. Тынычланмыйча концерт куйдырмыйлар.

Соңгы вакытларда очрамый әле Хәмзин. Гастрольләр дә юк. Акча да... Очраса да ярап торыр иде. Түзәр идек әле дүрт-биш көнгә, айлар буе түзәр идек. Шахтерлар шпалларда, рельсларда яталар, ачлыктан укытучылар да, врачлар да, укучылар да егыла...

Әй, Хәмзин, син кайда? Иртәгә Мәскәүгә китәбез — чык әле каршыга, пажалысты, тагын бер шул вокзаллардан. Балетлар карыйсыбыз, скрипкалар тыңлыйсыбыз килә. Ялындырма, ялындырма, Хәмзин! Иртәгә Мәскәү поездына кил, озат әле, пажалысты! Көтәбез, синдә өмет, Хәмзин! Юлыбыз уңмаса уңмас, кил, Хәмзин! Вокзал тәрәзәсеннән генә булса да кара!

## На-а, бахбай!

Тата исемле ат «Сысысыр» дигән утарда озак яшәде. Моны яшәү дисәң, хәтер калыр. Көн-төн эшләтәләр дә тугарып утарга куып кертәләр. Өстәвенә ахырдан бик каты сүгенеп, чыбыркы белән сугып куялар. Бераз утар капкасы төбендә рәнҗеп торганнан соң бүтән атлар янына килеп исәнлек-саулык сорашырга гына хәле кала иде аның. Башко исемле ахиренең дә көннәре шулай үтә. Чыбыркылап, тән-җан җәрәхәтләре әрнүеннән калтырап йөргәннәре күп булды. Бүтәннәргә караганда күбрәк эләгә иде шул аларга. Нефть ташып йөргәндә түзә алмыйча тәртәгә типкәләгән чаклары булмады түгел, булгалады. Күпме ташырга була? Ач карынга күп ташып булмый бит. Икмәген дә ташыдылар, итен дә. Үзең тартып барган ризыгыңны үзең кабып карама әле син! Ачуың килми дә булмас. Мари, Чуа, Яку, Бур һәм башка атлар хәлсезләнеп, кешнәмәс булдылар. Азәр, Әрмә, Үзбә, Латы исемле атларның еш кына дулап алган чаклары күп булды. Хәтта алар үзләренчә кешнәп тә алалар иде. Тата белән Башко кемнәргә дә ярамады. Кешнәсәң дә, Рыс атлары: «Что-за каля-маля?» — дип кенә җибәрәләр. Үзләре эшкә дә чыкмыйлар, әллә нинди ярамаган «су» эчеп, иләсләнеп яталар.

Менә беркөн утардагы барлык атлар җыелышып утар киртәсен тибеп җимерергә булдылар. Рыс атларының теге суны эчкән чаклары: атлар утарның черегән киртәләрен тибеп аудардылар да киң далага чыгып ычкындылар. Тата белән Башко да Идел-Урал киңлекләрендә дөньяларын онытып байтак иркенләделәр. Рәхәт тә соң дилбегәсез, тәртәсез, камытсыз, ыңгырчаксыз йөрүе. Нинди үлән, яфрак чемченәсең килә — рәхәтлән! Үзләренчә кешнәп, үзләренчә пошкырып җәйләре көзгә керде. Карлар явып, кайры кимерергә калды. Тата белән Башкога бүтән утар эзләп озак йөрергә туры килмәде һәм алар «Росси» дигән утарга килеп эләгүләрен сизми дә калдылар. Тагын шул ук камытларын киеп, шул ук тәртәләр арасында тагын да авыррак йөкләр ташыта башладылар. Тик шунысы үзгә: кайбер атлар бу утарга эләкмәгәннәр иде. Алар өчен дә эшләргә кирәк булды. Бераз башак бирә башладылар башлавын, үзләренчә кешнәргә рөхсәт бирделәр, ләкин йөгәнне салдырмадылар. Бәйсез, йөгәнсез, тышаусыз Идел-Урал буйларында йөрүләрен сагындылар алар.

Нигә шулай булды соң әле? Алар иркендә иделәр бит. Ул хатирәләр төштә генә калырлар микәнни? Нигә соң аларның үзләренең утарлары юк? Әллә соң безнекеләр киртә тота белмиләрме? Тәлинкә тота белгәнне, киртә генә

тота белерләр иде югыйсә! Әнә бит «Акыш» дигән утарда атлар менә дигән итеп яши. Эчәренә салкын суы бар, ашарына ашар улагы тулы, кешнәренә кешнәр теле җырлы.

Ә син Тата бәхетсез утарда яшисең. Әле тормышым хәйран дип башың чайкап торасың. Иркенләп чайкар идең дә бит — йөгәнең комачаулый. Әнә Башкога безнеңчә кешнәмисең дип авызлык каптырганнар, ә башкалар элеккечә эндәшмиләр, төш күрәләр, саташалар гына: кая теге киртә җимереп, йөгәнсез йөргән чаклары? Ми-ха-ха-ха! Бәйсезлек, на-а! Хайван!

## Гармун белән сөйләшү

*(Моңсу шаяру)*

Гармуным минем! Ә син бүген үзеңә илле яшь тулганын беләсеңме? Әтием сине миңа биш яшь тулган көнне юбилейга бүләк иткән иде. «Үземә алып бирмәделәр, мә, улым, уйна», — диде. Менә хәзер сиңа илле яшь, миңа илле биш. Үтте гомерләр. Әйдә, билгеләп үтәбезме? Эндәшмисең. Син гомердә эндәшмәдең, моңландың гына. Шул эндәшмәвең белән акыллы булып калдың, ә мин җүләр-лыгырдык Хәмзин, һәрвакыт дөресен сөйләп, «туры әйткән туганына ярамаган» дигәндәй, бернәрсәсез калдым. Болай барса, пенсия дә бирмәсләр. Шул властька «башкалар» килсә генә инде.

Ярый, менә мин сиңа бер нәрсә әйтәм, әйеме, син үпкәләмә! Билгеле, синең Кирам Сатиев кулында уйналасың килгәндер инде, теге заслуженный артистны әйтәм, яки гран-при алган Рөстәм Вәлиев кулында. Ну килеп чыкмады. Болтун Хәмзингә эләктең. Шулай да без үз эшебезне эшләдек. Авыл кешеләре: «Син булганда авылыбыз моңга күмелеп тора иде», — диләр. Иренми идек без синең белән урамнар әйләнергә. Ул сабантуйлар! Ул яшьләр уенында ярыштырып биетүләр. Печән өстендә тургай моңнарына кушылып гармун сайраттырулар! Беренче мәхәббәт! Мин сөйгән кызларны, минем йөрәк сагышларын син генә беләсең, гармуным минем!

Бергә булган кичләр,
Без кичергән хисләр
Хәтерләтә моңсу кояш баешын.
Капка төпләрендә
Тамды күкрәгемә
Ачы күз яшьләрең, калды сагышың.

Әй типтерә идек тә инде яшь чакта ул чарльстон, твистларны.

Джон в Америке родился,
Джон в Америке и рос,
Джон в Америке женился,
Джон в Америке подох.

Армиягә дә бергә киттек. Сынатмадык. Урысларны чәчтереп ыргыта идек җырлап. Тавыш бар!

Путь далек у нас с тобою,
Веселей, солдат, гляди,
Вьется, вьется...

Армиядән кайткач байтак буйдак йөрергә туры килде. Разве синең белән өйләнеп була. Гел кочактан төшмисең бит син. Авылдагы Фәхри кызы Нурдидә: «Гармуныңа гына өйләнерсең инде, карт алаша», — диде.

Әти гармун алып бирсә дә: «Артист булма!» — дигән иде. Булынды шул, минем үземнең дә ният юк иде. Әллә Әлфия Авзалованың кечкенә чагымда башымнан сыйпап китүеме, Илһам Шакировның мин студент чагында әйткән җылы сүземе мине шушы сәхнәләрдә тинтерәтеп йөртә. Гомерем булса, шулар артына басып гармунда уйнармын дигән идем. Бәлки, синең дә хыялың шундый булгандыр. Эх, булмады шул, булмады! Кирам булып, Рөстәм булып, Рамил булып булмады. Сөйгән кызлар күп иде минем. Беләсең син аларны. Казанга килгәч Ранияне дә синең белән саташып йөрүем куркытты, ахрысы, ун ел да йөрмәдек: «Гармуныңа сәлам әйт!» — диде дә кияүгә ычкынды.

Хәзер, Аллага шөкер, өйләндем, балалар да бар. Рания дә күренгәле, хатын да канәгать, син дә. Җырлар язабыз. Әле беркөн авылдан теге үгезләр караучы Нурдидә шылтырата: «Кил син, кил син, үзең кил» дигән җырыңны син кемгә багышлап яздың?» — ди. «Сиңа», — мәйтәм. Җылады да җибәрде. Рания дә сорады: «Кемгә яздың?» — дип. «Сиңа», — дидем. Җылыйлар.

Менә шулай, дустым гармун. Музыканың көче зур аның. Миннән башка сине мактамаслар, мактыйм әле үзеңне һәм «Алмазның халык гармуны» дигән мактаулы исемне туган көнең хөрмәтенә сиңа бирәм. Мәңге яшә, күңелләрне шатландыр, гармуным минем, яшьлек юлдашым!

## Әлү, әлү

*(Телефоннан сөйләшү)*

Әлү, әлү! Карале, Гали Вәлиевич! Гастрольләр оештырасы иде бит! Кемнәр килә, дисезме? Әлфия Авзалова, Гали Вәлиевич, Әлфия Авзалова! Әйе, әйе, саубуллашу концертлары... Моңа хәтле ике мәртәбә саубуллашты бит инде, дисезме? Кирәкми, ату неудобно гел саубуллашып торырга, дисезме? Ә сез саубуллашмагыз, гел исәнләшеп торыгыз! Постоянно исәнләшеп торырга акчам юк, дисезме? Алай димәгез инде, Гали Вәлиевич, без бит күп сорамыйбыз, итләтә генә түләрсез! Ничә сыер суярга кирәк, дисезме? Ике генә, Гали Вәлиевич. Карале, карт сыерлар булмасын!

Тфү, кара инде син аны, трубканы куйды бит. Вәт хайван! Кабат җыймый булмас номерын.

Әлү, әлү, районмы бу? Ә, Гали Вәлиевич, сезмени? Аңлап бетереп булмады, сыер суясызмы инде, әллә акча табасызмы? Юк, йомырка кирәкми, күкәй кирәкми, дим. Әле итнең дә мәшәкате күп. Кибеткә куеп кайчан акчага әйләнә әле ул. Короче, иткә! Бугазга басмагыз инде, дисезме? Юк, бугазы, башы, аягы, тоягы кирәкми. Чиста итләтә генә, ямегез. Әлү, әлү. Тфү! Тагын телефонны ыргытты.

Әлү, әлү! Гали Вәлиевич! Кем әле бу телефонга килеп керде, тавышың бик таныш, ә-ә, Гайфулламыни? Гайфулла Авзалов! Нишләп син Гали Вәлиевичкә шылтыратасың? Концерт куярга кирәк идемени? Ну, ничек соң, ризамы?

Килмә, килмә, йөремә,
Күземә дә күренмә, —

дип җырлый, дисеңме?

Слушай, акча юк бит колхозларда. Сез нәрсәгә куясыз? Чүпрәгә, дисеңме? Карале, шәп бит, ә! Бик болтать итеп йөрмә бу идеяңне, әйтә күрмә берәүгә дә, дим. Гайфулла, куй әле беразга телефоныңны, сөйләшеп бетерим әле Гали Вәлиевич белән.

Әлү, әлү, Гали Вәлиевич! Ит урынына чүпрә булса да ярый. Бездә чүпрә ясамыйлар, дисезме? Анысы минем эш түгел инде аның, Гали Вәлиевич! Табып алыштырыгыз күрше район белән.

Слушай, может килмәссез, дисезме? Ничек инде, Гали Вәлиевич, киләбез, киләбез. Халык теге вакытта да бик ошатып калды. Ходай кабат очрашырга насыйп итсен дип саубуллаштык бит. Халыкта акча юк бит, дисезме? Концерт алдыннан гына бераз бирегез инде халыкка акча! Менә бит, менә бит, Гали Вәлиевич, получается бит, Гали Вәлиевич!

Концертка барыр өчен генә акча биргәнне белсә, Президент, билләһи, урыннан очыра, дисезме? Курыкмагыз, Гали Вәлиевич, без хушлашу кичәләре оештырырга оста, менә диган итеп озатырбыз. Әлү, әлү, Гали Вәлиевич, ашыкмагыз әле.

Гали Вәлиевич, Гали Вәлиевич! Район, район... Карагыз әле, кызлар! Гали Вәлиевичне, районны бирегез әле! Гали Вәлиевич, сезме? Җырлап утырасызмыни? Зөһрәгә, дисезме? Шәрифуллинагамы? Нинди җыр?

Уңга карасам да юк,
Сулга карасам да юк,
Уңга карап, сулга карап
Утырып еласам да юк...

Юк шул, брат, юк, утырып еласаң да, акча юк. Зөһрә, дуслык хакына бушка да риза, ди. Бәлки, сез дә шулай итәрсез, дисезме? Дусын бик дус та бит без сезнең белән, Гали Вәлиевич, ну ачтан үлеп китәргә можем. Яртылаш булмыймы соң? Слушай, яртылаш дигәннән, белми дә торам, сездә аракы заводы бар түгелме соң? Аракыга куйыйк алайса. Мужыт яртысын чүпрәгә, яртысын шикәргә куярсыз, дисезме? Алай итмәгез инде, Гали Вәлиевич. Миңа бит аннан соң берәр районда концертларны самогон аппаратына куеп йөрергә туры киләчәк.

Әлү, әлү, Гали Вәлиевич! Мин Гали Вәлиевич түгел, Асаф Вәлиев, дисеңме? Карале, Асаф, син нишләп линиягә килеп кердең соң әле? Гали Вәлиевичкә шылтыратам, дисеңме? Асаф, дим, Асаф, син концертларны нәрсәгә куеп йөрисең, сер булмаса, әйт әле? Кызларга куеп йөрим, дисеңме? Да, брат, синең эшләр җайлы, син өйләнмәгән. Ә, кызларга түгел, казларга, дисеңмени? Асаф, дим, Асаф, куй әле трубкаңны, Гали Вәлиевич белән сөйләшеп бетерим.

Гали Вәлиевич, Гали Вәлиевич! Үтермәгез инде! Нәрсә, нәрсә, кем дисез? Хәмдүнәме? Ул да сезгә шылтыратамыни? Ә ул нәрсә сорый? Хәл-әхвәлләр сорый. Сезнекенме? Тапкан сорар нәрсә...

Әлү, әлү, Гали Вәлиевич! Хайван булмас идең. Әлү, әлү, Гали Вәлиевич! Өзелде бит. Карале, хәл-әхвәлең күпме тора соң синең? Унбиш концерт, дисеңме? Акчагамы? Әйе, акчага, дисеңме?

Әлү, әлү, вәт чурт. Телефонны ташлады. Гали Вәлиевич, хәлең ничек, хатының әйбәтме?

## Музей

Һич кенә искә төшерә алмыйм: нишләп мин музейда ятам соң әле? Нишләп йөри монда Хәмдүнә? Нишләп мин борынгы болгар сугышчысы ләхетендә? Нишләп мине мәктәп балалары сырып алган? Чалбарым кая? Хет трусик булсын иде, анысы да юк — сыңар яфрак ябып куйганнар.

Хәмдүнә кисәк кенә иелде дә колакка: «Селкенмә, мышнама, тик кенә ят, сиңа да, миңа да эш таптык», — дип пышылдады. Искә төште: әйе шул, без бит аның белән кичә, берәр эш юк микән дип, музейга кергән идек. Директоры танышыбыз Илһам Шакиров булып чыкты. Ул да, тамак хакына булса да дип, музейга директор булып урнашкан икән. Шул очракны «юган» идек бит.

Шулчак Хәмдүнә экскурсовод тавышы белән миңа карап шаккаткан мәктәп укучыларына аңлатма бирә башлады.

— Менә монда, хөрмәтле укучылар, Татарстанның атаклы сүз остасы Алмаз Хәмзин экспонатын күрәсез. Бу — оригинал. Бик яхшы сакланган экспонат. Кадерле укучылар, хәзер экспонатларны саклау технологиясе зур үсеш алды. Элекке заманда аларны спиртка салып саклаган булсалар, хәзер спиртны үзләренә салып, ягъни мәсәлән, эчкә салып сакларга мөмкин булуын ачыкладылар. Менә шул процедуралардан соң ул ятты да катты.

Хөрмәтле укучылар, сез Алмаз Хәмзиннең баш өлешенә игътибар итегез. Сез аның пәхмилдән, әй… тормыш михнәтләреннән тоныкланган ике күзен, теләсә кая тыкшынып йөргән борынын, авыз тартмасына бикләп тотып булмас телен күрәсез.

Алмаз Хәмзин нечкә күңелле, хәтта эчәргә кыстаганда да каршы килә алмас җан иде, әмма эрудит, әйе, кабатлап әйтәм, эрудит, җирбит түгел. Моны исбатлап бер мисал китерәм. Халкыбызның атаклы җырчысы Хәмдүнә Тимергалиеваны беләсездер инде, хөрмәтле укучылар. Ул менә шул җырчы хакында: «Аның белән бергә эшләргә язмасын, үтүк белән сугып баш ярылып үлгәнче үз үлемем белән үләм», — дигән. Менә ул теләгенә иреште. Хайван!

Хәмдүнәнең трусик урынына каплаган яфрагыма басуы булды, мин авыртудан акырып җырлап җибәрдем:

Авызыма ирис каптым,
Пахмил исе бетсен дип.
Авырттырып ник басасың,
Телисеңдер үлсен дип.

Хәмдүнә яңадан «кнопка»ма басты, янәмәсе, мине өзде. Мин авыртудан селкенә алмыйча тагын байтак яттым. Җитмәсә, теге укучы балалар кабат әйләнеп килеп «кнопка»ма басып интектерделәр. Еладым да җырладым, еладым да җырладым, еладым да җырладым. Акча кирәк шул.

Укучылар, иртәгә бөтен мәктәп белән киләбез, дип китеп бардылар.

Эш көне тәмамланып музейны бикләүләре булды, сикереп торып, акча санап утыручы Хәмдүнәгә барып ябыштым:

— Син нәрсә, — мәйтәм, — миннән көләсең?

— Мин бернәрсә дә түгел, — ди бу. — Акча кирәкми мәллә?

— Кирәк, — мәйтәм.

— Ал, алай булгач! Тик иртәгә чалбарың эченнән трусик киеп кил. Чишенеп яткансың, ә трусик юк икәнлеген белмәгәнсең. Син нәрсә, вообще трусик киеп йөрмисең әллә? Музей ачылыр алдыннан ярый әле күреп яфрак каплап куйдык. Ә миңа экскурсовод булмый җай калмады. Килмәс иде бәхет, бәхетсезлек коткарды. Мә үз өлешеңне. Ике йөз сум җитәме? Трусик алырсың!

Илһам Шакиров шундук, стенада эленеп торган Екатерина Втораяның Казан губернаторы биргән мактау грамотасын тартып алып, минем исемгә төзәтеп бирде. Сорап та тормыйча хезмәт кенәгәсенә музей пичәтен чәпеп: «Иртәгә иртәнге сәгать сигезгә килеп җиткән бул, — дип өстәп куйды. — Кара аны, соңга калсаң, уволю, йөрерсең аннан соң зоопаркта Рәшит Сабиров кебек ак аю булып эшләп. Шәрәфи кебек — жираф, Фән Вәлиәхмәтов кебек — фил, Шамкай кебек бегемот булып. Менә иртәгә, безнең бүгенге уңышны ишетеп, мәдәният министры, үзем киләм, дип шылтыратты. Шулай ук чишенеп ятарсың. Түлке арт ягың белән әйләнеп ят, ягъни «включателе»ң белән аска. Бүген дә акыра-акыра туйдырып бетердең, тавышың бигрәк әшәке».

Икенче көнне нәкъ сәгать сигездә чишенеп йөзтүбән ләхетемә кереп яттым. Менә ишектән сыпылып бала-чаганың минем янга йөгергәнен ишетәм.

Хәмдүнә лекциясен укырга тотынды:

— Хөрмәтле укучылар! Сезнең каршыда атаклы сүз остасы Алмаз Хәмзин экспонаты үзенең арт ягы белән бирелә. Ни өчен ул бүген шулай тәкъдим ителәме? Чөнки җәмгыятебез кешегә арт ягы белән борылганда нишләп соң әле ул гына аңа алды белән торырга тиеш ди? Бу, җәмәгать, символик поза! Син безгә ничек, без дә сиңа шулай.

Шул вакыт балалар минем «включатель»не эзләп шаулаша башладылар.

— Апа, апа, экспонат Алмаз Хәмзинне җырлатып күрсәтегез әле. Апа, апа, «включателе»нә басыгыз әле!

— Юк, — диде Хәмдүнә, — кичә дә сез аның «включателе» белән бик күп уйнагансыз, бүген инде менә эшләмәми, ватмансыз!

Молодец, Хәмдүнә. Болай да минем «включатель»нең эшләмәгәнлеген каян белде икән?..

Ниһаять, министр килгәнлеген абайлап алдым. Чөнки балалар бераз гына тына төште. Хәмдүнә дә, аның килүен сиздереп: «Исәнмесез, Илнур Хөснетдинович», — дип куйды. Нишләп, мәйтәм, бутый инде, безнең министрның исеме алай түгел бит.

— Менә, Илнур Хөснетдинович, сезнең каршыда атаклы сүз остасы Алмаз Хәмзин.

— Нихәл, Хәмдүнә, син хәзер монда эшлисеңмени?

— Хәерчелек, иптәш министр, акча җитми. Подрабатываю.

— Ә бу монда нишләп ята? Үлгән идемени? Сизми калганмын инде алай булгач.

— Өченче көн үлде, иптәш министр, сразы монда апкилдек, чөнки кумәр кешесе юк. Аннан соң музейга да кеше бик йөрми башлаган иде бит, менә хәзер, Аллага шөкер, бүгенгә билетлар сатылып беткән, иртәге өчен алалар, барысының да живой экспонат күрәсе килә.

— Чурт с ним, — диде Илнур. — Җүнле кеше түгел иде. Бик әшәке кеше иде. Ярый инде үз үлеме белән киткән, а то могли бы үзебез дә оештырырга.

— Эчәкләре алынганмы соң? — дип сорый бу Хәмдүнәдән.

— Баш мие алынган, — дип, Хәмдүнә аквариумдагы агарып үлгән су ташбакасына күрсәтте.

— Ну, малай, әшәке кеше булган икән бу, — диде Илнур, шул ук аквариумдагы бавырга охшаган таш өстендә суалчан шуышып barганын күргәч. — Чыгарып атыгыз, яткырмагыз монда!

— Башка җүнле артист юк бит, Илнур абый, менә үзем урнашыр идем дә аның урынына экспонат булып, экскурсовод кем булыр?

— Табарбыз, үл генә!

Хәмдүнә Илнурны күтәреп минем өскә бәрде.

Мин авыртудан акырып җырлап җибәрдем:

Авызыма ирис каптым,<br>Пахмил исе бетсен дип…

Балалар гөрләшеп кул чаба башладылар: «Включателе» включился, «включателе» включился!»

Ярый әле балалар шатлана. Ходай аларны шатлыктан аермасын!

Ул көнне дә без Хәмдүнә белән акчаны күп эшләдек. Музей директоры Илһам Шакиров көнләшүенә чыдый алмыйча төне буе эчте. Без иртәгә музейда очрашу нияте белән таралыштык.

Сызылып таңнар атты. Музей каршында меңләгән кеше кертүләрен көтә. Хәмдүнә белән служебный входтан эчкә үттек. Ишектәге кыңгырау шалтырауга, музейга халык тула башлады. Мин чишенеп үз урыныма йөгердем. Кичәге килешү буенча бу юлы кырын ятарга кирәк иде. Карасам, минем урында шыр ялангач килеш Шакир ята. Чумдым моның янына. Безнең янга килеп баскан Хәмдүнә сүзен башлый алмый тотлыгып торды.

— Хөр-хөр-хөр-хөрмәтле тамашачылар! Сез бүгенге экспозициядә яңа экспозицияләр, әй, экспонатлар күрәсез. Бу экспозицияне без «Татар артистларының бүгенге хәле» дип атадык. Ни өчен алар шәрәме? Шәрә булмыйча ничек булсын, акчалары булмагач. Сез инде атаклы сүз остасы Алмаз Хәмзиннең экспонатын күреп беләсез. Әйтегез әле, кайсыгыз танып белә бу экспозициядә урнаштырылган икенче экспонатны? Әйе шул, берегез дә белмисез. Сез Майкл Джексонны, Филипп Киркоровны, Леонид Якубовичны беләсез, ә аны белмисез. Без аны шуның өчен музейга куйдык та. Белсеннәр, күрсеннәр өчен. Бу, хөрмәтле паситителләр, «Зәлидә» телепрограммасын алып баручы Җәвит Шакиров түгел, ә мәшһүр җырчы Илһам Шакиров экспонаты!

Шул вакыт укучылар Шакирның «включателе»н эзли башладылар: «Апа, апа, җырлатып карыйк әле, җырлатып карыйк әле!»

Йа Алла, нәрсә булып бетә бу? Бүген түзсәм, иртәгә килмәс идем.

Хәмдүнә коткарды:

— Хөрмәтле укучылар! Шакир экспонатына «включатель» куелмаган әле, правадалары гына чыгып тора, иртәгә килегез, решим вопрос.

«Музейга депутатлар килде» дигән хәбәр таралды. Шул гына җитмәгән иде. Хәмдүнә тиз генә тәрәзә пәрдәсен тартып төшереп безнең өскә ябып куйды.

— Исәнмесез, Илнур Хөснетдинович! Килдегезме тагын?

— Әйе, менә депутатлар белән артистлар тормышын өйрәнергә килдек. Ник дисәң, беркадәр без дә артистлар бит.

— Бүген артистлар экспозициясе беразга ремонтка ябылды бит әле, Илнур абый, «включатель»ләре эшләми. Бераз спонсорлык кирәк иде, булышмассыз микән?

— Кашаповлардан сорагыз! Татар артисты дигәндә, алар үзләре үләргә әзер.

Ниһаять, музей ябылырга звонок шалтырады. Тәрәзә пәрдәсе астыннан чыгып Шакир белән төртешеп алдык. Мин әйтәм, син нәрсә кеше урынына кереп ятасың? Әнә мыек ябыштыр да сугыш бүлегенә кереп Гитлер булып ят!

Акчаны бүлештек тә өйләргә таралыштык. Икенче көнне инде без төрле экспозицияләрдә эшли идек. Минем янда халык аз булды. Барысы да сугыш бүлегендә Шакирның Гитлер булып торуына сокланалар иде. Ә мин әле бу вакытта Әлфия Афзалованың Екатерина Вторая арбасында Әби патша булып утыруын ишетмәгән идем. Ул көнне Хәмдүнәкәй, хәлдән таеп, Казан ханлыгы чоры экспозициясенә кереп Сөембикә булып егылган. Җәмәгать, әллә миңа хәзер Иван Грозный булырга микән?

Бирегез киңәш, бүген артист нишләргә тиеш?

## Ур-ра кычкырып

Әй, балалар, башлар каткан инде, нәрсә уйларга да белгән юк. Уйлап та карадык, эшләп тә, тешләп тә. Бу дөньяда безгә җүнләп яшәргә язмагандыр инде. Әйбәт кенә, тыныч кына яшәп ятканда нәрсә булса да ишеп төшерәләр башка. Йөз дә бишкә ник җиткәнеңә үкенеп яшисең, билләһи.

Яшь гомеркәйләремнең чәчәктәй вакытында революция чыкты. Сорап та тормыйча мине бер большевикка кияүгә бирделәр. Мамадыш янында аклар белән сугышканда, ур-ра кычкырып үлде. Ике бала белән өчәүләп акырып елап калдык. Шуннан соң, әйбәт кенә яшәп ятканда, колхоз төзи башладылар. Бер коммунистка кияүгә чыктым, өч көннән соң ур-ра кычкырып йөри торган җиреннән юкка чыкты. Кулаклар урманда агачка асып киткәннәр. Өч бала белән дүртәүләп акырып елап калдык. Шуннан, әйбәт кенә яшәп ятканда, ике балалы бер председательгә кияүгә чыгып, дүрт көн үткәч, моны да «халык дошманы» диеп, ур-ра кычкырып йөри торган җиреннән алып киттеләр. Әле хәзер дә кайларда башы югалганын әйтүче юк. Биш бала белән алтаулап акырып елап калдык. Тагын шуннан, әйбәт кенә яшәп ятканда, хатыны үлгән ике балалы бер иргә кияүгә чыккач, нимес белән сугыш башланды. Мескенкәемнең, ур-ра кычкырып атакага барган чагында, авызына пуля кереп, җан тәслим кылган. Җиде бала белән сигезәүләп акырып елап калдык.

Менә шулай гомерләр үтте. Җиде бала үстереп бирдем туган илгә. Сигезәүләп, ур-ра кычкырып, коммунизм төзедек.

Беренче балам, чирәм җирләргә китеп, тракторга кысылып, ур-ра кычкырып үлде. Икенче балам, җир тетрәгәч, Ашхабадка китеп, ур-ра кычкырып, басылып үлде. Өченчесе Днепрогэс төзешергә китте. Суларга батып үләсен белсәм, җибәрмәгән булыр идем. Ур-ра кычкырып, субай сугып, бетте безнең татар башлары. Дүртенчесенең гомерләрен шахта күмерләре алды. Бишенчесе утызын да тутыра алмады, бер гаепсезгә төрмәләрдә черетteләр газиз башкаен. Алтынчымның язмышы үземнекенә охшаса да охшар икән: бер дә кияүдән уңа алмый. Эчәләр бит ирләр, эчәләр, ур-ра кычкырып эчәләр. Малае Әфганда югалды. Җиденчемнеке — Чечняда, әле исән, ди, ур-ралар кычкырмады микәнни?..

Әй заманалар! Тагынниләр күрсәтер бу дөнья? Пенсияләр бирү дә бетәр микән инде? Сберкнижкедәге акчалар да ур-ра кычкырып янды. Их, ур-ралар кычкырып үләр идем, үлемтеккә акча җитмәс дип куркам.

...Әй, онытып торам икән бит. Безнең авыл Бушлыкта яңалыклар булды бит әле. Гомер буе тыныч кына яшәгән авылның дүрт урамы кисешкән чатка, ур-ра кычкырып, светофор куйдылар. Район буенча светофор кую планы үтәлсен өчен куйдылар микән инде аны, әллә берәр нәчәлниккә медаль кирәк булды микән? Әй, нәрсәгә соң әле монысына катышып торам. Куйган көннең шул мизгелендә үк бер кәҗә тәкәсен бәреп үтерделәр. Кызыл утка аркылы чыгып барганда, яшел ут белән килүче пионерлагерь нәчәлниге машинасы белән сытып киткән. Шул ук көнне шул урында өч песинең, биш этнең башына җиттеләр. Ике кеше чатан калды, бер сәпит янчелде, бер «К-700» бетон баганага бәрелеп, мәңге кабынмаслык хәлгә килеп, гомерлек һәйкәл булды. Шул бәрелүләрдән светофорга бик якын торган мәчетнең манарасы яңадан кыйшайды. Җен Фатыйх бер төн эчендә йортын элекке урыныннан илле метрга эчкәрәк күчереп салды. Авыл халкы хафага төште. Киңәштеләр дә килештеләр: светофорга тимәскә, чөнки өстәгеләрнең ачуы кабарырга мөмкин, ә шулай да аның бер генә төсен, кызыл төсен генә калдырырга булдылар. Һәм шулай иттеләр дә.

Тимерче Бәдертдиннең кадими заманыннан калган кувалдасын апкилеп светофорның тимер баганасын төяргә тотындылар. Башта светофор бөтенләй сүнде, тагын бераз кыйный торгач, сарысы кабынды, аннан яшел, баганада, шактый яньчелгәч, бер кызыл ут калды.

Шул ук көнне багана төбендә колхозның Алмаз исемле пләмәнни үгезен таптап киттеләр. Светофор төбендәге кибеткә комбайнерлар комбайннары белән килгәндә кызыл утлы светофорны сөзеп маташкан чагы булган, үзе пычакка килеп керде, диделәр, ур-ра кычкырып.

Шул ук көнне Шәмдәлче авылыннан килеп утыз тавыкны, кырык казны, илле үрдәкне таптатып киткәннәр. Бушлыкта светофор куелганны белмәгәннәр.

Шуннан авыл халкы, тагын җыелып, бу светофор мәсьәләсен хәл итәргә булды. Әйдә өстән куйдырткач торсын инде, ачуларын кабартмыйк дип, шул ук Бәдертдин кувалдасы белән бәреп, үзебезчә — татарча булсын дип, яшелне генә калдырдылар. Өстән күрше Ришай авылы кешесе Җәкәүне ГАИ итеп куйдылар. Күп тә үтми, аның тапталган гәүдәсен пычрак юлдан куптарып алдылар. Әле җан бирмәгән булган. Үзе шәп кенә җиффәргән. Җиффәрмәгән булса, исән каласы түгел икән. Күрше Оба авылы кешеләре, бу нинди җүләр авыл уртасында күсәк болгап тора дип, иске «Запорожец»лары белән таптатып киткән булганнар.

Икенче көнне светофорның утын шул Бәдертдин кувалдасы белән бәреп, безнеңчә дә, аларча да булмасын дип, сары утка күчерделәр.

Шул төнне җиденчемнең Чечнядагы малае психованный булып кайтып светофорны Мәскәү Кремле каршына утыртып куйган. Барсагыз күрерсез, кызыл уты әле дә бертуктаусыз янып-сүнеп эчне пошырып тора, ди. Торсын — урыны дөрес сайланган. Андагыларга ул килешә торган төс. Анда хайван тапталасы юк, разве анда-монда берәр кеше эләксә генә инде. Үзегез беләсез, бездә кеше чутта түгел. Аннан соң, андагылар беркайчан да ур-ра кычкырып яшәмәделәр. Ур-раны без кычкырдык, хәер, без инде башка бернәрсә дә эшли белмибез.

## Митрәй

Сез безнең авыл Митрәйне беләсезме? Юк, ул сезгә охшамаган... Сезгә дә охшамаган. Әнә теге апага охшаган охшавын, ләкин ул — Митрәйне әйтәм — хатын-кыз түгел, алка тагып йөрми. Нәрсә дисез, без дә хәзер алкалар, йөзекләр тагып йөрмибез, дисезме? Куркасызмы?.. Әйе шул, алтын тагып, әйбәт бүрек киеп йөрергә башы ике түгел кешенең. Митрәй дә шулай ди. Бервакыт шәп кенә киенеп Казанга килде бу минем белән. Кырык яшь егеткә, өйләнергә вакыт бит инде. Үзегез беләсез, хәзер авылларда утыз карчыкка бер егет туры килә. Анысы да Митрәй кебек алпавыт булырга йөрүче хәсрәт капчыгы. Вокзалга килеп төшүгә, зәңгәр күзле Казан чибәре эләктереп тә алды моны.

— Митрофанов, — дип таныштырды үзен Митрәй, Рәсәй Думасында утыручы депутатны искә төшереп.

— Слицка, — диде кызыл иреннәрен шапылдатып чибәркәй, тагын бер депутат исемен хәтерләтеп.

— Дом-дук, жук, — диде Митрәй тотлыгып, кунарга урын юк икәнлеген аңлатып.

— Пойдем, найдем, — диде Слицка.

Киттеләр култыклашып куак шаулаган якка.

Митрәйнең «Аллага тапшырдым» дигән сүзләре куак төбеннән вокзалларга бәреп чыңлады. Чыңлар шул, күргән нәрсәсемени?.. Әллә поезд кычкыра, әллә Митрәй үкерә. Әй, кызлар, аңлыйсызмыни сез авыл егетләренең хәлләрен!.. Бирегез бер чиләк аракы — эчеп бетерә. Бирегез тимер — бөгә! Бирегез кирпеч — сугып сындыра! Китерегез сарык — бер утыруда ашап бетерә. Табыгыз бер кыз!..

Ә шәһәр егетләре нәрсә? Йөз грамм эчсәләр — егылалар, тагын йөз грамм җиппәрсәләр — торалар. Сөт өсте юк. Ул эләкмәгәч, рәт тә юк.

Хөрмәтле ханымнар! Ничек торасыз сез ул ирләрегез белән?! Торса — торабыз, тормаса — юк, дисезме?

Нәрсә сөйли идем әле? Ә-ә, Митрәй турында бит. Поезд китте, җирләр тибрәтеп. Каршы якта Митрәй тора анадан тума, яп-ялангач, кемнедер озаткан кебек, трусигын җилләтеп. Чишендергәннәр моны куак төбендә Казан «Слицка»лары.

Юк, аның кәчтүме сезнеке төсле түгел, аныкы шакмаклы иде. Әнә сезнеке төсле. Ул кәчтүм үзегезнекеме? Ә-ә, бәясе төшкәнне алдыгызмы? Чалбарыгызны күрсәтегез әле. Кальсоныгыз акмы?.. Төссезләнгәндер инде юа-юа. Митрәйне әйтәм, ул да сезнең кебек җәй көне дә кальсон кия торган иде. А то бура бураганда шырпы керә, ди. Бу юлы Казанга үзе килмәде, Казан кызларына ат башы хәтле сәламен генә җибәрде. Үзләре кайтсыннар, диде. Киләсе елга өйләнергә исәбе. Конкурс игълан иткән, авыл башында белдерүе тора. Анда «Бу авылда өйләнмәгән кырык яшьлек Митрәй тора» дип язылган. Әйе, бу авылдан ул берәү генә. Ә бит алар меңәрләгән.

Әгәр һәр авыл башында шундый белдерүләрне күрсәгез, гаҗәпләнмәгез, алар безнең Митрәй кебек өйләнмәгән, әмма авылларын, туган якларын, әти-әниләрен яратучы, хезмәт сөюче ялгыз егетләрнең моң-зарлары кадакланган такта булыр.

...Юк, ул сезгә охшамаган, сезгә дә... Кәчтүме аның шакмаклы иде...

## Ай югары, Ай югары...

Мендем мин ул Айга. Кыегыннан аякларымны салындырып сезне күзәтәм.

Әнә Шамкай каядыр ашыга. Өстән караганда атлый кебек, ә үзе тәгәри. Театрдан киткәннән бирле тыз да быз чаба Шамкаебыз. Шәрәфи әйтмешли: «Чапмый булмый, китереп тоттырмыйлар. Тоттыралар тоттыруын, ләкин без теләгәнне түгел».

Атаклы Шамкай! Сиңа айдан кычкырам: «Пенсияң нихәтле? Күрсәтмә миңа чалбар төймәңә таба. Адәм мәсхәрәсе...»

Президенттан ким эшләми югыйсә: бер карасаң — үзебездә, бер карасаң — Мәскәүдә... Мин телгә салынып торганда, әнә Уфага да барып җиткән. Шыгрым тулы заллардан алкышлар тавышын ишетәм.

Бу вакытта даһиебыз Шәрәфи меңенче мәртәбә Камал театрында Әҗәлен уйный. Күрәм, кулларын күкрәгенә куеп йөрәген капшый. Үзем дә үлмәдем микән дип шикләнә, ахрысы. «Шәрәфи, синең тырнагыңа да тормаган Голливуд артистлары Америкада губернаторлар, миллиардерлар!»

Әнә, карыйк әле, нишләп йөри икән анда, мәсәлән, Шварцнеггер? Һә! Буш белән кочаклашып, Тын океан уртасында көймәдә чайкалалар.

Шәрәфи, Шәймиевкә әйтимме, сине дә берәр районга глава итеп куйсыннар! Ичмасам, Иделдә су коенып ятканыгызны күрсәм дә сөенер идем.

Йә, ярый, кеше мәшәкатьләрен онытып, җиһанны күзәтим әле. Тагы кайчан менәм мин бу Айга? Биеклек бөеклеккә тиң булмаса да, хыялланып утыруы үзе бер рәхәт.

Матур да соң безнең Җир шары! Ал нурларга төренеп таң ата. Кытайлар, япуннар күптән уянган. Әллә йокламыйлар да микән? Русиядә дә торырга вакыт түгелме? Анда-монда нидер шартлаталар — селкенеп тә караучы юк. Әйләнәләр дә яталар. Уяныгыз, өегезгә ут төртәләр! Янасыз бит!

Каяле, безнең авыллар нишли икән? У-у! Халык басуда. Балалар укымый — бәрәңгедә. Бөтен Татарстан кулында чиләк-көрәк. Быел иген мул уңган. Җыеп алырга кирәк. Русия кырларында кәбестә җыеп йөрүчеләрдән башка адәм затлары күренми. А кушать все хотят! Эй, братцы, кончай балдеть! Ишетәләрме соң? Пычагым башы!

Әнә Мәскәүләренә кара! Кырмыска оясымыни, никадәр халык мыж килә. Заводка баралар дисәм, заводлары эшләми. Базар өстендә базар. Саталар. «Блендамент» белән ышкып, «Стиморол» белән чәйнәп, памперсларга төреп, илне саталар. Берочтан безне дә.

Казан нишли? Әнә Кремльгә немесләр килгән, күптән түгел генә кытайлар булган иде, Корея министры да шунда, Нурсолтан еш күренә, гарәпләрнең юлы өзелми. Беларусларга ни калган? Төрекләр туганга әйләнеп беттеләр. Казан дусларын барлый, татарны дөньяга таныту кирәк. Юккамыни мин Айга менеп аяк селкеп утырам. Юри күрмәмешкә салышасыз. Гомергә татарны танымадыгыз!

Гер күтәрү буенча ун тапкыр дөнья чемпионы Фәнис Сәхиевне кемнең күкләргә күтәреп мактаганы бар? Кемнәрнең Марат Сафинны, Алинә Кабаеваны, Хәбил Бикташевны алар татарлар диеп әйткәннәрен ишеткәнегез булды? Күпме хоккейчылар, футболчылар безнеке! Хәер, «Ак Барс»тагы теге негр капкачыны татар дип әйтәләр ди үзе.

Телгә салынып күрми кала язганмын, Африкада ниндидер тузан туза. Әнә-әнә, Европада да өермә купты. Ә-ә! Безнең автоузышчылар икән. Давай, егетләр, давай, сынатмагыз! Давай, Рөстәм, бирешмә! Ай-рат! Ай-рат! Афәрин, безнекеләр тагын беренче!

Уф, кычкыра-кычкыра тамак бетте. Кхы-кхы. Карале, Түбән Кама төтеннәре айга хәтле күтәрелә икән, тончыктыра башлады.

Әй, кем анда тагын арттан бәрәңге белән ата? Башны тишәсең бит. Хатын, синме ул? Нәрсә? Нишләп Ранияләрнең тәрәзәсенә карап утырыйм ди? Хәзер төшәм.

Ай югары, ай югары,
Айга сез дә менегез!
Мин мендем дә сезне күрдем,
Ә сез мине күрегез!

## Сабантуйлар җитәр тиздән!

Сабантуйлар җитәр тиздән,
Көтә халык һәм мин дә.
Шатлык белән бүләк килә,
Ун пылесос өемдә!

Җиде электр чәйниге
Чәй кайнаталмый ята.
Пылесослар унысы да
Эшләмиләр ничурта.

Өч магнитофон бирделәр,
Төшми алар чормадан.
Шырды-бырды тоттыралар,
Курыкмыйлар Ходайдан.

Утызлап сәгать җыелды,
Берсе, ичмасам, ник йөрсен!..
Ну Алмаз байый дигәнне
Ишетсә, тавык көлсен.

Ел буе тула кибеттә
Җыен ватык товарлар.
Бүләккә шәп, сабантуйда
Тикшермичә алалар.

Сабантуйда гына түгел,
Беркөн юбилей булды.
Паспортын гына бирделәр,
Суыткычы онтылды.

Артист булгач кайвакытта
Концертлар да куябыз.
Җырлы мансар якларыннан
Тик әйләнеп узабыз.

Халкы әйбәт, һичбер сүз юк,
Чәйләр куеп озата.
Ну башлыгы концерт өчен
Акча бирми аптрата.

Хәер, мине генә түгел,
Илбашны да алдыйлар.
КамАЗ белән нефетенә
Банкротлык сылыйлар.

Ул — тимер, мин — асылташ
Булгангамы талыйлар.
Әллә инде аны, мине
Шыр тилегә саныйлар...

Сабантуйлар җитәр тиздән,
Җитәрләр, ну, җитәрләр!!!

Миңа тагын ватык сәгать,
Уйлыйм, бүләк итәрләр.

Кызыгын кызык,
Тик шунысын бел!
Сине-мине
Ярык тагарак
Яннарында көтәләр.

## Гайбәтләр

Бик еш миннән сорыйлар,
Энем, Алмаз, әйтәле,
Нигә көн дә радиода
Үзешчәннәр тавышы.

Башка җырчылар юкмыни,
Илһам әллә үлгәнме?
Әлфия Афзалова кая соң,
Кияүдәме, ирдәме?

Хәмдүнәнең хәле ничек,
Җырлыймы, төрмәдәме?
Үтүк белән суккач, теге
Баянист үлмәгәнме?

Фәйрүзә игезәк тапкан, ди,
Кем беләндер үбешкәч.
Фирзәрнең эшләгәне ашарга
Җитә микән күп эчкәч.

Сәгыйть Гыйбашев нигәдер
Ябыккан, ди, тиктомал.
Аерып булмый икән аны
Хәзер җырчы Равилдән.

Искәндәр Биктаһиров кайда,
Ул аракы эчәме?
Муса Маликның этисе
Үзе җырлый беләме?

Салават кайда, Салават?
Акча җыйды, күренми.
Америкага киткән бит ул,
Түзә халык сүгенми.

Гөлзадәнең фамилиясе
Сафиуллинамәле?
Башка фамилияләргә
Алмаштырмадымы әле?

Эльвира Розалина ул
Маржушкамы, татармы?
Ятьмә күлмәк асларында
Комбинашкасы бармы?

Шул Гайфулла Авзаловның
Кыланышын яратмыйм.
Төнлә төшләремә кереп,
Килмә, диеп кабатлыйм.

Сәнифәнең ак күлмәкләр
Кигәнен күрсәң иде.
Сары күлмәге бу төштән
Өстәрәк торса иде.

Фамилҗәсе Әхмәтова,
Исеме Лидияме әле?
Җөмһүриятен болгап җырлый,
Бәбиләмәдеме әле?

Ат дагасын җырлый торган
Эльвираны яратам.
Бөтен сбруен тугарып,
Төнлә саташып ятам.

Равил Хариска сүзем бар,
Әйт әле үзен күргәч.
Зинһар өчен, җыр язмасын,
Җырлар әле мин үлгәч.

Рөстәм Закиров беркөнне
Җырлый да җырлый, малай.
Гран-при акчасы беткән,
Ашарга сорый бугай.

Зөһрә Шәрифуллинаны әйтәләр,
Филармониядән киткән.
Су буенда учак ягып
Җырларга җыры беткән.

Венера Ганиева, әйт,
Опера җырламасын.
Без опера яратмыйбыз,
«Җомга» көен җырласын.

Давай безгә туй күлмәге,
Давай безгә аулак өй.
Айдар Фәйзрахман молодец,
Операча җырламый.

Зәйнәп белән Зөфәр Билал
Законный торалармы?
Бергә мунча кереп йөри,
Дип сөйлиләр аларны.

Асаф Вәлиевкә ничә яшь,
Уйлыймы өйләнергә.
Өйләнер өчен алай күп
Кирәкми өйрәнергә.

Ренат Ибраһимовның тавышы беткән,
Бик каты йөткерә, ди.
Ул хәзер Камал

Театрының зәңгәр түбәсеннән
Кабан күленә сикерү буенча
Төнге сабантуй үткәрә, ди.

Хәниянең хуҗасы
Габделхәе бит инде.
Шул Алла Пугачеваның
Киркоровы күк инде.

Күзегездән күреп торам,
Беләм ниләр уйлыйсыз.
Бу Алмаз үзе кем белән
Йөри икән дип уйлыйсыз.

Мин дә сездән сорыйм әле,
Булмый бит телне бәйләп.
Кем белән килдең концертка,
Хатының микән, әйбәт.

Менә сеңлем, синнән сорыйм,
Кичәге егетең кая?
Бүгенгесен күреп торам,
Вот те ситуация...

Дуслар, кеше тикшергәнче
Бер-беребезне тикшерик.
Артист халкы күз каршында,
Булмый берни яшереп.

Бер-беребезгә игелек телик,
Бер-беребезне яратыйк.
Минем сүзләрне куәтләп,
Бер гөрләшеп кул чабыйк.

## Бер мәхәббәт тарихы, яки...

КАТНАШАЛАР:

Рафинад — 30 яшь.
Флорида — 27 яшь.
Нәсимә — 55 яшь.

Вакыйга бүгенге көннәрдә шәһәрнең бер кунакханәсендә бара.
Нигәдер ут сүнгән. Көлгән тавышлар ишетелә.

Хатын. Ә син помнить итәсеңме, когда син минем кулымнан тоткан идең?

Ир. Ну, конечно, помнить итәм. Мин әле ул чакта очень здорово краснел даже.

Хатын. Мин тоже, тагын дрожал хәтта.

Ир. Карале, это булды тугызынчы класста, да бит?

Хатын. Юк. Син ошибаешься. Это булды беренче тапкыр, когда син мине чәчемнән тарттың, мин җиденче класста укыдым. Ә син уже был на десятом. *(Көлә.)* Уф, улям, даже эчем болит.

Ир. Син даже мин синең чәчеңнән тартканымны да помнишь. Ха-ха-ха! Ә мин, ә мин первый раз, когда твои кулларыңны тоттым помню. *(Көлә.)*

Хатын *(көлә-көлә)*. Ә син беләсеңме, один раз малайлардан мине защищал?

Ир. Нет, белмим. В памяти калмаган.

Хатын. Скромныйланма инде.

Ир *(көлүеннән туктап)*. Чыннан да не помню, Флорида.

Хатын. Эх син. А говоришь любишь! Яратам, яратам, дисең.

Ир. Конечно, люблю. Поэтому мин сине бүген монда чакырдым да, акыллым. Иди ко мне якынрак.

Ут кабына. Сәхнә уртасында Рафинад белән Флорида бер-берсенә карап басып торалар.

Флорида. Ой, свет кабынды! Рафинад!

Рафинад. Ут булмау миңа ошабрак тора иде әле. Ә безне ут только испугнул.

Флорида. Рафинадым минем, кил монда ближе, милый, как я соскучилась.

Алар бер-берсенә якыная башлыйлар, ишектән, атылып, кунакханәдә эшләүче Нәсимә керә. Урын-җир әйберләре өләшә башлый.

Нәсимә. Исәнмесез, җаныкайларым! Татарлардыр бит, әйеме?

Рафинад. Әйе, әби, апа, тетя...

Нәсимә. Нәсимә Зәйниевна, диген.

Флорида. Нәсимә Зәйниевна, исәнмесез!

Нәсимә. Исәнме, матурым. Паспортларыгызны миңа бирдегезме әле?

Рафинад. Юк, сезгә бирмәдек. Там внизу оставили.

Нәсимә. Ирле-хатынлылар инде, әйеме?

Рафинад. Ыхым, ыхым...

Нәсимә *(Флоридага)*. Хатынымы, дим, иптәшеме?

Икесе бергә. Да, әйе, да. Әйе шул.

Нәсимә. Да, да. Шул да шул. Җаныкайларым, минеке дә менә шул. Җылы суның кайчан булганын хәтерләмим. Салкын суны төнлә бирәләр. Бәдрәф эшләми. Мәшәкатьләрегез булса, каршыда горком бинасы, милиция кертсә, шунда сорарсыз. Үтүк юк. Ут янса яна, янмаса — юк. Урысча әйтмешли, как хочешь, так и живи!

Рафинад. Без тоже привыкли инде, Насыйма апа!

Нәсимә. Нәрсәгә генә привык соң син? Тфү, урысча сөйләтеп торасың. Нәрсәгә күнеккән әле сез?.. Сугыш, ачлык күр... Карагыз әле, бик сөйләштереп тормагыз әле, яме, мине. Эшем күп.

Чыгып барганда, сәерсенеп, кабат борылып карап кала. Рафинад белән Флорида аңа һәм бер-берсенә аптырап карап торалар. Ниһаять, Нәсимә чыгып китә.

Флорида. Что будем делать, Рафинад, ә? Безне моннан не прогонят? *(Сүзсез торгач.)* Әллә бу мине белә инде.

Рафинад. Ул с каждым так, күптән белгән кебек сөйләшә, наверное. Әнә керде дә: тр-тр-тр-тр... Бөтенесен сөйләп бетерде. Раньше учительницей эшләгән, наверное.

Флорида *(исенә төшереп)*. Да, охшаган...

Рафинад. Син чего-то вспоминать итәсең что ли?

Флорида. Ә син не помнишь, была у нас такая?

Рафинад. Не помню.

Флорида. Эх син. Ничего не помнишь и меня... Вспомни-ка!

Рафинад. Мәктәптә что ли?

Флорида. Ну, ну...

Рафинад. По татарскому языку что ли?.. А-а! Вспомнил!

Флорида. Да-да! Молодец, искә төшердең!

Рафинад. Ул бит Надежда Зиновьевна иде.

Флорида. Вот, точно она и есть. Нәсимә Зәйниевна!

Рафинад. Точно! Тогда почти все татарские учителя переименованы были. Ә без татарскому языку йөрмәдек. Всегда убегали.

Флорида. Без тоже.

Рафинад. Ә потом ул үзе әллә кая югалды. Без аны сизми калганбыз. Әле менә син искә төшергәч кенә вдруг вспомнил мин моны.

Флорида. Честно говоря, мин ул турыда мало помню. Давай забудем ул турыда.

Рафинад. Да, үзең бит искә төшердең. Миңа все равно.

Флорида. Ә син минем белән безнең этне прогулкада йөрткәнне помнишь? Этнең исеме Фуранилин иде. Помнишь? Әле ул синең портфельне до вашего дома довезла.

Рафинад. Помню, помню, Флорида! Такое никогда не забывается. Ялгышмасам, это было, тогда ты восьмой класс бетердең. Техникумга керергә йөри идең. Мин хотел, чтобы син мәктәпкә больше бармасын иде дип. Мин сине ул көнне бик нык көткән идем.

Флорида. Да, да, мин дә ул көнне көткән идем. Прежде всего мин ул көнне тебя ждала.

Рафинад *(Флоридага елышып).* Мин тоже, Флорида.

Флорида *(Рафинадны иркәләп).* Рафинад!

Рафинад *(Флориданы үзенә тартып).* Флорида!

Флорида *(кисәк турсаеп).* Ә син мотоциклыңа Светаны утыртып килгәнсең.

Рафинад. Ул синең белән встречаться итәргә теләгән иде.

Флорида. Да она не со мной хотела встречаться, она хотела форсить.

Рафинад. Ә мин каян белим.

Флорида. Глупец син.

Рафинад. Ә мин думал, что син мине видеть даже не хочешь.

Флорида. Шуңа күрә аны утыртып ускакал, да?

Рафинад. Ну, Флорида, забудь!

Флорида. Такое не забывается.

Рафинад. Если так разбираться, үзең Виталик белән постоянно разыгровать итә идең.

Флорида. Син Света белән булгач, мин Виталикны придумала, конечно.

Рафинад. Не говори, Витя безнең кебек слесарь малае түгел иде инде ул. Аның әтисе как на черной Волге проедет, так и слюны протекали у девчонок- претенденток. Беләбез!

Флорида. Давай не будем бу турыда кузгатырга, Рафинад!

Рафинад. Үзең бит.

Флорида. Рафинадчигым, шикәрем!

Рафинад. Флоридам, Флорам, Фаунам минем!

Кочаклашмакчы гына булалар, Нәсимә керә.

Нәсимә. Җаныкайларым, әйбәт кенә урнаштыгызмы? *(Шифоньерны ачып.)* Менә монда ике элгеч. Бәрәч! Моның берсе кая киткән тагы? *(Эзли.)* Монысын да *(иске элгечне күрсәтеп)* икенчене элеп киткәннәр. Кара инде син бу кешеләрне, ә, элгечкә хәтле эләктереп киткәннәр бит. Өстәлдә ике стакан, бер графин. Бәрәч! *(Стаканга күрсәтеп.)* Берсе кая моның? И-и-и, монысын да чәлгән бит бу. Менә кешегә ышан, менә кешегә ышан...

Рафинад. Безгә алып китәргә ничего не оставили инде, Надежда Зино... әй, Нәсимә Зәйниевна.

Флорида. Борчылмагыз, Нәсимә Зәйниевна. Безгә стакан кирәкми.

Нәсимә *(Рафинадка бик игътибар белән карап).* Сезгә кирәкмәсә, миңа кирәк. Аны бит миннән таптыралар.

Рафинад. Безгә ут кирәкми. Борчылмагыз!

Нəсимə. Карап-карап торам да, чыннан да сезгə бернəрсə дə кирəкми. *(Икесенə дə сынап карап.)* Аптыраш кругом.

Флорида. В самом деле, ничего не нужно, борчылмагыз!

Нəсимə. Хе... Яшьлəргə бернəрсə дə кирəк булмагач, безгə ни кирəк инде тагын. Хе... *(Чыгып китə.)*

Ул чыгып киткəч, Рафинад белəн Флорида тиз генə кочаклашмакчы булалар, лəкин Нəсимə капылт кына тагын борылып керə.

Нəсимə. Алай булгач, болай, җаныкайларым. Мин илле бишенче бүлмəдə, кирəк булсам нитсəм, дəшəрсез. *(Бераз аптырап торганнан соң.)* Шикəрем бар, чəем бар — чəй эчəргə керегез!

Рафинад. Спасибо!

Флорида. Рəхмəт!

Нəсимə. Рəхмəте соңыннан, эчкəч булыр. Сөйлəшеп утырырбыз. *(Чыгып китə.)*

Флорида белəн Рафинад бер-берсенə карап куялар. Тагын килеп керə күрмəсен дип, читлəшеп утыралар.

Флорида. Əллə ничек, не удобно булып китте.

Рафинад. Да, есть такое ощущение. Биллəhи, как дети сидим. В жизни раз встречаешься и то кеше төсле түгел.

Флорида. Рафинад, если не возражаешь, мин бер əйбер алып килгəн идем. *(Шешə белəн аракы чыгара.)* Без бит инде хəзер балалар түгел.

Рафинад. Флорида, не удобно! Минем үземнең бар. Сине күргəч, баш кругом, от счастья онытып торам. *(Аракысын чыгара.)*

Флорида. Ой-ой-ой! Дела будут!

Рафинад. Əйдə бераз. Как говорят: за встречу! *(Стаканга бүлеп аракы тəкъдим итə.)*

Флорида. Башта үзең.

Рафинад *(эчеп куя).* Для смелости!..

Флорида. Ой, минем давно эчкəн юк инде. *(Кабымлык эзли, лəкин ул юк.)*

Үбешергə якынлашалар, шулчак ялт итеп Нəсимə керə.

Нəсимə. Менə, җаныкайларым, сезгə тагын бер стакан. *(Шешəне күреп.)* Бəрəч!!! Закускагыз да юк икəн бит. *(Чыгып китə.)*

Флорида белəн Рафинад ераккарак китеп басалар. Менə-менə ул тагын əйлəнеп керер кебек. Ə ул юк та юк.

Рафинад *(бераз басып торгач, пышылдап).* Кил бире!

Флорида. Юк, ярамый. Вот-вот килеп керер.

Рафинад. Ишекне биклик.

Флорида. Юк, нельзя. Догадается.

Рафинад. Ну и что, какое ее дело. Без законно устроены.

Флорида. Она ведь паспортларны сораган иде.

Рафинад. Это не ее дело.

Флорида. Как не ее дело?

Рафинад. Чөнки, потому что все уплачено.

Флорида. Кому?

Рафинад. Астагыларга!

Флорида. Кемнəргə?

Рафинад. Аста утыручыларга. Тем, кто устраивает.

Флорида. А-а!

Рафинад *(үзенең янына чакырып).* Иди сюда!

Флорида. Подожди бераз.

Рафинад. Больше түземем калмады.

Флорида. Хəзер, хəзер, җаным.

Рафинад. Мин гел только сине генə уйладым.

Флорида. Уйладың, ə башкага өйлəндең, эх син...

Рафинад. Мин бəхетсез, Флорида, аңла! Мин бу встречаны бик озак көттем. Я тебе стихи сочинил, послушай əле.

Мин тауларда йөрим сине эзлəп,

Ә син томан артында.
Раз чыгасың и югаласың,
Табармынмы икән кайчан да?..

Флорида. Рафинад, бу минем турыдамы?

Рафинад. Әйе.

Флорида. Әйбәт.

Рафинад. Мин аны сиңа багышлап чыгардым.

Флорида. Тагын бармы стихотворениеләрең?

Рафинад. Алар минем бер общая тетрадьта иделәр. Мин кирәк булмас по-моему дип ташладым, да и жизненные ситуации изменились.

Флорида. Ой как жалко. Зря ташлагансың сочинительствоңны. Бу стихотворениегә җыр можно было состряпать.

Рафинад. Вообще-то аның мотивы бар иде *(җыр көйли башлый).*

Мин тауларда йөрим сине эзләп,
Ә син томан артында.
Раз чыгасың и югаласың,
Табармынмы икән кайчан да?

Сине эзлим, сине, сине генә,
Бергенәмдер инде син бу дөньяда да.
Иртән кояш алсу нурын сибеп,
Кичләрен моңсуланып батканда да.

Мин кырларда йөрим сине эзләп,
Ә син урман янында.
Барсам йөгереп урман кырыена,
Син буласың инде тауларда.

Сине эзлим, сине, сине генә,
Бергенәмдер инде син бу дөньяда да.
Иртән кояш алсу нурын сибеп,
Кичләрен моңсуланып батканда да.

Флорида. Ой, как шәп! Ә мин татарча җырларны онытканмын инде.

Рафинад. Да, мин дә бүген первый раз с тех пор татарча җырладым. Если честно әйткәндә, кроме «Утыр әле яннарыма»дан башка мин больше и җырлар белми дә идем.

Флорида. Все равно у тебя әйбәт получается.

Рафинад. Ну да, әйттең. Кая инде ничә ел гел по-русски везде, всюду... Балалар вообще татарча белмиләр.

Флорида. Безнең өйдә дә шулай ук инде. Виталик ул: «Вот ваши чаплашки поют», — дип, телевизорны борып икенчегә куя.

Рафинад. Кичә кызым үзенең нациясен определять итеп утыра. Как хотите, мин үземне «русская» дип язам, ди. Ә миңа бу дөньяда все безразлично. Нәрсәгәдер бөтенесе кувыркком артка тәгәри. В начале пути нәрсәдер упущено.

Флорида. Не вешай нос! Миңа калса, без өйдә бик дружно яшибез, бергәләп җырлар җырлыйбыз *(җырлап җибәрә).*

По Дону гуляет,
По Дону гуляет,
По Дону гуляет
Казак молодой...

Флорида стаканга аракы салып эчеп җибәрә.

Флорида. Эх, Рафинадым минем, Рафинадым! Белмисең йөрәгемдә минем ниләр кайный. Ул үзенең почмагына барып чукына, ә мин, ә мин... *(Рафинадны кочаклый.)*

Рафинад. Флорида, әйдә бергә...

Шул вакыт Нәсимә керә.

Нәсимә. Нишләп чәй эчәргә кермисез? Чакырганны көтәсезме әллә? Закускагыз бармы соң? Таптыгызмы?

Рафинад. Без вообще-то эчә торган кешеләр түгел. Шулай да... берне решили ачарга. *(Тәкъдим итеп.)* Рәхим итегез!

Нәсимә. Кирәк түгел иде дә инде. *(Каршы килебрәк.)* Каршы килү килешмәс. Танышу хөрмәтенә.

Флорида. Әйдәгез, әйдә!

Нәсимә *(эчеп куйгач).* Нәм-нәм-нәм-нәм. Ымма. *(Чыгып китә.)*

Рафинад һәм Флорида кочаклашмакчы гына булалар, тагын Нәсимә керә. Кулында төргәк белән дуңгыз салосы.

Нәсимә. Нәм-нәм-нәм-нәм. *(Өстәлгә кискәләп куя.)*

Рафинад. Отлично!

Флорида. Ә без поросенканы үзебез үстереп сало ясыйбыз.

Нәсимә. Ә мин болай итәм. Кибеттән тач май дуңгыз ите алам да, тозлап, борычлап, сарымсаклап куям. Ашарга әйберең булмаса, шуны суырып ятарга булыр, дим.

Флорида. Нәсимә Зәйниевна, нәрсә ул, как вы сказали, сарымсак?

Нәсимә. Чеснок була ул, чеснок.

Флорида. Ә без тоже так делаем.

Рафинад. Кто верит, кто мечтой живет — тот всегда дольше живет. Шулай бит, Нәсимә Зәйниевна. Безне школларда шуңа өйрәттеләр.

Нәсимә *(Рафинадка әллә ничегрәк карап).* Школларда өйрәтерләр анда. Хәзер шул школларда гына өйрәтсәләр инде. Башка өйрәтер җирләр бетте. Анысы шулай, Рафинад, өметсез шайтан, ди халык. *(Кисәк кенә.)* Карагыз әле, сезнең берегез бер җирдән, икенчегез икенче җирдән... *(Уңайсыз хәлдән үзе тартып чыгарган булып.)* Әй, мин үзем дә Красный Баран кызы. Кыр-Тау районыннан Татарча Сайгаклы авылыннан, кыз чакта син кайсы авыл кызы дип сорасалар, без Баран кызлары дип әйтүе шулкадәрле гарьлек иде. Шулай бөтен авылларның исемнәрен русчага әйләндереп бетергән чаклар бар иде бит ул. Әй, ул әле хәзер дә шулай.

Рафинад *(Нәсимә янына җайлап кына килеп).* Нәсимә Зәйниевна, без бер-беребезне яратабыз. Ә менә жизнь сложилась по-другому.

Нәсимә. Алай икән...

Флорида *(елардай булып).* Нәсимә Зәйниевна! Я очень устала. И муж хороший, кыйнамый.

Рафинад *(күңеле тулып).* Татарча сөйләшеп, чәй эчеп утырасым килә. Менә Флорида белән сөйләштек тә монда очрашырга булдык, Нәсимә Зәйниевна!

Нәсимә *(аларны кочаклап).* Әти-әниләрегез исәннәрме, балалар?

Флорида. Әйе, исәннәр.

Нәсимә. Кайтып күрендегезме соң әле?

Рафинад. Юк.

Нәсимә. Кайткалыйсызмы соң?

Флорида. Почти юк.

Нәсимә. Балалар, сезгә иң элек әниләрегез янына кайтырга кирәк.

Флорида. Минем вакытым да калмады инде. Мине Виталик бер генә көнгә җибәргән иде.

Нәсимә. Әниләрең янынамы?

Флорида *(башы белән ымлап).* Әйе.

Рафинад. Мин дә Светадан бер генә көнгә өйгә кайтып килергә сораган идем.

Флорида. Нәсимә Зәйниевна, кайтсам да әниемнең күзләренә туры карый алмыйм. Кияүгә чыкканда рәнҗеп калды бит ул миңа.

Нәсимә. Гомер буе үзеңнән качып йөреп булмый бит инде.

Рафинад. Нәсимә Зәйниевна! *(Күңеле тулып чыгып китә.)*

Нәсимә *(Флоридага).* Балаларың бармы?

Флорида. Бар, Нәсимә Зәйниевна.

Нәсимә. Ирең белән торасыңмы соң?

Флорида. Торам.

Нәсимә. Яхшы кешеме соң?

Флорида. Әйбәт, как и все люди торабыз.

Нәсимә. Соң, шулай булгач.

Флорида. Без разные люди аның белән. Аның үз интереслары, минем үземнеке. Соңгы елларда чего-то без разными стали. Токмачлы аш ашыйсым килә, Нәсимә апа. *(Еламсырап куя.)*

Нәсимә. И җаным, шулай диләр аны. Сагынгансыңдыр шул, сагындыра ул токмачлы ашлар. Гел щи ашап тордыгызмы?

Флорида *(аның белән килешеп).* Ы-ы.

Нәсимә. Хет тәмләп сөт белән чәй эчә идегезме?

Флорида. Үзем генә эчәм. Бүтәннәр ияләшә алмый.

Нәсимә. Балаларны өйрәтергә кирәк иде. Сөтләп чәй эчсәләр, ул инде безнеңчә, ягъни үзебезчә булыр иде. Пәрәмәчләр, өчпочмаклар, бәлешләр пешерә идеңме соң?

Флорида. Юк. Мин аларны пешерә белмим. Өйрәнмәгәнмен.

Нәсимә. Ә балаларың ничәү?

Флорида. Икәү. Берсе кыз, икенчесе малай.

Нәсимә. Иван белән Марияме?

Флорида. Николай белән Людмила.

Нәсимә. Анда үзең кем булып йөрисең инде?

Флорида. Флора инде.

Нәсимә. Фауна дисәләр дә була инде, әллә ни аерма юк. Полный маржа булып беткәнсең икән. Менә шулай итеп безнең татар кызлары маржушкага әйләнеп бетәләр инде.

Флорида. Юк. Паспортта әле татарка дип язылганы калган.

Нәсимә. Анысы аның, җаным, бумажка гына шул. *(Йөрәгенә күрсәтеп.)* Менә монда булуың кирәк, менә монда. *(Бераз уйланып утыргач.)* Кая соң әле безнең, теге ничек әле исеме, шикәрме әле шунда.

Флорида. Сез кемне әйтәсез?

Нәсимә. Теге инде, менә синең, корт чаккыры... Конфет түгел инде, исеме шундыйрак...

Флорида. Сез кемне вспоминаете?

Нәсимә. Менә синең мәхәббәтең инде, исеме ничек әле? Ириска түгел инде.

Флорида. Рафинадны әйтәсезме?

Нәсимә. И-и, миңгерәү. Менә бит, ә! Рафинад кая соң әле безнең?

Флорида. Аның душасы тулды, ул хәзер керер.

Нәсимә. Рафинад! Рафинад!

Рафинад керә.

Мин сине шикәрләр, конфетлар белән бутап бетердем. Көчкә исемеңне таптым, Флорида әйтмәсә әле, тәки Ирис дип йөрер идем үзеңне. Токмачлы аш ашыйсың киләме?

Рафинад. Килә, Нәсимә Зәйниевна. Кайчан ашаганымны хәтерләмим.

Нәсимә. Алай булгач, аш ашыйбыз. Хәзер камыр басарбыз, әйеме, Флорида, токмач җәярбез, бәләкәй генә ат итем бар иде, бик шәпләп кенә татарча аш өлгертербез. *(Чыгып китә.)*

Рафинад. Флорида!

Флорида. Нәрсә булды?

Рафинад. Мин сине сагындым.

Флорида. Рафинадым минем, Ирисчигым.

Кочаклашалар. Караватка авып киткәндә генә, Нәсимә керә.

Нәсимә. Җаныкайларым, әллә коймак та куеп җибәрәбезме, әчегә.

Рафинад. Татарча коймакмы?

Нәсимә. Мин башкача пешерә белмим.

Флорида. Булышыйммы, Нәсимә апа?

Нәсимә. И җаным, күптән шулай диләр аны, Нәсимә апа, диләр. Безнеңчә шулай бит ул. Апа гына диләр. Синсез Ирис нишләр соң, әй, Рафинадың?

Флорида. Ә сез аның белән бераз сөйләшеп утырыгыз!

Нәсимә. Әйдә, алай булгач, мин сиңа кухняны күрсәтеп килим әле. Син пешерә торырсың, ә без гәпләшеп утырырбыз, килен коймагы көтеп. Мә, яп бу алъяпкычны! *(Алъяпкыч бирә.)*

Рафинад көзге каршына килеп чәчен тарый, йөзенә карый.

Нәсимә. Тормыш дигән нәрсә катлаулы шул ул. Яшьли ясаган ялгышларны төзәтү җиңел түгел. Мин үземнән чыгып фикер йөртәм. Искә төшерәм дә шуларны, йөрәгем жу итеп китә. Кыска гына мизгелгә хисләреңне тыя белмәү гомерлек үкенечләр китерә икән ул. Менә хәзер мин гомерлек ялгыз. Балам булудан мәхрүм калып, гомерлек ялгызлыкка дучар булдым. Үз баламны түгел, кеше балалары тәрбияләп, укытып гомерем узды. Анысы да яртылаш мәсхәрәләнеп, кимсетелеп. Мин бит, Рафинад, югары белемле укытучы кеше. Татар теле укытучысы! Соңыннан мәктәпләрдә татар теле кыскартылып, татар балаларына урыс теле укытып, Нәсимә Зәйниевна урынына Надежда Зиновьевна булып йөргән, соңыннан бөтенләй, фикер каршылыклары буенча, мәктәптән куылган кеше. Менә хәзер

гостиницада эшләп һәм яшәп гомер кичерәм. Кешеләр минем белән кайгыларын уртаклашалар, тулган күңелләрен чишәләр. Синең соң, Рафинад, гаиләң бармы?

Рафинад. Бар, Нәсимә апа.

Нәсимә. Хатының үзебезнең кешеме?

Рафинад. Марҗа, Нәсимә апа!

Нәсимә. Алла, шулай бик тупас әйтмә!

Рафинад. Бик матур сап-сары марҗушка, Нәсимә апа.

Нәсимә. Нәрсә, шул марҗага өйләнү бик модно мәллә ул? Әллә марҗаларныкы икенче төрлеме? Сихерләре бармы?

Рафинад. Юк ла инде, Нәсимә апа. Бер дураклык булган инде, уйланылмаган.

Нәсимә. Уйларга кирәк иде. Бу баш нәрсәгә соң ул сезгә — ир кешегә. Хатының ни исемле?

Рафинад. Света.

Нәсимә. Света, Светлана... Сәлимә исемле бер җабага гына үзебезнең татар кызы булса да, ичмасам...

Рафинад. Шулай да бит.

Нәсимә. Токмачлы аш ашаганың булмадымыни?

Рафинад. Юк, булмады.

Нәсимә. Пешерә белмимени?

Рафинад. Юк. Токмач җәя белми. Бик эре килеп чыга, бармак хәтле.

Нәсимә. Гел щи ашап тордыңмы?

Рафинад. Әйе. Аннан соң тозлы кәбестә.

Нәсимә. Чиркәүгә йөрмәдеңме соң?

Рафинад. Юк, анда бармадым.

Нәсимә. Ник?

Рафинад. Почему, сам не знаю. Икона күрсәм, башым әйләнә минем.

Нәсимә. Ә балаларыңның исемнәре Иван белән Марияме?

Рафинад. Да, почти.

Шул вакыт, коймак күтәреп, Флорида керә.

Флорида. Ой, Нәсимә апа, агач кашык белән коймак салу шундый удобно икән ул.

Нәсимә. Әллә белми идеңме?

Мактый-мактый коймак ашыйлар.

Нәсимә. Чәй әзердер, кертим әле. *(Чыгып китә.)*

Рафинад. Син шундый матур, Флорида!

Флорида. Бу киемнәр белән, әйеме?

Рафинад. Әйе. Кил бире!

Алар бер-берсенә якынаялар. Шул вакыт Нәсимә керә. Рафинадның башына түбәтәй кигезә.

Нәсимә. Менә болай татарча була.

Флорида. Ой, Рафинад, сиңа ничек килешә!

Нәсимә чыгып китә. Алар бер-берсенә тагын якынаялар.

Рафинад. Флорида, мин сине шундый сагындым.

Флорида. Рафинад, сөеклем минем.

Рафинад *(колагына пышылдап).* Фло-ри-да-а-а!!!

Флорида *(чәчләреннән сыйпап).* Рафинадым минем!

Нәсимә керә.

Нәсимә. Чәй булды, коймак пеште, аш кайный. Менә безнең эшләр шәп бара. *(Сөтләп чәй ясый).* Менә нәрсә әйтәсем килә, җаныкайларым, сезгә. Сезнең әти-әниләрегезне дә сүгәсем килә әле минем. Кара инде нинди исемнәр кушканнар бит сезгә. «Флорида» урынына үзебезчә матур гына, җайлы гына итеп «Фәридә» дип кушсалар ни була? Ә синекен «Рафинад» урынына һич булмаса «Шикәр» дип кушсалар да татарчарак булган булыр иде.

Рафинад. Безнең ярты урам Рафинад исемле иде.

Флорида. Минем исем белән дә шулай булды. Модасы шундый иде.

Нәсимә. Мода була да ул, уза да. Ә менә кеше исеме мәңгелек булсын! Аннан соң телегезне оныткансыз. Әллә нинди телдә сөйләшеп утырасыз. Ни татарча, ни русча. Туган җирегезне, әти-әниегезне оныткансыз. Иманыгыз калмаган. Көй-моңнарыгыз, хисләрегез буталган, югалган. Әйдәгез әле, Габдулла Тукайның «Туган тел»ен җырлап искә төшереп алыйк.

И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!
Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы.

Дөньяда күп...

Үзе генә җырлап утыра. Флорида белән Рафинад кушыла алмыйлар.

И җаныкайларым. Кайчан җитәр бу адәм баласының үз телендә, үз илендә рәхәтләнеп, иркенәеп яшәр һәм эшләр чаклары! Йә, ярый. Ял итегез! *(Чыгып китә.)*

Флорида. Күңелсез булып китте.

Рафинад *(аракы тәкъдим итеп).* Бәлки?!

Флорида. Юк, Рафинад, син мине кочаклап үп тә...

Нәсимә керә.

Нәсимә. Менә паспортларыгыз. Иртәгә иртүк китәсе булгач... алыгыз.

Флорида. Бүген инде ул, иртәгә дигәнебез. Хәзер тагын бер сәгатьтән поездга чыгарга кирәк.

Рафинад белән Флорида бер-берсе каршына килеп басалар. Алар ягымлы гына бер-берсен иркәләшәләр. Күңелләренә тулган хисләре аша җыр яңгырый.

Һәр агачның була үз урманы,
Һәрбер кошның бардыр оясы.
Минем татар, үги бала кебек,
Читтә йөри эзләп анасын.
Халкым, сине алтын аең көтә.
Кузгал юлга әйтеп бисмиллаң.
Әйләнеп кайт изге туфрагыңа,
Бабаң кабере әле сакланган!
Ят җирләрдә яңгырый гармун моңы,
Өзгәләнә йөрәк шуңарга.
Сагышларын басар өчен микән
Җыела татар гармун тыңларга.
Ераклардан җәннәт эзләп йөрмә,
Үз илеңнән гүзәл нәрсә бар?
Гөл бакчасы яса туган яктан,
Үз татарың белән яшәп кал!
Халкым, сине алтын аең көтә,
Кузгал юлга әйтеп бисмиллаң.
Әйләнеп кайт изге туфрагыңа,
Бабаң кабере әле сакланган!

Рафинад. Флорида, кайт, озак көттермә!

Флорида. Рафинад, кабат очрашуны көтеп ала алмам кук.

Рафинад. Түз, бәгырем!

Флорида. Безгә очрашырга кирәк, көт мине!

Рафинад. Көтәрмен!

Флорида. Түзәрмен!

Нәсимә, Флорида, Рафинад күмәкләшеп елыйлар.

ПӘРДӘ.

## Лифт ватылды...

КАТНАШАЛАР:

Дилбәр — юан хатын, Джек исемле эт белән.
Әби.
Кәли — сәрхуш ир.
Студент.
Джек — негр.

Подъездга Әби керә. Кулында полиэтилен пакетка салынган сөт.
Бисмилласын әйтеп лифт төймәсенә баса.

Әби. Эшли микән инде?! *(Лифтның тавышы да чыкмый.)* Җәяү менә башласам, менеп җитеп булмас, сөтем әчеп бетәр микән? *(Тагын лифт төймәсенә баса.)*

Шул вакыт подъездга Кәли керә. Кулында полиэтилен пакет белән пиво.

Кәли. Нәрсә, әби, лифт эшләми мәллә? *(Лифт төймәсенә баса. Лифт эшләми, йодрыгы белән суга. Әбигә карап.)* Әгәр җәяүгә калсам, точно пиво агып бетә. *(Үзе пакет тишегеннән сиптереп агып торган пивосын эчә. Әбигә тәкъдим итә.)* Мә, эч, әби!

Шул вакыт подъездга эте белән Дилбәр керә. Кулында ике зур сумка.

Дилбәр. Нәрсә, лифт эшләми мәллә, кичә ябылмый иде.

Әби. Бүген ябылмый гына түгел, ачылмый да әле.

Дилбәр. Бездә шул булыр инде, блин. Дөньясы нинди, лифты шундый. *(Күкрәк кесәсеннән кулъяулыгын алып тирен сөртә.)* Авызына күрә селәгәй!..

Әби *(Дилбәргә).* Ничәнче этажга... катка менәсең?

Дилбәр. Ундүртенчегә!

Кәли *(Дилбәрнең сумкасына карап сызгырып).* Этаж саен йөз грамм чутыннан. Күтәреп менешәм.

Дилбәр. Акылың алтын икән, алкаш, несчастный. *(Этенә эндәшеп.)* Джек, возьми!

Эт бер сумканы авызына алып күтәрә. Әби, Кәли, Дилбәр, эт чиратка баскан кебек торалар. Студент керә. Китап укый-укый чиратка баса. Шул вакыт подъездга Джек-негр керә. Кулындагы магнитофоннан заманча көй яңгырый, шуңа кушылып үзе җырлый, сызгыра. Лифт төймәсенә баса, ул эшли башлый, аның өстән төшкәне ишетелә. Лифтның ишеге ачылып китә. Барысы да тыгыла-тыгыла лифтка кереп тулалар. Лифт ябыла һәм кузгалып күтәрелә башлый. Бераздан соң ул ватылып туктый. Эчтән дөбердәтә башлыйлар.

Кәли. Әй, кем бар анда, без лифтта калдык!

Әби. Әй Аллам, нәрсә инде бу, ә? Гөнаһлы бәндәләр утырды микән әллә...

Дилбәр. Лифтны ачыгыз!

Кәли. Лифтерны чакырыгыз!

Дилбәр. Сволочьлар! Жаловаться буду!

Лифтның ишеген каерып ачалар да шаккатып калалар. Лифт өстә эленеп калган икән. Эт чиный башлый. Алгы планда Джек-негр сүзсез генә басып тора, музыка тыңлый. Студент укый, аның башына Дилбәрнең күкрәкләре тиеп тора. Студент анда-монда күтәрелеп куя, аңа бик комачау. Эт уртада. Дилбәр арткы планда, Кәли сул якта, Әби уңда. Барысы да лифтның төймәсенә басып карыйлар. Әби дога укырга тотына. Дилбәр дә шикләнеп Джек-негрга карый. Эт ырылдап куя.

Джек, бире кил!

Джек-негр аңа карап яңадан берсүзсез катып кала. Эт иснәнеп Әбинең сөт пакетын ялый башлый. Әби куркып утыра-утыра да пакетын ачып эткә сөтен эчерә башлый. Сөтне бераз эчкәч, эт Кәлинең пакетын ялый башлый, Кәли аңа пиво эчертә.

Ягез, берәр җаен табыгыз инде. Монда төн кунып ятып булмас. Әй, син, студент, ташла әле китабыңны. Лифтта застряли бит, беләсеңме шуны?

Студент эндәшми, һаман утыра, китап укый.

Студент, дим, лифт ватылды, берәр чарасын күрик әле. Лифт ватылды, дим. Слушай!

Студент. Ы-ы!

Кәли *(Студентка).* Мә, эчәсеңме?! *(Пиво эчертә.)*

Студент (игътибарын бернәрсәгә дә юнәлтмичә). Шәп! Түлке эт исе килә. Кайда саталар?

Кәли. Мунча янында.

Студент. Шулаймыни... Алай булгач, мин тиз генә барып килим әле.

Китабын яба, күтәрелеп карый, этне күреп өнсез кала, сикереп торып лифттан чыгып китмәкче була, чак кына егылып төшми, кире урынына сеңә. Эт белән карашып торалар. Дипломатын ачып, колбаса телеме бирә. Эт аңа тәпиен бирә, аннан соң эт бөтенесенә дә тәпиен биреп исәнлә-шеп чыга. Джек-негрга килеп җиткәч кенә,Дилбәр аны туктата.

Дилбәр. Джек, утыр! Утыр, диләр сиңа! Джек!

Джек-негр чүгәли. Эт тә чүгәли.

Студент. Нәрсә бөтенегез дә җыелышып миңа карап утырасыз. Лифт эшләми икән бит. Кая, китегез әле... *(Төймәләргә басып карый.)* Әй, кем бар анда, лифтны карагыз әле. *(Лифттагыларга карап.)* Нигә сез кычкырмыйсыз?

Кәли. Без кычкырдык инде, хәзер син кычкыр! Син ученый кеше, давай син кычкыр! Без рабочий классны бар дип тә белмиләр хәзер. Кычкыр давай, кычкыр!

Әби. Кычкыр, улым, кычкыр! Без пенсионерларны эткә дә чутламыйлар хәзер.

Дилбәр. Кычкыр, Студент, кычкыр! Син интилигин кеше. Интилигиннар кычкыра торган заман хәзер. Парламентта гомер буе кычкыралар инде.

Эт ыржаеп өреп куя.

Кәли. Этләр заманы хәзер. Әнә бер ыржаюы булды — тындык.

Дилбәр. Эт, димә аңа. Джек, диген. Нинди эт булсын ул сиңа, оскарблять итмә! Джегым минем! *(Үбә.)*

Студент. Апа, породасы нинди бу овчарканың? *(Кесәсеннән этләр рәсеме чыгарып, чагыштырып утыра башлый.)* Английский кокер-спаниель, гладкошерстая такса, доберман, дог, жесткошерстый фокстерьер, ирландский сеттер, колли, дратхаар, ньюфаундленд, пекинес, пудель, русская псовая борзая, русский спаниель, эрдельтерьер, бобтейль.

Джек-негр. Фокстерьер!

Студент. Ничек?

Джек-негр. Фокстерьер!

Студент. Вот из ё нейм?

Джек-негр. Фокстерьер!!!

Студент *(Джек-негрга күрсәтеп)*. Фокстерьер?

Джек-негр. Ноу, ноу. Ё нейм из фокстерьер. *(Эткә күрсәтеп.)*

Дилбәр. Син үзең факистержыр. Аның исеме Джек.

Джек-негр *(Студентка)*. Май нейм из Джек. *(Үз исемен әйтә.)*

Дилбәр. Бәрәч, бу негрларга эт исеме кушалар икән!

Джек-негр *(үзенә күрсәтеп)*. Джек.

Дилбәр. Дилбәр мин. Дольбермин.

Джек-негр. Доберман! Ай эм вери хэппи, доберман!

Дилбәр *(Студентка)*. Нәрсә ди ул?

Студент. Бездә дә шундый эт исеме бар, ди. Доберман!

Кәли *(Джек-негрга кулын биреп)*. Кәли! Минем исемем кебек берәр эт юкмы? *(Студентка мөрәҗәгать итеп.)* Сора әле!

Студент. Хиз нейм из Кэлли.

Джек-негр. О! Колли! Ес, ес, ес!

Студент. Бар, ди. Колли исемле этләр безнең якларда бик күп, ди.

Джек-негр танышырга дип Әбигә кулын суза.

Әби (куркып китә, дога укый башлый). Догамны, догамны онытытым.

Джек-негр. Дог! Ес дог!

Студент. Дог дигән эт тә бар, ди. Э май нэйм из Саттар.

Джек-негр. О, шотландский сеттер!

Дилбәр *(шаркылдап көлеп җибәрә)*. Шотландский сеттер! Син, гөлкәем, шотландский сеттер, ди.

Барысы да көләләр.
Эт өреп куя. Барысы да тыналар.

Дилбәр. Джек, утыр!

Эт тә, Джек-негр да утыралар.
Бераздан соң барысы да кычкырырга тотыналар.

Коткарыгыз! Коткарыгыз!

Дилбәр *(үзе ашый, үзе күши).* Көне буе эштә йөреп арылган. Блин. Аякларга чыдар хәл юк. *(Сумкасыннан зур колбаса алып комсызланып ашый башлый. Башкалар иреннәрен ялап утыралар.)*

Студент. Апа, сез кайда эшлисез соң?

Дилбәр. Кибеттә эшлим, җаным, кибеттә. Страшный авыр эштә. Көне буе аяк өсте колбаса сатам. Син үзең кем соң, китап укып йөргән буласың. Студент та түгелсеңдер әле. Ученый, хәсрәт капчыгы...

Студент. Студент мин, апа, студент. Көндез эшләп, кичен укып йөрим. Менә лекциядән кайтышым. *(Джек-негрга борылып.)* Ай эм стюдент!

Джек-негр. Ай эм мин дәген стюдент. Конгодан.

Студент. Ай эм Казаннан.

Джек-негр. Казаннан?

Студент. Казаннан.

Джек-негр. Ай есть татарча әз генә белям.

Кәли. Әйдәгез, танышу хөрмәтенә. *(Этнең авызыннан алып, пиво эчертмәкче була. Берсе дә эчми, баш тарталар.)*

Әби *(Студентка).* Әти-әниең бармы соң, улым?

Студент. Бар, әби, бар.

Әби. Ничәнче квартирада торасыз?

Студент. Унынчы катта.

Әби. Җүәрия малае мәллә син, сөйләшүләреңә, кыяфәтләреңә кадәр әниеңә охшагансың.

Студент. Әйе, әби, Җүәрия малае мин. Уртанчыларыннан берсе.

Әби. Сигез баламы әле сез?

Студент. Тугыз, әби.

Әби. Зур квартира бирмиләрмени әле?

Студент. Юк әле, әби.

Әби. Ничек сыясыз сез анда?

Студент. Менә шушындагы кебек инде. Монда, лифтта, әле иркенрәк тә.

Дилбәр. Шуңа күрә иркенләп, рәхәтләнеп утырасыңдыр әле син монда.

Студент. Миңа барыбер. Өйдә дә идәндә, монда да идәндә.

Кәли. Өйдә дә идәндә, монда да идәндә,
Кем карасын бездәй ирләргә.

Сузылып яталар, алар белән бергә эт тә ята.

Дилбәр *(Кәлигә).* Джекка карап ятма! Авызыңнан әллә нинди яман ис килә.

Кәли. Әбекәй, пивоны тотып тор әле. Тартасы килә башлады. Слушай, Студент, шырпың бармы? *(Идәннән нәрсәдер эзләнә.)* Төпчек табып тартырга иде. *(Лифт идәненнән төпчекләр таба.)* Шырпың бармы? Әй, слушай, апа, синең шырпың бармы?

Дилбәр. Кукиш! Бер кабы биш сум. Ә болай бирмим.

Кәли. Кончай! Бир инде. Моннан чыгып котылгач акчасын бирермен.

Дилбәр. Ай-һай, бирерсең микән... *(Кәлинең фуражкасын алып.)* Акча тапкач кереп алырсың. Мә!

Кәли. Син ничәнче квартирада торасың соң?

Дилбәр. 171дә.

Кәли. Слушай, Доберман, то есть Дилбәр, сезнең җәмәгатегез бармы?

Дилбәр. Юк. Без Джек белән икәү генә торабыз.

Кәли *(этнең кулын кысып).* Тәбрик итәм сезне!

Дилбәр. Башка сүзегез булмаса, борчылмагыз сораштырып. Ә үзеңнең соң хатының бармы?

Кәли. Мин дә шул бер эт белән торам. Өрми торган, таламый торган чагы юк. Кайтып керү белән борын төбен исни һәм шыңшый башлый.

Дилбәр. Унсигезенче этаждагы Зиночкамы әллә синең хатының?

Кәли. Ә сез аны каян беләсез?

Дилбәр. Ул мунчада эшлиме?

Кәли. Әйе.

Дилбәр. Ул да миңа бер эт белән торам, дворняжка тек дворняжка инде дигән иде. Ул эт син булып чыгасың инде, алай булгач. Нәселсез эт. Ә исемегез породалы югыйсә — Колли. *(Көлә.)* Колли!

Барысы да көләргә тотыналар. Көлеп туйгач, бөтенесе дә кычкыра, лифтны дөбердәтә башлыйлар. Бераздан еламсырап алалар. Әби дисбе тарта.

Студент. Әби, син ничәнче катка менәсең? Бер дә күзгә чалынганың юк. Монда торасыңмы, кунакка киләсеңме?

Әби. Икенче катта торам.

Студент. Ә без өченче кат тирәсендә эленеп торабыз бугай.

Дилбәр. Кая барма: трамвайда, троллейбуста, автобуста, инде менә хәзер лифтта да шушы әбиләр аяк астында буталып йөриләр. Керсәң — чыгар әмәл юк, чыксаң — керер әмәл юк.

Кәли. Аракы кибетендә дә шулай.

Джек-негр. О, ес дог әби әйбәт, во!

Студент. О, әбейкә, маладис!

Джек-негр. Вери гуд компания! Әттәч! Доберман әйбәт, Колли әйбәт, Саттер әйбәт, әби Дог әйбәт, Джек әйбәт. Ничек әле сездә әйтәләр. Ад-д-даш!

Әби *(Студентка пышылдап, Джек-негрга күрсәтеп).* Гөнаһ шомлыгы, бигрәк кара инде, име?

Студент. Курыкма, әби! Кызыңны алып куйса, иң яраткан киявең булыр әле менә. *(Джек-негрга.)* Карале, Джек, синең ваефың — хатының бармы? *(Этнең башына сугып.)* Кит әле, синнән сорамыйм. Син өйләнгән бит инде.

Джек-негр. Ноу!

Студент. Синең, әби, кияүгә чыкмаган кызың бармы?

Әби. Бар.

Студент. Ничә яшьтә?

Әби. Кырык биштә.

Студент. Слушай, Джек, әбинең вери гуд кызы бар. Хочешьмы? *(Әбигә.)* Болай аяк-куллары исән-саумы?

Әби. Исән-сау, алары гына бар барын.

Студент. Слушай, Джек! *(Эткә.)* Синең белән сөйләшмибез лә без. *(Джек-негрга.)* Все о’кей!

Дилбәр. Әрәм була, әби, кызың! Әрәм була! Кырык бишкә хәтле сакланып килеп...

Студент. Әби, каршы килмә! Африкада анда җәннәттә яшәгән кебек яшиләр. Эх, үзем кыз кеше булсам, икеләнеп тормас идем. Давай, әби, давай, риза бул! *(Үзе Джек-негрны төрткәли, үзе аңа баш бармагын күрсәтә.)* Во кызы әбинең! *(Джек-негрның кулын кыса.)* Килештек! *(Әбигә карап.)* Булды, әби, килештек. Кулыңны бир, әби.

Дилбәр. Студент, студент! Бик ашыкма әле син. Монда әби кызыннан яшьрәкләр дә бар.

Студент *(лифттагыларга күз төшереп).* Кем бар?

Дилбәр. Апаң. Монда әле кырыгы тулмаганнар да бар.

Студент *(Джек-негрга карап).* Үзе нәрсә дияр бит әле...

Джек-негр. Миңа барыбер, менә адаш нәрсә әйтер бит әле?

Дилбәр. Әйтмәс. *(Джек-негрны чакырып.)* Кил монда, утыр. Ымма... *(Үбә.)*

Джек-негр белән эт Дилбәрне уртага алып утыралар.

Кәли. Туй! Пар күгәрченнәр шикелле,
Ничек кавыштыгыз сез?
Икегез дә пар килгәнсез,
Ничек табыштыгыз сез?

Студент. Ай икегез, икегез,
Икегезнең битегез.
Берегез кара, берегез юан,
Рәхәт гомер итегез!

Кәли *(Дилбәргә).* Мәгәриче булырмы? Сумкаңда бардыр бит?

Дилбәр *(Джек-негрга).* Алдамассыңмы?!

Джек-негр. Ноу!

Дилбәр. Әйбәтләп яратырсыңмы?

Джек-негр. О, ес!

Дилбәр. Ныгытып яратырсыңмы, кысып кочакларсыңмы?

Джек-негр. Ну инде!..

Дилбәр. Ну, кысып күрсәт әле.

Джек-негр *(кысып кочаклап).* Менә шулай!

Дилбәр. Ныграк, ныграк!!! Ныграк, дим!!! *(Негр аякларын лифт стенасына терәп кочаклый.)* Әй, корчаңгы, алай кочаклыйлармыни аны. *(Джек-негрны кочаклап кыса. Негр кычкырып җибәрә.)* Менә хәтәбе шулайрак. *(Джек-негрга колбаса тоттыра.)* Мә, аша! Хәл керә торсын. Берничә көн яшәп карарбыз, рәт чыгара торган булсаң, мин сиңа өйләнермен. Ә хәзер берәүгә дә обещать итмә!

Кәли. Әби, синең кәефең кырылды, ахрысы.

Әби. Кырылмыйни. Кызга кияү табылды дигәндә генә...

Кәли. Квартирагыз зурмы соң?

Әби. Кызым белән икебезгә ике кумныт. Әй шул бәбечкәемне алучы булса, Алланың рәхмәте белән кияү кешегә машиналык акча бирермен дигән сүзем бар иде. Әй Аллам, нигә генә соң ул безгә үзенең хәер-фатихаларын бирми, сөендерми икән.

Студент

Кәли

Әби. Лифтта кызыма кияү кирә-ә-ә-к, кызыма кияү кирә-ә-ә-к, дип кычкырып утырып булмый бит инде.

Кәли. Алкаш булса да ярыймы?

Студент. Студент булса да ярыймы?

Джек-негр. Ай лов ю, әби! Әбине мин яратам! *(Урыныннан кузгалмакчы була.)*

Әби. Кем булса да ярый. Алкаш әзрәк эчсә, студент картрак булса, негр аграк булса — ярый.

Кәли *(эткә)*. Джек, мә эчеп бетер пивоны!

Студент. Әби, миңа унбиш елдан утыз биш тула инде.

Джек-негр. Мин Африкадагы кешеләргә караганда аграк әле, әбейка. Аха!

Кәли *(Джек-негрга).* Син таптың инде, тик кенә утыр! Әйдә, без, Студент, синең белән санашабыз. *(Саный башлый.)* Акыты, пакыты, чукыты на, авел, павел, германы, икс, пикс, грамматикс, плюнс. Әби, киявең мин чыктым. Аяк-куллары исәнме соң кызыңның?

Әби. исән, исән. Бераз гына сакал-мыек баса басуын, ләкин ул аны гел кырып тора. Анысы зыянсыз. Менә шул, кияү.

Кәли. Ә!!!

Студент. Кичә гәҗиттә укыдым. Казанның Хуҗа Насретдин урамындагы бер йорт лифтына биш кеше кергәннәр, ди. Шуларның берсе бишенче этаж төймәсенә баскан, ди, икенчесе сигезенче этаж төймәсенә баскан, ди. Шулай итеп, биш белән сигез ничә була? Илле сигез була! Лифт күтәрелә дә күтәрелә, ди. Болар тугызынчы катны да узып, йорт түбәсеннән үк чыгып киткәннәр, ди. Айны да узып киткәннәр, ди, болар, кояшны да. Безнең кебек лифт белән очып йөрүчеләр күптер әле ул һаваларда. Ничек булып беткәнен язмаганнар.

Дилбәр. Карагыз әле! Без дә шулай очып йөрмибез микән? Мин үзем ундүрткә баскан идем.

Кәли. Мин җидегә бастым.

Студент. Мин унга бастым.

Әби. Мин икегә бастым.

Джек-негр. Кнопс да, секстинга.

Студент. О-о-о! Очына чыгарлык түгел! Җәмәгать, безнең йорт уналты катлы гына бугай бит. Димәк, без чыннан да космоста!

Барысы да аска карыйлар.

Дилбәр. Тәлинкәләр күренмиме?

Студент. Юк.

Әби. Фәрештәләр күренмиме?

Студент. Бик еракта кемнәрдер күренә анда. Авызларын ерып утыралар.

Кәли. «Тур» яки «Җәннәт» дигән язулар күренмиме?

Студент. Юк.

Кәли. Ә, алай булгач, әллә ни еракка китә алмаганбыз икән. Үзебездә икәнбез.

Әби. Улым, беркая да очмаганбызмы әллә?

Студент. Юк, әби, юк. Аз гына кузгалып киткәнбез дә туктаганбыз һәм ватылганбыз.

Әби. Аллага шөкер, алай булгач, куркыныч юк икән.

Студент. Юк, әби, юк. Застряли генә, застой!

Әби. Нәрсә дисең?

Кәли. Терәлеп каттык, ди. Бөтен ил терәлеп катты, ди.

Студент. Һәм катачакбыз, диген!

Дилбәр. Ничек инде ул алай? Мин катарга җыенмыйм!

Студент. Менә әбинең бер машиналык акчасы бар, ә ашарына юк!

Кәли. Чөнки ашарга менә монда! *(Дилбәрнең сумкаларына сугып күрсәтә.)* Менә монда алар, әйеме, ханым. Менә монда алар. *(Этнең корсагына сугып күрсәтә.)* Менә монда алар. *(Джек-негрның эченә сугып күрсәтә.)*

Дилбәр. Һәм менә бу алкашларга китә. (*Кәлинең эченә һәм тамак төбенә сугып күрсәтә.*)

Студент. Әби, пенсияне күпме аласың?

Әби. Нәрсәне?

Студент. Пенсияне, мәйтәм, күпме, ничә сум аласың?

Әби. Йөз егерме тәңкә! Аллага шөкер, җитә әлегә.

Дилбәр. Әй, сез шул Аллага шөкерегез белән чәй эчеп торасыз инде.

Әби. Алай димә, кызым. Алланың биргәненә шөкер дип торырга кирәк.

Дилбәр. Каян алып бирә торгандыр ул карчыкларга, ә безгә үзең күтәреп кайтмасаң, бирергә уйламый да. *(Кинәт кабынып.)* Әй, сез! Берәрегез бармы анда? Сволочь лифтер! Кая олактың? Застерәли бит.

Кәли. Подлец, диген.

Дилбәр *(кычкырып).* Падлис!

Студент. Бездельник, диген!

Дилбәр. Биздилни-и-к!

Әби. Денсез, диген!

Дилбәр. Денсез!

Джек-негр. Дуңгыз, диген!

Дилбәр. Ышвае-е-ен!

Джек-эт. Вау!

Студент. Диген.

Дилбәр. Вау! Вау!

Кәли *(Студентка).* Чыдар хәл юк, малай. Тышка чыгасы килә.

Дилбәр. Кем лифтны сасытты? Абщественный местыны!.. Үтерә-ә-м!

Әби. Мин түгел.

Студент. Мин түгел.

Джек-негр. Ноу, ноу.

Кәли. Эттер әле.

Студент *(Кәлигә күрсәтеп).* Кайсыгызның эч даруы бар? Югыйсә бу безне...

Джек-эт. Вау! Ке-ше-лә-р! Эх сез, ке-ше-ләр!

Алгы тәпиләре белән лифт төймәсенә баса. Лифт эшли башлый һәм аскы этажга төшә. Барысы да этне таптап, өстенә басып лифттан чыгып йөгерәләр. Эт лифттагы чүпләрне җыештыра, аларны чүп савытына сала. Музыка яңгырый. Эт елый-елый җырлый.

Этләр этлек эшләмиләр,
Алар тугры һәрчак дуслыкка.
Бу дөньяда безне эт итүче
Тик кешеләр икән,
Тик кешеләр икән...

ПӘРДӘ.

## Татар империясе

КАТНАШАЛАР:

Чыңгыз хан.
Үтәмеш.
Сөембикә.
Иван Грозный.
Петр I.
Наполеон.
Ленин.
Мао Цзэ-Дун.
Сталин.
Гитлер.
Хрущев.

Екатерина II.
Брежнев.

### Беренче күренеш

Вакыйга җир астында бара. Ярымтүгәрәк рәвешендә төзелгән парламент залы. «Дөнья матур, дөнья киң» дигән җырның инструменталь варианты яңгырый. Уртада трибуна. Югарыда санап үтелгән кешеләр барысы да гадәти киемнәрдән. Парламентарийлар өйлә намазы укыйлар.

Сүбәхәнәкә әллаһүммә үә бихәмдикә үә тәбәракәс-мүкә үә тәгәлә җәддүгә үә лә иләһә гайрук…

Намаз бөтен шартын китереп укыла. Шул вакыт өстән дөбердәп табут килеп төшә. Барысы да аптырап калалар. Табутның капкачы ачылып китә. Аның эченнән барлык орден-медальләрен таккан Брежнев торып утыра. Барысы да, бераз шаккатып торганнан соң, намазның соңгы юлын укып куялар.

Раббәнә әтинә фиддун йә хәсәнәтән үә фил ахирәти хәсәнәтән үә кыйнә гәзәбәннәр. Бирәхмәтикә йә әрхәмәр-рәхимин. Амин.

Брежнев, табутында утырган килеш, күкрәк кесәсеннән кәгазь чыгарып, речь сөйли башлый.

Брежнев. Глубокоуважаемые товарищи, друзья! Вот настал час прощания с вами. Не могу скрыть своего искреннего удовлетворения — мы жили с вами хорошо! Народы всех стран будут помнить меня как своего любимого вождя, как никак мы жили, хотя и короткое время, в коммунизме. За этот огромный труд перед своим народом, я награждаюсь шестьдесят шестым орденом Ленина! Долгие продолжительные апплодисменты… *(Берәү дә кул чапмагач, Брежнев аптырап як-ягына каранып куя.)*

Ленин. Минем сиңа орден биргәнем юк. Гомумән, мин сине белмим. Безнең большевиклар партиясендә мондый медальле этәчләр булмады һәм булмас та! Безнең бурыч медаль алу түгел, ә чын коммунистик җәмгыять төзү!

Брежнев *(башкаларга карап)*. Каля-маля… О чем бормочет чукча?..

Екатерина II. Товарищ, вы уже «на том свете», то есть вы уже похоронены, вы уже под землей. Ваше последнее обращение к народу здесь ни к чему. Разрешите представить вам бывших знаменитостей: это Владимир Ильич Ленин, мондагы исеме — Пеләш Малай, а вот справа от вас первый — Чингиз хан, дальше — Үтәмеш хан *(Брежнев торып баса, танышып йөри башлый)*, Иван Грозный, мондагы исеме — Сөйкемсез Иван, Петр I — Пәхер Беренче, Наполеон Бонапарт — Одеколон, Мао Цзэ-Дун — Кытай Малай, Иосиф Виссарионович Сталин — Мыекбай, Адольф Гитлер — Фашист Малай, Никита Сергеевич Хрущев — Кукуруз Малай, ханбикә Сөембикә, мин үзем — Екатерина, монда килгәч, Йокычиренә булдым.

Чыңгыз хан. Екатерина Вторая!

Брежнев. Теге, простите… *(Әйтә алмыйча интегә.)* Что ли?

Екатерина II. Бозык! Сез уйлаганча түгел. Президент ассоциации всех подземельных честных женщин — Иң Саф Кыз һәм…

Чыңгыз хан *(шаулаша башлаган парламентарийларны тынычландырырга тырышып)*. Югары Шурабызның утырышын дәвам итәбез.

Сталин *(Гитлерга пышылдап)*. Моны шымчы итеп җибәрмәделәр микән монда? Тикшерергә кирәк. Килү белән теләсә нәрсәгә тыкшына башлады.

Гитлер. Мин дә бик шикләнеп торам. Начальник булырга ярата, ахрысы. Чыңгыз ханны кисәтеп куярга кирәк. *(Чыңгыз ханга барып пышылдый. Чыңгыз хан, аның сүзләренә колак салгандай, башып селкеп куя. Гитлер башкаларның да күңеленә шом салып йөри башлый. Алар да бер-берсе белән пышылдашып алалар.)*

Чыңгыз хан. Көн тәртибендә берничә мәсьәлә. Беренчесе — Җир Асты Татар империясенең икътисади һәм сәяси хәле, аның куәтен ныгыту чаралары; икенчесе — императорлыкка кандидатлар тәкъдим итү һәм аларны тикшерү; өченчесе — Җир Асты Татар империясенең беренче императорын сайлау; дүртенчесе — төрлесеннән.

Ленин *(Чыңгыз ханның колагын «ашаганнан» соң)*. Мөхтәрәм парламентарийлар! «Төрлесеннән» дигән өлешкә мин бүген сезнең сафка килеп тыгылган *(Брежневка күрсәтеп)* бу иптәшнең фикер нигезләмәләрен тыңлап карарга тәкъдим итәм.

Чыңгыз хан. Фикерләшеп алыйк. Кем дә кем… *(Барысы да пышылдауга күчәләр.)*

Иван Грозный. Кем булса да үзебезнең кеше итәргә кирәк моны.

Петр I. Тышкы яктан беркатлы кешегә охшаган бугай бугаен.

Наполеон. Болай зыяны булырдай тоелмый.

Мао. Чегән, тач чегән. Чегәнгә охшаган.

Хрущев. Кайдадыр күргәнем бар бугай бу зур кашларны…

Екатерина II. Күренеп тора, үбешергә ярата.

Чыңгыз хан. Әллә бераз комиссияләрдә эшләп алабызмы?..

Барысы да «әйе шул, әйе шул» дип чыгып киткән булалар да, ишек артына качып, берүзе калган Брежневны күзәтеп торалар. Брежнев яңадан, күкрәк кесәсеннән кәгазен чыгарып, «речь толкать» итә башлый.

Брежнев. Как учат нас классики марксизма и ленинизма: Маркс и Карл, а также Энгельс и Фридрих, анализируя их, можно с уверенностью сказать: «Призраки бродят под землей». *(Туктап уйланып тора.)* Мне кажется, я их где-то встречал. *(Ишек төбендәгеләр җанланып алалар.)*

Сталин *(Гитлерга).* Күрдеңме, юри бутап сөйләшә.

Гитлер. Мин дә шуны чамаладым. Карлны Маркс ди.

Хрущев. Фридрихны Энгельс ди.

Мао. Ә бит югыйсә Марксны Фридрих дип әйтергә кирәк.

Екатерина II. Сез шуны беләсезме икән: Карл Фридрих Маркс Энгельсның хатыны белән йөргән, ди. Хи-хи, ишеткәнегез юкмы?

Иван Грозный. Ник, алар монда килгәч безнең тарафтан тагын бер үтерелеп, тагын бер тапкыр ике метр аска күмеп куелган кешеләр түгелмени?

Наполеон. Ә-ә! Теге сакал-мыеклы ике яһүд шулар идемени? Мин бит аларны Швед короле белән Прус короле дип торам.

Гитлер. Юк ла, алар түгел. Болар бит коммунизм дип бик котырып йөрделәр. Шул башларына җитте инде аларның.

Екатерина II. Юньле җәмгыять түгел, хатыннарын да юньләп бүлешә алмадылар.

Мао. Коммунизмда барлык нәрсә уртак!

Сталин. Бу да шуннан башлады.

Чыңгыз хан. Империя нигезенә балта чаптырмабыз! *(Ленин, Сталин, Хрущевка ишарәләп.)* Заманында сез үзегез бик кызып коммунизм дип йөргән идегез. Хәзер генә суындыгыз. Тыныгыз да чыкмый.

Хрущев. Без нәрсә? Без бернәрсә дә әйтмибез. Өстәгеләр шымчы җибәрмәсеннәр дип кенә хафаланабыз.

Ленин. Ялгышыбыз коммунизм төзүдә булса да, без империянең нигезенә тап төшермәдек!

Сталин. Безнең кебек империя тота белгән кеше юк әле ул!

Чыңгыз хан. Тс-с-с! Бик кычкырмагыз! Әкренләп очына чыгарбыз. *(Ишектән керә-керә сөйли.)* Шулай итеп, комиссия утырышына йомгак ясап, алдагы мәсьәләләргә күчәбез. Чыгыш ясаучыларның сөйләү кысаларын ачыклыйк. Доклад сөйләүчеләргә — биш минут, сүз куертучыларга — бер минут. Тавышка куям. Кем дә кем, доклад сөйләүчеләргә биш минут вакыт бирергә, ә сүз куертучыларга — бер минут, ди, кулларын күтәрсеннәр!

Барысы да бердәм кулларын күтәрәләр.

Брежнев. Единогласно!

Чыңгыз хан. Беренче мәсьәлә буенча сүз миңа бирелә. (*Пауза.*) Хөрмәтле Җир Асты Татар империясе Югары Шурасы, данлы хөкүмәт галиҗәнаплары, тигезләр арасында тигезләрнең, олуглар арасында олугларның фикер кабызучысы даирәчесе — Чыңгыз хан! *(Үзенә ишарәләп куя, эчке ләззәте кыяфәтенә чыга.)* Тәҗрибәм буенча гыйбрәтле тәкъдимнәр әйтә алам дип исәплим. Шуңа күрә иң беренче итеп сүзне миңа бирүегез игътибарга лаек. Ышанычыгызны акларммын кебек. (*Пауза.*) Галәм вә барча җиһан безнең рух белән тулган. Бу рухның җитәкчесе кодрәтле Аллаһы Тәгалә алдында баш иеп, инде әйтeләчәк сүзләргә күчәм. (*Пауза.*) Рух! Эш бу рухның нинди булуында! Изге рухмы ул, әллә кара рухмы — без аны һәрвакыт аера белеп яшәдек. Безнең рух җирдә Исламны тудырды. Шуның аша безгә иман керде. Минем сәфәр юлларын хәтерләгез! Дөньяның күпме өлешендә минем җан газапларым, рухи кардәшләрем, иман таләпләрем иңеп калдылар! (*Пауза.*) Бөек Татар империясен төзү чаткылары минем заманга барып тоташа!

Гитлер. Регламент!..

Чыңгыз хан. Хәзер тәмамлыйм. Бу — кешелек өчен иң дөрес, иң алдынгы караш һәм бердәнбер юл иде. Ләкин безне аңламадылар… Шул. Мин бөтенесен әйттем. *(Шикле карашын Брежневка төбәп туктап тора.)* Хуш! Кемнәр дәвам итә? Рәхим итегез, Сөйкемсез Иван!

Иван Грозный трибунага чыга.

Иван Грозный. Хөрмәтле Югары Шура рәисе, Бөек Татар империясе даирәчеләре, парламентарийлар! Без империяне төзедек, ул яши, әмма ләкин төзү белән яшәү бер нәрсә, аны саклап кала белергә дә кирәк. Без үзебезнең ялгышлардан сабак алып яшик. Ни өчен өстә империя таркала? Чөнки барлык мәктәпләрдә дә бер дин кертелмәгән. Үзәк гомер буе бу эшкә тиешле ярдәм күрсәтмәде, үз мәнфәгатен, үз кесәсен генә кайгыртып яшәде. Безнең монда

эш бөтенләй икенче төсле куелырга тиеш. Без көчләп, атып, суеп үз империябездәге халыкларны бер дингә кертергә тиешбез.

Чыңгыз хан. Без сезнең нинди динне күз алдыгызда тотканны беләбез, хөрмәтле Сөйкемсез Иван. Халыклар дуслыгына балта чапмагыз! Бу трибунада андый сүзләргә урын юк!

Иван Грозный. Сез үзегез дә, галиҗәнап, бу эштә үрнәк күрсәттегез бугай. Сезнең җир өстендә кылган гамәлләрегез яман фикерләр уята.

Чыңгыз хан. Өстәгеләр ялгыш фикер тудыралар, ягъни аларның үз мәнфәгатьләрен кайгыртып эшләгән уйдырмалары хәзер челпәрәмә килеп беттеләр.

Иван Грозный. Сез берничә хатын белән торган дип…

Чыңгыз хан. Уйларыгыз ялгыш! Сезнең вакытыгыз бетте. Үзеңнең тугыз хатыныңны, ике йөз кырык сөяркәңне бел! *(Брежневка ишарә ясап.)* Чит кеше янында телеңне тыебрак сөйләшсәң әйбәтрәк булыр! Сүз ханбикә Сөембикәгә бирелә.

Сөембикә. Бәлки, мин мәртәбәле җыелышта бу турыда сүз куертырга тиеш тә түгелдер. Әмма ләкин, Сөйкемсез Иван сүз алгач, мин дәшми кала алмадым. Сөйкемсез Иванның кылган гамәлләре халкыбызга мәгълүм. Татар милләтенең Җир Асты империясенә агылуына ул иң зур өлеш керткән кеше. Моны танырга кирәк, җәмәгать! Шуңа күрә бу зат *(Брежневка күрсәтеп)* алып килгән медальләрнең зур күпчелеген аңа тагыйк.

Чыңгыз хан. Көн тәртибенә якынрак килеп сөйләгез, Сөембикә ханбикә! Бүген бүләк бирү тантанасы түгел, бүген Татар империясенең киләчәге турында ватанпәрвәрләрнең җан атып сөйләшүе!

Сөембикә. И Бөек Шурабыз рәисе! Минем сүзләрем шул турыда түгелмени? Җир өстендәге эшләребез белән мондагысы шул ук бер эшнең дәвамы түгелмени? Менә катнаш никахлар мәсьәләсе. Моны СССР империясе императорлары Пеләш Малай, Мыекбай, Кукуруз Малай һәм, гафу итегез *(Брежневка күрсәтеп)*, исемегезне белмим, шулхәтле куаныч белән эшләделәр ки, татарлар өстә генә түгел, хәтта аста да кими башладылар. Шуңа күрә мондагы халык башка милләтләр хисабына үсә башлады. Ә бит башка милләтләрне татар итү өчен күпме чыгымнар тотыла. Уку-укыту эшләре, китаплар бастыру, кадрлар әзерләү, матбугат тоту һәм башкалар, һәм башкалар… Шуңа күрә мин катнаш никахларга тешем-тырнагым белән каршы.

Чыңгыз хан. Сезнең вакытыгыз бетеп килә.

Сөембикә. Хәзер төгәллим. Туры әйткән туганына ярамаган, ди татар халык мәкале. Бер баскач, әйтеп бетерим, югыйсә сез миңа сүз бирмисез. (*Пауза.*) Менә тагын бер мәсьәлә: менә сезнең оныгыгыз Бату хан христиан империясе Римда, «Сникерс корпорейшн» концернында…

Чыңгыз хан. Микрофонны алыгыз!

Сөембикә, микрофоннан тавышы ишетелмәгәч, тузынган була, авыз эченнән нәрсәләрдер мыгырданып кала.

Сүз Пәхер Беренчегә бирелә.

Петр I. Империяне ныгыту өчен башка илләрнең алдынгы тәҗрибәсенә таянырга кирәк. Татар империясенә Кара һәм Балтыйк диңгезе, Тын һәм Атлантик океан ярларындагы диңгез флотларын көчәйтергә кирәк. Үз акчасын, үз фәнен, үз галимнәрен кабат барлап чыгарга тиеш. Мәдәниятне, мәгърифәтне алдынгы илләр дәрәҗәсенә күтәрергә, Себер һәм башка җирләрдә казылма байлыклар эзләүне, сәүдәне көчәйтү зарур. Барлык эшләрдә дә дәүләт монополиясенә таяну мөһим. Татар империясенең киләчәге — бердәмлектә һәм хәрби көчтә. Татар армиясен, аның флотын үстерү — безнең төп бурыч!

Чыңгыз хан. Афәрин, Пәхер! Сүз алучылар бармы? Рәхим ит, Бонапарт әфәнде Одеколон!

Наполеон. Хөрмәтле коллегалар! Бөтен тормышның яме үз хыялларыңны тормышка ашыруда. Татар империясенең дә максаты шул булырга тиеш. Әгәр без гүзәл җир астында вә куәтле, вә бердәм империябезне төзи алганбыз икән, димәк, безгә, җирнең өске кабыгын алып ташлап, калкып чыгарга кирәк. Җирдә мәхшәрләр күп булды, ләкин әле мондые булмады. Эшлик без аны. Яратам көтелмәгән хәрәкәтләр ясарга.

Ленин. Бирегез миңа Җир шарында таянырлык бер нокта, бөтен җир шарының астын өскә әйләндерәм!

Чыңгыз хан. Пеләш Малай, сезгә сүз бирелмәде. Дәвам итегез, Одеколон!

Наполеон. Мин үземне бөтен Татар империясенең императоры дип игълан итәм!

Чыңгыз хан. Әлегә император сайлауга күчмәдек. Утыр, Одеколон! Пеләш Малай, сүз сезгә.

Ленин. Татар халкының хыялы тормышка ашты! Без, коммунистлар, аны гомер буе әйтеп килдек. Татар империясе көчәйсен һәм чәчәк атсын өчен коммунистлар партиясенең берничә тәкъдиме бар: беренчесе — халыкка һава бүлеп бирү турында декрет; икенчесе — халыкка су бүлеп бирү турында декрет; өченчесе — бертеллелек турында декрет. (*Пауза.*) Ни өчен мин бу декретларны санап үттем? Дәлилләр китерәм. Карагыз, җир өсте ничек пычранды! Чүпләнде! Без сулыш ала торган тишекләр томаланды. Җир өстен пыяла, калай, пластмасса, үләксә басты. Инде бү-

ген өстән кешеләр дә коела башлады. Үзегез күрдегез. *(Брежневка ишарәләп.)* Шуңа күрә, һәр кеше үзенең хокукларыннан тулы файдалансын өчен, икегә бер метр чамасы җирдән һава бүлеп бирергә кирәк. (*Пауза.*) Су турында. Без эчә торган сулар хәзер эчәргә яраксыз, җәмәгать. Аңа йә аракы кушылган, йә ул сыра белән буталган. Спиртны — денатураттан, сөтне — катыктан, чәйне шампуньнан аерып булмый. Сулы фенолда коенабыз, комганнарыбызга нефть утыра. Наполеонның ыштанын төшереп карасагыз, үзегез дә ышанырсыз. Минем тәкъдим — самогон аппаратларын эшкә җигеп, чиста су кудырырга. Моны империя масштабында хәл итәргә кирәк. (*Пауза.*) Тел турында. Гомумән, телне тыярга кирәк. Бик күп сөйләшә башладык. Аста бер генә тел булгач, алар гына лыгырдыйлар иде, калганнары урысча белмәү сәбәпле тик кенә утыралар иде, ә монда бөтенесе лыгырдый. Димәк, телне тыю декреты кирәк. Әйтик менә, Сөйкемсез Иван әллә нинди «суверенный урыс дәүләте» дигән сүзләр ычкындыргалый. Минем исәбемчә, бу бик каты лыгырдауга керә. Андыйларның йә телен кисәргә, йә…

Сөембикә. Болай да күп тыйдыгыз, күп кистегез инде. Ичмасам, монда, аста сөйләшеп калыйк.

Чыңгыз хан. Сөембикә ханбикә, сезгә сүз бирелмәде. Бераз тыйнак булыгыз! Пеләш Малай, сезнең вакытыгыз бетте.

Ленин. Бер генә минут, хәзер бетерәм. Телне кисәргә һәм тагын бер нәрсәне…

Чыңгыз хан. Чамалап сөйләшегез, Пеләш Малай! Онытылып китәсез. Бу сезгә шалаш корып фин сыерлары көтеп ята торган урын түгел. *(Пауза.)* Сүзне Кытай Малайга бирәбез.

Мао. Бөек Халык Шурасы! Үземне сайлап җибәргән Кытай татар провинциясеннән кайбер тәкъдимнәремне кертермен дип уйлыйм. Бөек Конфуций тәгълиматларына таянып фикер йөрткәндә, татарлык ул барыбызның да күңелендә бар. Аны инкяр итеп булмый. Татарлыкның башы да бит әле безнең провинция тирәләреннән башлана. Татарлык ул — бераз гына кытайлык та, монголлык та, урыслык та, немеслек тә, яһүдлек тә, французлык та. Менә нәрсә ул татарлык! *(Пауза.)* Без монда җыелып Бөек Татар империясенең киләчәктә яшәү кануннарын яңартып маташабыз. Бөек Конфуций «Һәрнәрсә кабатлана һәм яңадан әйләнеп кайта!» дигән. Шулай булгач, безгә монда матур гына яшәргә кирәк. Әгәр чыннан да кабат өскә кайтсак, кызарып торырга туры килмәсен. Ә анда әйтербез, тату яшәдек, дип. Көнләшеп үлсеннәр. Безнең монда төзегән җәмгыятебезгә кызыксалар, тизрәк үләргә тырышырлар.

Чыңгыз хан. Рәхмәт, Кытай Малай! Хөрмәтле парламентарийлар, Кытай Малайдан үрнәк алыгыз! Үз вакытын ул төгәл кулланды.

Мао. Минем беттемени инде?

Чыңгыз хан. Бетте, бетте. Сүзне Халыклар Атасы Мыекбай ала. (*Сталин, гадәттәгечә, авызына трубка кабып, ашыкмый гына сүз башларга уйлый.*) Халыклар Атасы Мыекбай, сезнең вакытыгыз бетеп килә!

Сталин. Бу турында иптәш Фашист Малай ни уйлый?

Гитлер. Бөек Татар империясе канлы сугышларда үзенең императорына таянырга тиеш! Мин моны халкым өчен янып-көеп йөргәнгә күрә әйтәм. Одеколон инде үзенең кандидатурасын күрсәтте. Ләкин без, милләтебезнең язмышы кыл өстендә торганда, битараф булып утыра алмыйбыз. Безнең партия — Милли Көч партиясе исеменнән мин үземнең кандидатурамны тәкъдим итәм. Милләт ул иң беренчеләрдән — бөек юлбашчы!

Чыңгыз хан. Без әле кандидатуралар күрсәтергә барып җитмәдек. Кисәтеп куям.

Сталин *(Гитлерга).* Әйдә, мин сиңа бер уен тәкъдим итәм. Әгәр җиңәсең икән, син — император, җиңелсәң — мин.

Гитлер. Нинди уен?

Сталин. Җир алышы. *(Кесәсеннән пәкесен чыгара.)* Хөрмәтле Шурадан рөхсәт сорыйм. Рөхсәт итегез бу мөһим мәсьәләне вакытында хәл итәргә! Милләт язмышы кыл өстендә торганда, каршы килүчеләр булмастыр. *(Астыртын гына һәммәсен йөзе белән сөзеп чыга.)* Фашист Малай ни уйлый? Ризамы?

Гитлер. Риза!

Сталин *(идәннән түгәрәкләп ак таш белән җир бүлеп ала).* Мин пәкене синең җиргә ыргытам, очы белән кадалса, шуннан үземә җир бүлеп алам. Әгәр мин кадата алмасам, син минем җиргә пәкене ыргытасың, кадалса, үзеңә җир бүлеп аласың. Кем алдан үзенә бөтен җирне алып бетерә, шул җиңүче була. Кем башлый? Жирәбә салабыз. Юк, жирәбә түгел. Син инде бер уенны кырык беренче елда беренче булып башлаган идең, бу юлы мин башлыйм.

Уен башлана. Башта Сталин яхшы гына җир бүлеме эләктереп ала, аннан соң Гитлер. Кызып китәләр, сугыша ук башлыйлар. Башка парламентарийлар да бу бәргәләшүгә катнашып китә. Югары Шура ике лагерьга бүленә. Брежнев доклад укый башлый.

Брежнев. Советский народ и его победоносная Красная Армия нанесли сокрушительный удар по фашистской Германии, именно на малой Земле, там, где как тигр сражался. Я — сын великого народа, строителя коммунизма!

Чыңгыз хан. Туктагыз! Карагыз әнә! Яңа юлбашчыгыз барлыкка килә түгелме?

Иван Грозный. Бәреп төшерегез үзен!

Петр I. Андый сүзләр өчен без тел кисә торган идек!

Сөембикә. Сөйләсен, сөйләсен!

Үтәмеш. Тел төбен капшап карыйк.

Наполеон. Нинди сугыш турында сөйли ул?

Екатерина II. Мин мондый генералны белмим.

Брежнев. Хенералиссимус! Родная коммунистическая партия наградила своего сына еще одним орденом Золотой Звезды и званием Героя Советского Союза.

Ленин. Тезислар дисәң, тезис түгел, вәгазь дисәң, вәгазь түгел… Бер ычкынган фанатик микән әллә бу?..

Мао. Андыйлар җир йөзендә күп инде хәзер. Ничек булса да моны татарчага өйрәтеп карарга кирәк. Бабасы теле бит чүтеки. Бәлки, кем икәнен белербез.

Сталин белән Гитлер тыннары кысылып, сугышып арыйлар да, ниһаять, туктыйлар.

Гитлер. Син Сталинград янында да хәрәмләштең. Арттан килеп бәрмәгән булсаң... Курск янында да баш белән төрттең. Югыйсә маңкаңны чыгарадыр идем. Аяк чалудан башканы белмисең.

Сталин *(Гитлерның кесәсеннән кулъяулыгын алып бирә)*. Мә, салага, борыныңны сөрт.

Тагын сугыша башлыйлар. Башкалар боларны аералар.

Чыңгыз хан. Ярый, тынычланыгыз! Сүзне Кукуруз Малай ала.

Хрущев *(ботинкасын салып, кулына тотып трибунага менә. Ботинкасын болгый-болгый сөйли башлый).* Милләт нык булсын өчен аны эшләтергә кирәк. Яңа эш урыннары булдырырга, мәсәлән, чирәм җирләр. Соңгы вакытта өстән килүчеләр бик күп көтелә. Шуңа күрә аларны чирәм җирләргә җибәрергә кирәк. Мондагыларны да куарга кирәк.

Барысы да. Ничек итеп?

Хрущев. Колхозларны, совхозларны эреләндерергә! Шулай итсәң, үзләреннән-үзләре китәләр алар. Эш — милләтнең тоткасы! Татар кешесе гомер-гомергә эш яратты, ул эштән курыкмый. Шахтада да алар, күктә дә, диңгездә дә. Менә кукуруз ашауга гына күнегә алмыйлар. Хәер, монда кукуруз юк, ул булмагач, дуңгыз да юк. Ул дуңгыздан үзем дә биздем инде. Хәзер ат ите генә ашап торам. Рәхмәт. Инде татар булуыма горурланам! Дустым Гагарин да монда килгәч эчми башлады, өчпочмак пешереп, кымыз эчеп кенә ята.

Екатерина II. Соңгы вакытта милләтебезгә зур куркыныч яный. Үзегез карагыз әле, арагызда татар милләтенең таза-сау токымын дәвам итәрлек нәселле бер ир-зат бармы? Юк! Җыеныгыз карт-коры. Без монда Сөембикә белән ни кыра алабыз?.. Берегездә бер иман әсәре юк. Сезнең белән йоклау түгел, янәшә басып торырга да оят. Барыгыз да гырлый. *(Брежневка.)* Син гырламыйсыңмы? Храпишьмы, дим?

Брежнев. А как же!

Екатерина II. Менә карагыз, бу да гырлый. Каян килсен ди ул «императорчиклар»?

Брежнев. Храп спас человечество от гибели. Как вам известно, в глубокой древности, когда еще люди жили в пещерах, они спали у костра. Ближе к огню располагались женщины и дети, а чуть дальше от них по наружному периметру — мужчины. И храпели. От этого храпа дрожала земля. Хищники боялись не только напасть на них, но и подойти близко к пещере. Этот природный инстинкт самосохранения и сейчас имеется у мужчин. Поэтому с уверенностью можно сказать: настоящий мужчина тот — кто храпит!

Сталин. Тел төбен аңлап булмый бу бәндәнең.

Гитлер. Әллә без аңгыра, әллә бу ни сөйләгәнен үзе дә белми.

Мао. Кесәләрен тикшерергә кирәк. Докладтан башка тагын нәрсәсе бар икән?

Хрущев. Кукуруз чәкәне белән башына бәреп миңгерәүләтик алайса. Айныганчы әфтиякләренә күз төшереп алырга өлгерәчәкбез.

Чыңгыз хан. Хөрмәтле Югары Шура әгъзалары! Сабырлык белән тыңлыйк әле әфәндебезне! Бәлки, ул аның безнең каршыда ясаячак фикер нигезләмәләре, ягъни мәсәлән, якты киләчәгебезгә мәдхиянамәләредер.

Брежнев. Я самый большой энтузиаст настоящего храпа, особенно тогда, когда по-черному поддатый. На земле все люди этим делом увлекаются. Я с уверенностью заявляю и горжусь тем, что являюсь отцом коммунистического храпа. Вся страна, весь социалистический лагерь, весь народ храпел. Храпежный коммунизм, окруженный волчьей стаей капитализма, спокойно спал. Сон — это спокойное состояние людей, человечества и общества. Я вас призываю…

Биредәгеләрне гипнозлап йоклата башлый. Шул вакыт Чыңгыз хан айнып китә.

Чыңгыз хан. Регламент! Җитте, җитте!

Брежнев. Меня никогда не перебивали. Я еще не закончил свое вступление.

Сталин. Бу мөртәт, коммунизм турында сөйләп, безнең аңны кабат агулап алды.

Хрущев. Мин бит үземне яңадан генсек дип торам.

Ленин. Коммунизм идеяләре алар мәңгелек!

Чыңгыз хан. Шулай итеп, хөрмәтле Югары Шура әгъзалары һәм… *(Брежневка карап)* күп чыгышлардан соң шундый нәтиҗә ясарга була: сез империя язмышына берегез дә битараф түгелсез. Бу бик куандыра. Шулай итеп, көн тәртибендәге беренче мәсьәләне уртага куеп сөйләшүне һәм фикерләр йөртүне төгәлләргә кирәк дип саныйм. *(Пауза.)* Чыннан да, милләтебезгә император кирәк. Ә хәзер кандидатураларны тикшерәбез. Үземнең кандидатура турында… Хөрмәтле Югары Шура әгъзалары! Инде өлкән яшьтә булуымны сәбәп итеп, мин үземнең кандидатурамны кертмәскә булдым. Мине яклап алдан ук тавыш бирүчеләр булган булса, гафу үтенәм, аларга ихтирамымны белдерәм, рәхмәтемне әйтәм. Минем үрнәкне башкалар да кабатлый алалар.

Сөембикә. Хөрмәтле Олуг Шура рәисе! Олуг дисәм дә, сезнең беренче булып курка калуыгыз бу ихтирамга тап төшерде. Бәлки, мине дә әйтеләчәк сүзләремнән соң тәнкыйть утына күмәрсез. Татар халкының бу олуг урынга бердәнбер лаеклы ханбикәсе булсам да, мин бу вазифадан үз иркем белән ваз кичәм. Император булу ул хатын-кыз эше түгел. Император булу ул — башка милләтләрнең, дәүләтләрнең иркен кисү, чикләү, изү! Мин андый катылыкка бара алмыйм. Мин үз кыйблама беркайчан да хыянәт итмәдем һәм итмәм дә. Империя ул татар халкына хас нәрсә түгел. Татар ул эш һәм ирек ярата. Сез ханбикә күңелен түгел, Ана күңелен аңлагыз! Мин Үтәмеш хан файдасына үз кандидатурамны сезнең тикшерүгә тәкъдим итмим.

Чыңгыз хан. Рәхмәт, ханбикә! Мин сезнең теләгегезне уртаклашам. Сөйкемсез Иван, сезнең нигезләүләрегез?

Иван Грозный. Гадел һәм Бөек Татар империясе Шурасы рәисе! Мин үземнең татар токымыннан икәнлегемне зур горурлык белән тагын бер тапкыр игълан итәм. Татар империясен татар кулы белән генә төзеп була! Татарның иң гүзәл һәм батыр ханбикәсе Сөембикәнең миңа карата ачулы фикерләрендә тирән мәгънә ята. Әйе, мин ул халыкны канга батырдым, мин аның сатлык ханнарын яратмадым һәм әлегә кадәр күралмыйм. Без аларны суеп-кисеп җир астына тутырдык. Болар барысы да мондагы империяне ныгыту, аның халкын күбәйтү хакына эшләнде. Әйтегез, моңа кайсыгыз шушы кадәр өлеш кертте? Ха-ха-ха! Юкмы?.. Юк шул. Хәзер ул империя чәчәк ата. Тагын җир өстендәге алты-җиде миллион татар килсә, без Аллаһы Тәгаләбез үзе дә көтмәгән галәмәт зур эш эшләп ыргытырбыз. Бөек Җир Асты Татар империясе төзибез. Аның императоры мин булмыйча кем булсын?!

Чыңгыз хан. Пәхер Беренче, трибунага рәхим итегез!

Петр I. Минем нигезләмәләрем. Теләсә нинди юл белән империянең көчен арттыру. Икътисад, сәясәт, фән, флот, армия, кадрлар, алдынгы технология, дөнья базарлары һәм миңа ышаныч!

Чыңгыз хан. Сезнең беттеме?

Петр I. Әйе.

Чыңгыз хан. Бонапарт Одеколон, сүз сезгә.

Наполеон. Татар хөкүмәте даирәләренә талашып яшәү, көнләшеп эш итү хас. Шуңа күрә ничәмә-ничә еллар, гасырлар буе ул үзенең бер генә юньле юлбашчысын да хәтерләми. Болай яшәү хәлсезләндерә. Әгәр безнең империяне нык һәм көчле, бүленмәс һәм таркалмас итеп төзисебез килә икән, безгә чит төбәкләрдән килгән талантлы, абруйлы полководецларга мөрәҗәгать итәргә кирәк. Алар бар. Һәм ул кешеләрнең берсе мин булырмын!

Чыңгыз хан. Ярый, шулай да булсын ди. Алга таба кемнең нигезләмәсен тыңлыйбыз?

Ленин. Тарихны аерым шәхесләр генә ясамый. Хәер, шәхеснең дә тоткан урынын инкяр итәргә ярамый. Без бу эштә бөтен бер партиягә таянабыз. Ул партия бар! Аның исеме — Коммунистлар партиясе! Аның тәгълиматлары чиста һәм изге! Тик аларны боздылар гына. Ул тәгълиматларны үтәүдән аерым шәхесләр читкә тайпылдылар, булдыксызлыкны җәмгыятьтән күрделәр. Социалистик җәмгыять үзенең ныклыгын канлы бәрелешләрдә исбатлады. Әйе, исбатлады, хәтта аның белән аерым сәләтсез юлбашчылар идарә итсәләр дә, әйе, әйе, Сталиннар, Хрущевлар һәм менә бу да. *(Брежневка күрсәтә.)* Әйттем мин сезгә Сталинны куймагыз дип…

Сталин. Картлач ычкынган, психбольницага озатырга кирәк үзен.

Хрущев *(ботинкасын салып, Ленинга кизәнә башлый).* Синнән калган сәләмә илне, җәмгыятьне җимергәнгә рәхмәт әйт!

Брежнев *(медаль тотып Ленин янына килә. Ленинның үзенә һәм аның медальдәге сурәтенә күрсәтеп).* Я — Ильич, ты — Ильич, это ты в самом деле Владимир Ильич что-ли? На тебе, дарю. (*Медаль тага.)* Надо же, Ильича встретил. Давай встречу отметим!

Чыңгыз хан. Утыртыгыз әле шуны урынына. Кытай Малай, сүз сезгә.

Мао. Монда кемгә карама — шул император. Ә менә татарның әле үз империясендә бер генә дә император булганы юк. Шуңа күрә мин тыйнак кына үземнең кандидатурамны тәкъдим итәм. Куймасалар, үпкәләмим. Мин барыбер үзебездә дә бер әйбер дә эшләмәдем, чәй эчеп кенә яттым, бака ашап…

Чыңгыз хан. Башка кандидатуралар бармы?

Сталин *(салмак кына).* Мин бардыр дип уйламыйм. Бу турыда иптәш Гитлер-Фашист Малай ни уйлый?

Гитлер. Нәкъ шулай уйлый!

Сталин. Шулай уйламаса, без аны… Башка төрле уйлаучылар бармы? *(Җайлап кына трубкасын тарта. Брежнев янына килеп.)* Син нәрсә уйлыйсың? *(Брежнев гырлап йоклый.)* Иң куркыныч һәм иң шикле зат!.. *(Пауза.)* Императорлык ул берни эшләми бака ашап яки гырлап йоклап яту түгел. Ул — титаник эш! Сөйкемсез Иванның сүзләрендә мин күңелемә якын ризык табам, татулык күрәм. Мин дә бит мондагы империяне ныгыту өчен күпме татар башын ашаган кеше. Аларны мин төрмәләрдән, лагерьлардан йөзәр меңләп бу дөньяга озата идем. *(Пауза.)* Алар барысы да, «Сталин өчен!» дип, Фашист Малайның утлы иттурагычына ташландылар. Татарлар аеруча әтәчләнеп утка керделәр. Шуларның күпмесе өйләренә кайтмыйча туп-туры Җир Асты Татар империясенә коелды. Миннән бөтен дөнья өркеп торды. Хәзер дә шулай булачак. Язмышыгыз кем кулында буласын үзегез сайлагыз! Һәркемнең бүгенге тәртибе — киләчәккә стратегия!

Чыңгыз хан. Сез кеше вакытына керәсез, вакытыгыз бетте.

Сталин. Без беркайчан да кеше хисабына яшәмәдек һәм бервакытта да кеше кесәсенә кермәдек. Без үзебезнең ни эшләгәнне һәм ни эшләячәгебезне белеп торабыз. Безне өйрәтергә кирәкми, җанкисәк Чыңгыз хан!

Чыңгыз хан. Бу сезнең мәсхәрәләвегезме?

Сталин. Юк, галиҗәнап, Югары Шура рәисе вазифаларыннан үз мәнфәгатегезгә файдалануыгызны искә төшереп үтте дип кенә кабул итегез.

Чыңгыз хан. Кандидатларны тыңлау дәвам итә.

Трибунага Гитлер чыга.

Гитлер. Чыгышымны мактаудан башлыйм. Рәхмәт, Мыекбай! Минем кандидатурамны яклаган кебек булды соңгы сүзләрең.

Сталин. Салпы якка салам кыстырма! Без аңа мохтаҗ түгел.

Гитлер. И кодрәтле парламентарийлар! Бирегез миңа ун ел вакыт! Ул миңа империянең барлык теләкләрен тормышка ашырырга җитәр. Тарих шаһит. Мин өстә ун ел эчендә бөтен Җир шарының астын өскә әйләндерә яздым. Ялгышлар бар барын. Ә кем бу дөньяда ялгышларсыз яши ала? Кем әүлия? Әүлияләр юк! Татар империясе — минем күптәнге хыялым. Исегездәдер, өстә чакта мин татарларга Идел-Урал Штаты төзергә булышмакчы идем. Тыңламадылар. Инде менә тарих тагын бер мөмкинчелек бирә. Ышаныгыз миңа һәм билгеләгез мине бу империянең фюреры итеп! Ул сезгә күрмәгәнегезне күрсәтер!

Чыңгыз хан. Беттеме? Башка кандидатураларны тыңлыйбыз.

Трибунага Хрущев чыга.

Хрущев. Минемчә, бернинди олуг эшне дә хәрби күзлектән чыгып хәл итәргә ярамый. Аның бит йомшак кына җәеп катыга утырта торган ысуллары да бар. Әйтик, кукуруз стратегиясе! Кукурузны чәчәсең дә җыясың, чәчәсең дә җыясың. Дуңгыз үрчетәсең. Дуңгыз ашаган татар бик тиз кырыла башлый бит ул. Өстә кырылса, аста ишәя генә. Империябезнең халкы ишәюдә минем өлеш гаять зур. Император итмәсәгез дә, президент итәргә була торгандыр бит инде мине. Президент булу хәзер бик модно!

Чыңгыз хан. Сез, Йокычиренә, үзегезне артык тыйнак тотасыз кебек. Кандидатурагызны кую турында уйламыйсызмы?

Екатерина II. Андый теләк юк түгел. Ләкин тора-бара тынгы бирмәсләр дип уйлыйм. Чөнки хатын-кызга Татар империясенең императоршасы булып тору аеруча авыр. Хатын-кызны бик өнәп бетерми бит ул татар халкы. Шуңа күрә әлегә мин уйланам, бәлки, менә бу иптәшне *(Брежневка күрсәтә)* куярга кирәктер. *(Башкалар шаулаша башлыйлар, ризасызлык күрсәтәләр.)* Как тебя зовут?

Брежнев (әйткән сүзе аңлашылмый). Брежнев!

Екатерина II *(барысына тәрҗемә кылып әйтә)*. «Брежнев» ди. Тегендәге последний император.

Брежнев. Хенеральный секретарь, хенералиссимус! *(Медальләренә күрсәтеп.)* Че, не видишь что ли?

Екатерина II. Императором хочешьмы?

Брежнев *(башын селки)*. Аха, хочу!

Чыңгыз хан. Башта татарча өйрәнсен!

Барысы да. Башта татарчасын өйрәнсен!

Чыңгыз хан. Шулай итеп, тугыз кандидат җыелды. Сайлау кәгазьләрен таратабыз! Тәртибе мондый: сайларга теләгән кешегезнең исемен исемлектә калдырасыз, ә теләмәгәннәрне — сызасыз.

Кәгазьләр тараталар.

Екатерина II. Олуг Шура рәисе, Чыңгыз хан! Сезнең тарафтан укып кителгән көн тәртибенә икенче итеп Сөйкемсез Иванның Мәскәү тирәсендә урысларның Татар империясе белән ассоциацияләнгән автономиясен төзү турындагы гаризасын тикшерүне кертергә иде.

Чыңгыз хан. Бүгенгә вакыт бетте, баш катырып йөрмәгез әле. Бүтән тәкъдимнәр юкмы? Юк. Бүгенгә Шура утырышы тәмам. Иртәгә, көннең икенче яртысында, сайлау нәтиҗәләрен сезгә комиссия әгъзалары игълан итәр. Иртәгә кадәр тәнәфес.

**Икенче күренеш**

Мәктәп. Класс. Парталар. Беренче сыйныф укучылары укый торган партада Брежнев дәрес өйрәнә. Екатерина II — аның укытучысы. Кара тактага урыс алфавитында булмаган алты хәреф язылган.

ЕкатеринаII *(тактадагы хәрефкә төртеп)*. «Ә» хәрефе, ә.

Брежнев. А.

Екатерина II. Ә, ә!

Брежнев *(һаман үзенчә)*. А.

Екатерина II. Аңгыра-а. *(Ачуы кабарып.)* Ә. Мә-ә! Сарык.

Брежнев. Нәрсә?..

Екатерина II. Кәбестә. Овечка, мәйтәм.

Брежнев. Э-э-э!

Екатерина II. Вот, молодец! Надан. Икенче хәрефкә күчәбез. «Ө» хәрефе. Ө-ө.

Брежнев *(авызын бүрттереп)*. О-о!

Екатерина II. Йомшак итеп, йомшаграк! *(Иреннәрен «ө» хәрефе төсле итеп кыландырып, авызын Брежневның иреннәре кырыена ук тери.)* Ө-ө.

Брежнев *(үбешү хыялы белән)*. Ө-ө-ө.

Екатерина II. Маладис! (*Маңгаеннан үбеп ала, шул вакыт Брежневның калын кашларына карап кала.*) Бу кашларыңны ябыштыргансың дип торам. Үзеңнеке икән. Хәзер өченче хәрефне өйрәнәбез. «Җ» хәрефе. Җ.

Брежнев. Жы, жы.

Екатерина II. Жы түгел, җе, җе.

Брежнев. Жды.

Екатерина II. Җүләр!

Брежнев. От такого слышу. Сама жулярка!

Екатерина II. Беренче дәрестә үткән сүзне кабатлыйк әле. Ну-ка? Сә-лам.

Брежнев. Са-лам.

Екатерина II. Менә молодец! Монысын беләсең. Бүгенгә өч хәреф җитеп торыр. Татар алфавитындагы калган хәрефләрне иртәгә өйрәнербез. Ә хәзер радиодагыча тиз сөйләшергә өйрәнү алымнарын үзләштерик.

Тәлгать әфәнде, әйтегез әле, сез базарга барасызмы?

Скажите пожалуйста. Талгат әфәнде, вы на базар идете?

Брежнев. Я не Талгат афанды.

Екатерина II. Нет, это понарошку. Вы как будто Талгат. Отвечайте!

Брежнев. Э, нәрсә калган анда миңа?

Екатерина II. Юк, сез тулы текст белән отвечайте! Мин — Гөлфия.

Брежнев. Юк, бармыйм, Голфия афанды.

Екатерина II. Әфәнде түгел, туташ, түти, апа.

Брежнев. Юк, Голфия туташ тути, тоташ тути дисез бит, дөресме?

Екатерина II. Сез мине уңайсыз хәлгә куясыз. Дөрес, дөрес!

Брежнев. Юк, Голфия туташ тути, мин базарга бармыйм, үзең барсаң, әбиеңә сәлам әйт, бабаң утырмага килсен!

Екатерина II. Нәрсә, нәрсә? Болтун! (*Ә үзе Брежневның чәченнән сыйпап куя.*) Хәзер сиңа намаз уку тәртипләрен өйрәтергә Үтәмеш хан килер.

Чалбар каешына пәкесен ышкып, Үтәмеш керә. Екатерина II чыгып китә.

Үтәмеш. Син бит әле сөннәткә дә утыртылмагансыңдыр. (*Брежнев аптырап карап тора.*) Нәрсә шаккатып карап торасың? Утыртырга кирәк булыр, дим.

Брежнев *(шаккатып)*. Талгат афанды, сез базарга барасызмы?

Үтәмеш. Мин Талгат түгел, мин — Үтәмеш. Базарга барырга дип алмадым мин бу пычакны. Хәзер сине, Чыңгыз хан килгәч, сөннәткә утыртабыз. Иртәгәдән тәһарәт ала башларсың. Хәзер тәһарәт алу тәртипләрен өйрәтәм. Намаз укырсың, саваплы булырсың! Утыр юньләп! Менә сиңа беренче дәрес. Тыңла! (*Брежневны мөселманча итеп утырта-утырта интегеп бетә.*) Намаз укысаң, Аллаһының нигъмәтләренә түләп ашавыбыз, түләп яшәвебез була. Әгәр дә намаз укымасак, бушка ашаучы, бушка яшәүче булабыз. Шуның өчен, газиз туганым, намазга бик игътибарлы булыйк. *(Пауза.)* Намаз укыячак кешенең тәне, киеме вә урыны һәртөрле нәҗесләрдән пакь булмак лаземдер һәм шәригать боерган рәвешчә су илә тиешле әгъзаларын юып тәһарәт алу фарыздыр. Тәһарәт алганда ошбу сигез төрле эш кылыныр. (*Бөтенесен җентекләп аңлатып чыга.*)

Брежнев. Ә болай кирәк түгелмени?.. (*Чүгәләп, арт ягын юып күрсәтә.*)

Үтәмеш. Анысы иртәгә. Иртәгә мин сиңа госел тәртипләрен өйрәтермен.

Шул вакыт алар янына, кулына дисбе тотып, Сөембикә керә. Аңа Екатерина II ияргән.

Сөембикә. Кылган вә башлаган шөгыльләрегез хәерле догада булсын! (*Брежневка дисбе тоттыра.*)

Брежнев. Нәрсә бу?

Сөембикә. Бу — дисбе. Тәсбих. Менә шушыны тартып утыр! (*Дисбене ничек кулланырга кирәклеген күрсәтә.*) Утыз өч мәртәбә «Сөбханаллах», вә утыз өч мәртәбә «Әлхәмдүлилләһ», вә утыз өч мәртәбә «Аллаһу әкбәр» дияргә кирәк булыр. Эчеп йөрүләр бетте. Монда Татар империясе, ә аның үз тәртипләре. Әнә кара тәрәзәгә, очсыз-кырыйсыз татар киңлекләрендә татар каеннары үсеп утыра, кырларында — татар арышлары, татар урманнары, татар мунчалары, татар тургайлары, татар сандугачлары, татар җырлары, татар көйләре.

Ерактан җыр ишетелә.

Идел порты яннарында
Чайкала диңгез,
Чайкала диңгез.
Ил буйлап безгә кунакка
Дуслар, килегез.
Дуслар, килегез!

Мәскәү, Мәскәү,
Дәртле матур кала!
Башкалабыз Казаннан ул
Якты нур ала,
Якты нур ала!

Сөембикә. Күрдеңме, нинди матур җырлар!

Иван Грозный белән Петр I җырлап керәләр.

Нәфис мехлар, кара алтын
Төяп бүләккә, төяп бүләккә,
Теплоходлар, дулкын ярып,
Китә үзәккә,
Китә үзәккә!

Мәскәү, Мәскәү,
Дәртле матур кала!
Башкалабыз Казаннан ул
Якты нур ала,
Якты нур ала!

Алар янына түбәтәй киеп Ленин керә. Кулында үз томнарының берсе. Ул шигырь сөйли.

Казан әле Казан уянмаган.
Яфрак белән яфрак сөйләшә.
Йөрим таңда Сибгат урамында,

Күңелем Сибгат белән сөйләшә…

Шул вакыт Наполеон, Мао, Гитлер татар милли киемнәрендә «Өч дус» биюен биеп керәләр. Башкалар кул чабып алкышлап торалар. Биюдән соң Сталин белән Хрущев, түбәтәй киеп, шигырь укыйлар.

Сталин. Бер горурлык хисе яна миндә,
Эчтән бәреп яна битләрдә.
Сөйләр идем аны дөньядагы
Барлык-барлык парламентларда!

Хрущев. Кирәк булса, дөнья картасыннан
Кырык илне эзләп табармын.
Мин яшәгән Татар иле менә,
Күр, кайларга илтә тауарын!..

ЕкатеринаII (*җырлый*).
Көн саен берәр кыз белән
Таныша кайберәүләр.
Мәхәббәт эшендә шулай
Ярыша кайберәүләр.

Әй, егетләр, егетләр,
Танышасыз бик җиңел.
Көн саен алмаштырырга
Кызлар пирчәткә түгел…

Брежнев «Туган тел»не җырлый башлый. Аңа түбәтәй кидерәләр. Беренче куплеттан соң Брежневка башкалар да кушыла. Сәхнәгә Чыңгыз хан, Сөембикә, Үтәмеш чыгалар. Җырга алар да кушыла. Барысы да, җыр бетте дип, таралыша башлыйлар, ләкин Брежнев дүртенче куплетны да җырлый башлый.

Брежнев.
И туган тел! Синдә булган иң элек кыйлган догам:
Ярлыкагыл, дип, үзем һәм әткәм-әнкәмне, Ходам!
Барысы бергә. Ярлыкагыл, дип, үзем һәм әткәм-әнкәмне, Ходам!

**Өченче күренеш**

Өйлә намазы тәмамланып килә. Дога кылучыларның соңгы сүзләре яңгырый.

Барысы бергә. Раббәнә әтинә фиддун йә хәсәнәтән үә фил әхыйрәти хәсәнәтән үә кыйнә гәзәбәннәр. Бирахмәтикә йә әрхәмәр-рахимин.

Чыңгыз хан. Йә, җәмәгать, дога кылыйк. Амин. Югары Шурабыз Җир Асты Татар империясенең көн тәртибендәге мәсьәләләренә караган утырышның дәвамын ачык дип белдерергә рөхсәт итегез. Барыбыз да урыннарындамы? Кайда безнең Зур Каш?

Шул вакыт киңәшмә залына кулларын бот арасына кыстырып, чыраен сытып Брежнев керә.

Гитлер. Нәрсә булды, Зур Каш? Эчең китә мәллә?

Хрущев. Ул пес итә алмый бугай.

Чыңгыз хан. Игътибар итмәгез. Аны Үтәмеш хан әле генә сөннәткә утыртты.

Сталин. Чын күңелдән тәбрик итәм!

Иван Грозный. Котылуың белән!

Петр I. Әй, без дә курыккан идек…

Мао. Бака сидеге сөртергә кирәк, тиз төзәлә ул.

Сталин. Әнә Наполеон Ленинныкына үзе сиптерде, Ленин йөгереп йөри хәзер.

Үтәмеш. Шөкер, үзебезнең кеше булды.

Гитлер. Үзебезнеке икән. Юкка шикләнгәнбез.

Чыңгыз хан. Игътибар итмәгез дип әйттем бит инде. Утырышыгыз урыннарыгызга, утырышыгыз! Көн тәртибендә император сайлау һәм төрлесеннән.

Иван Грозный. Сез, олуг Чыңгыз хан, урыс республикасының Татар империясенә ассоциацияләнгән автономия булып керү турындагы минем гаризаны карарбыз дип вәгъдә иткән идегез.

Чыңгыз хан. Бу нәрсәне башка көнне эш тәртибендә генә карарбыз. Вакыт әрәм итеп тормыйк әле. Монда мөһимрәк эшләр дә җитәрлек. Бүтән борчымагыз! Сайлау комиссиясе рәисе, кичәге сайлау нәтиҗәләрен игълан итегез!

Трибунага Үзәк сайлау комиссиясе рәисе Мао Цзэ-Дун күтәрелә.

Мао. Сайлау кагыйдәләрен бозу очраклары күзәтелмәде. Бөтенесе дә әйбәт, демократик тәртиптә узды. Үзәк сайлау комиссиясе сезнең игътибарга тавыш бирү нәтиҗәләрен чыгара: Үтәмеш ханны яклап өч тавыш бирелгән, тугыз тавыш каршы, битарафлар юк. Башкаларны яклап берәр тавыш бирелгән, унберәр тавыш каршы. Битарафлар юк. *(Пауза.)* Зур Каш, сөннәткә сайлаудан соң утыртылу сәбәпле, безнең империянең тулы хокуклы бәндәсе булып җитешә алмады. Чыңгыз хан белән Сөембикә ханбикә, үзегезгә мәгълүм, кандидатураларын күрсәтмәделәр. Шулай итеп, Җир Асты Татар империясенең беренче императоры итеп Казан ханы Сафагәрәй һәм Сөембикә ханбикә улы Үтәмешгәрәй хан игълан ителә!

Сөембикә һәм Чыңгыз хан торып басып Үтәмешне тәбрикләп кул чабалар, башкаларның кәефләре кырыла. Кинәт алга, кискен хәрәкәтләр ясап, Екатерина II чыга.

Екатерина II. Юк! Юк! Һәм тагын бер тапкыр юк! Татар империясенең императоры булырлык кеше Үтәмеш кенә түгел! Түгел! Ул безнең нәселдә дә бар! Бар! Ләкин ул әле өстә хакимлек итә. Аның исеме — Барыс Җылсын! Ул минем Казан татарыннан туганнан туган оныгым — Барыс Җылсын!

Чыңгыз хан. Ул бит әле үлмәгән. Башта үлсен! Императорны тәбрик итеп алкышламаган, кулын килеп кысмаган бәндәләр үзләрен уңайсыз хәлгә куя күрмәсеннәр.

Барысы да бер-берсен уздырып, туктый алмыйча кул чабалар. Кул чабулар бик озакка сузыла. Үтәмеш горур рәвештә трибунага үтә.

Үтәмеш. Бөек Җир Асты Татар империясе парламентарийлары, җитәкче даирәләре, киң җәмәгатьчелек, газиз халкым! Ышанычыгызны акларкмын! *(Пауза.)* Ниһаять, татар халкы үзенең гасырлар буена хыялланган теләгенә иреште. Аның үз империясе, үз императоры бар. Безнең максат — ирекле җәмгыять төзү! Хокукый дәүләт төзү, халыкларның гомерлек хыялын тормышка ашыру. Ул нидән гыйбарәт: беренчедән, халыклар дуслыгын булдыру, икенчедән, кем күпме йота ала, шулкадәр демократия алу. Моның өчен нишләргә? Моның өчен үзара милли килешүгә кул куярга кирәк, бердәм бүленмәс Татар империясен ныгыту кирәк, үзара шартнамәләр, солыхлар төзү кирәк.

Иван Грозный. И бөек императорыбыз! Без инде берничә тапкыр халкыбыз исеменнән, дөресрәге, урыс исеменнән, үзебезнең дәүләтчелегебезне тергезү хакында империябезнең олуг юлбашчыларына күп тапкырлар мөрәҗәгать иткән идек. Хәзер бар өмет сездә. Безнең күпме байлыгыбыз үзәккә китә. Туксан сигез процент бит! Чыңгыз хан заманында да без бу хәтле коллыкта яшәми идек. Күрәләтә, көпә-көндез талау бит бу!

Чыңгыз хан. Ун процент түли иделәр һәм рәхәтләнеп кайгы белми яшәделәр.

Иван Грозный. Аллаһы Тәгаләдән шул вакытларның кире кайтуын теләп ялварам. *(Пауза.)* Безнең телебез бетеп килә. Сез үзегез беләсез, телен югалтса, милләт бетте дигән сүз. Монда милләтләрнең тигез хокукы турында сөйләшеп утыру буш сүз ул. Хәзер безнең егерме-утыз мең тиражлы өч-дүрт гәҗитебез калды. Урыс милләте җан акырып елый. Шуңа күрә ул хәзер кара янып көн-төн эчә башлады. Мондый идемени ул урыс халкы? Ул хәзер Алласын да, побын да онытты. Ул хәзер аларны беләсеңме куда посылает?.. Авызындагы бар белгәне — өч хәреф. Аның хәтта үз каены да, үз урманы да, үз кыры да, үз мунчасы да, үз чәе дә, үз самавыры да, үз кунакчыллыгы да, үз җәе дә, үз кышы да, үз салкыны да, үз җылысы да калмады. Барысы да татарныкы! Әйтерсең лә ул каеннар татарларда гына үсә, әйтерсең лә ул чәйне татарлар гына татар шикәре белән тәмле итеп эчә белә, әйтерсең лә ул салкын кышлар татарларга гына килә, әйтерсең лә ул татар карлары шул татар кышларында гына ява һәм башкалар, һәм башкалар…

Чыңгыз хан. Авызыгызны чамалабрак ачыгыз, Сөйкемсез Иван!

Иван Грозный. Ярар. Безгә хәзер сүгенергә дә сүзләр калмады. Мәктәпләрдә, балалар бакчаларында татарча укыталар, телевидение-радио көне-төне татарча сөйли, урамга чыксаң, урысча сөйләшергә кушмыйлар, «каля-маля» диләр. Урыс иҗтимагый хәрәкәтен милләтчелектә гаеплиләр. Кешеләрне көчләп сөннәткә утырту очраклары да юк түгел.

Брежнев. Ы-ы-ы! (*Еламсырап шыңшып куя.*)

Иван Грозный (*аны җәлләгән сыман*). Авыртамыни?..

Брежнев (*шыңшый*). Ы-ы-ы!

Петр I. Сиңа наркоз белән ясадылармы соң?

Брежнев. Наркоз белән.

Петр I. Сиңа әле чыдарга була. Минә безнекен, Сөйкемсез Иваннныкын, Одеколонныкын, Пеләш Малайныкын наркозсыз кисеп ыргыттылар.

Брежнев *(еламсырап)*. Ә Сталинныкын?

Петр I. Сталин бит әле ул кайчан гына үлде. Яшь бит әле ул. Аның вакытында наркоз уйлап чыгарганнар иде бит инде. Ул врачка кистерде.

Иван Грозный. Милләт мәсьәләсе хәл ителгәндә, сүзне икенчегә бормагыз әле. Сүз урыс дәүләтчелеге турында бара бит.

Петр I. Соң, Зур Кашныкы авырта бит. Дәүләт дигән булып халыкны болай да онyттык инде. Мескен халык ыңгыраша, соңгы сулышын җуя, ә без һаман «дәүләт» дибез. Халыксыз дәүләтнең нигә кирәге бар аның. Халыкка аңа ирек кирәк, ирекле империя кирәк!

Ленин. Безнең партия халык өчен барысын да эшләде! Электрификация планы гына ни тора!

Сталин. Безнең казаныш — индустриализация, коллективизация!

Хрущев. Һәм дә химизация!

Брежнев. Плюс коммунизм!

Мао. Культура революциясе!

Гитлер. Кырдыгыз ишәк чумарын! Бары тик безнең партия генә — Милли Көч партиясе генә кешелекне афәттән коткара!

Наполеон. Җыен шизик җыелган. Халыкны бары яулап алулар гына коткара. Анысы да әле мөһим түгел, иң мөһиме — маневрлар!

Екатерина II. Һәр эштә егетлек кирәк, егетләр кирәк!

Үтәмеш. Сез, галиҗәнаплар, көн тәртибеннән читкә тайпылдыгыз түгелме! Чыңгыз хан, мәҗлес утырышын тәртипкә китерегез!..

Чыңгыз хан. Хөрмәтле Югары Шура әгъзалары! Көн тәртибенең тагын бер мәсьәләсенә тукталабыз.

Иван Грозный. Безнең автономия мәсьәләсе…

Чыңгыз хан. Туктагыз әле, комачауламагыз, Сөйкемсез Иван әфәнде! Ул мәсьәлә көн тәртибендә юк ич, кертелмәгән.

Иван Грозный. Бәлки, төрле мәсьәләләр тикшергәндә, бу мәсьәләгә тукталырбыз?

Чыңгыз хан. Сезнең бу мәсьәләне куертырга хакыгыз да юк бит әле.

Иван Грозный. Бар!

Чыңгыз хан. Кем бирде аны сезгә? Андый дәүләт юк җир йөзендә. Әйе, җиде миллионлы урыс халкы бар. Әйе, сез үзегезнең белдегегез белән, Зур Каш әйтмешли, суеверенный дәүләт игълан иттегез, әйе, республикагызда ике теллелек кабул иткәнсез. Икегә, өчкә аерылып йөрсәгез дә, сезнең вәкаләтләрегез җитми, аларны сезгә бирергә берәүгә дә хокук бирелмәгән. Үзегез әйтәсез бит, без Татар империясе составында, аның нәкъ уртасында кечкенә дәүләт, дип. Беркая да очып китәргә җыенмыйбыз да, дисез. Шулай булгач, сезгә ни кирәк? Мин сезне аңламыйм. Әллә мин генә аңламыйммы сезне? Әнә императорга мөрәҗәгать итегез!

Иван Грозный Үтәмеш янына килә.

Иван Грозный. Бераз бәйсезлек кирәк иде.

Үтәмеш. Күпме булдыра аласыз, күпме йота аласыз, шулкадәр алыгыз, яме! Чыңгыз хан, бирегез әле шуңа сораган әйберен, тилмереп йөрмәсен!

Иван Грозный *(тиз генә Үтәмешкә урыс фуражкасы кигезеп куя)*. Сезгә урыс халкы исеменнән… Бирегез инде.

Үтәмеш. Ярый алайса, берәр шартнамә-фәлән төзербез.

Чыңгыз хан. Хөрмәтле Югары Шура әгъзалары! Көн тәртибендә безнең «төрлесеннән» дигән бүлек каралган. Монда сез кызыксындырган сорауларыгызны бирә аласыз. Минем дә бер тәкъдимем бар, сез аны якларсыз дип уйлыйм. Әле бит без килгән иптәшкә Югары Шура дәрәҗәсеннән, аның югарылыгыннан торып татарча исем кушмадык. Минем тәкъдимем шул: бу иптәшкә «Зур Каш» дип исем кушарга. Инде бу исем сезнең тарафтан бераз кулланылды да булса кирәк. Каршылар юкмы? Тавышка куеп тормыйм. Сүзне Зур Кашның үзенә бирәбез.

Брежнев. Тирән мәрхәмәтле иптәшләр! Су-е-ве-рен-ный Татар империясе Югары Шурасы әгъзалары, ягъни мәсәлән Политбюро членнары. Менә мин сезнең янга килеп җиттем. Сез мине яхшы каршыладыгыз, рәхмәт сезгә! Әле яңа гына килеп төшүемә карамастан, мин өстәге тормышны сагынам, ямансулыйм. Менә ничә көн, урыс әйтмешли, ни в одном глазу. Күрәм, сездә бәйрәмнәр юк. Ә бит бәйрәмнәр кирәк. Минем килеп төшүемне дә билгеләп үтүче булмады.

Чыңгыз хан. Татар империясендә «сухой закон». Эчү юк!

Брежнев. Монда шулай, эшләр хөрти. Без бутылки не разберешься. Анда да (*өскә күрсәтеп*) мин киткәч эшләр шәптән түгел. Халык интегә, зарплата түләмиләр, суеш, үтереш, фатирларны талыйлар, хатын-кызны көчлиләр, завод-фабрикалар эшләми, бөтен нәрсә мафия кулында, бөтен нәрсә җимерек хәлендә, гаеплеләр юк.

Иван Грозный. Үзем кайтам, тәртип урнаштырам.

Петр I. Юк, синнән булмый, булдырсам, мин генә булдырам!

Наполеон. Бер яхшы гына маневр кирәк!

Ленин. Кабат революция ясамый булмас, ахры.

Мао. Конфуций әйтә, дөнья кабатлана, ди.

Сталин. Мин кирәк аларга!

Брежнев. Алар да шулай ди. Өстә анда сине көтәләр!

Гитлер. Теге вакытта әйттем мин аларга, тыңламадылар. Хәзер Бавар сырасы гына эчеп яткан булырлар иде.

Хрущев. Халык сарык бит ул. Аңа минем кебек көтүчеләр кирәк!

Екатерина II. Барлык өмет хатын-кызда. Аларны бу упкыннан бары тик хатын-кыз гына чыгара!

Сөембикә. Халык бөек ул! Ул үз юлын табар! Аңа комачауламаска гына кирәк!

Үтәмеш. Барысы да Алла кулында!

Сталин. Аларның Алласы — мин!

Брежнев. Әйтәм ич, алар сине көтәләр.

Чыңгыз хан. Тагын бер тәкъдим бар. Өстәгеләргә мөрәҗәгать белән чыгарга. Пеләш Малай, синең баш яхшы эшли, яз!

Ленин. Без кәгазьдән укырга өйрәнмәгән. Әйтеп торам, языгыз! Мөхтәрәм тере кардәшләребез! Сезнең хәлләрегездән хәбәрдар без. Сүз дә юк, сезнең өчен кайгырып, ут йотып ятабыз. Никадәр генә авыр булмасын, сез яшәргә тиеш. Монда да сезне бик көтеп тормыйбыз. Беләбез, бик психланып беттегез, сугышасыз, әшәке сүзләр әйтеп сүгенәсез, тартасыз, эчәсез. Җиргә төкерәсез, теләсә кайда бәдрәф ясыйсыз. Бөтен җир сасы, пычрак, шакшы. Сезнең аркада безнең дә монда эшләр начарланды. Соңгы вакытта бер юньле кеше килми башлады — җыен алкаш, проститутка, тюремщик. Суларга һава җитми, бөтен һава юллары әллә нинди банкалар, полиэтилен пакетлар, ямьсез җирен сөртеп ыргыткан кәгазьләр белән тыгылып бетте. Эчә торган сулардан фенол, нефть, денатурат исләре килә. Әгәр тизрәк бу тәртипсезлекләрне туктатмасагыз, монда бик тыгын булачак. Инде хәзер үк «беженец»лар чат саен хәер сорашып утыралар. Күрәсең, өстә аларны күмми-нитми ташлап китәләрдер. (*Пауза.*) Мөхтәрәм тере кардәшләребез! Акылыгызга килегез! Тәртипсезлекләрне дәвам итсәгез, кырылышып монда килә башларсыз. Ә без аңа әзер түгел, средстволар да юк. Шуны истә тотып, әйдәгез үзара килешү төзик. Өстә тәртип урнаштырыйк! (*Пауза.*) Мөхтәрәм тере кардәшләребез! Сезнең күпсанлы сорауларыгыз буенча без моннан үзебезнең Халыклар Атасын — Мыекбайны, сезнеңчә әйтсәк, Сталинны кабат җибәрә алабыз. Хәбәрләшеп торыйк. (*Пауза.*) Бетте.

Чыңгыз хан. Тавышка куям. Кем дә кем Халыклар Атасын — Мыекбайны — өскә тәртип урнаштырырга командировкага җибәрергә ди, кулларын күтәрсеннәр!

Барысы да бу эшне хуплап кулларын күтәрәләр. Чыңгыз хан Сталинга өстәгеләргә язган мөрәҗәгатьне тапшыра.

Гитлер (*Сталинга*). Уңышлар телим!

Сталинны өскә күтәрү өчен Брежнев табутын сәхнә уртасына куялар. Сталин табутка кереп ята. Табут әкрен генә күтәрелә башлый. Бөтенесе Сталинны озатып кул болгыйлар. Нәкъ шул вакыт болар янына ак халатлардан табиблар килеп керә. Ут кабына.

Хөрмәтле тамашачылар, әлегә кадәр без психбольницадагы авыруларның төнге кыланышларын карап утырганбыз икән бит.

Табиблар. Барыгыз, хәзер үк урыннарыгызга ятыгыз әле! Һәр төн шушы галәмәт. Барыгыз, бар.

Авырулар, өс киемнәрен салып, ак пижамаларыннан калалар. Тиз генә парламент өстәлләрен сүтеп, алардан караватъ ясыйлар да йокыга талалар.

I табиб (*бераз тынычлангач*). Карале, Авраам, ә бит шулкадәр оста уйныйлар.

II табиб. Ә син кайсы тишектән карап тордың?

I табиб. Ә син кайдан?

II табиб. Мин көн саен карыйм.

I табиб. Мин дә.

II табиб. Җүләрләр уйный…

I табиб. Ә акыллылар карап тора, шулай бит, Хаем!

II табиб. Гомергә шулай булды.

I табиб. Һәм шулай булыр да!

ПӘРДӘ.

Эчтәлек

Бер килсә килә бит ул
Юлларга кемнәр чыгар...
Минем кыйблам
«Язмагыз әле!»
Нинди прогрессия буенча яшибез
Сәгыйрьләр сагындыра
Кепка бәласе
Көрешү
«Кыскарту»
Җиде кояш
Бакча кыйссасы
Әйбәт саубуллашабыз
Минем дә күңел тыныч
Бәйрәм белән!
Ничә градыс?
Без ничә тиенлек?
«Шалтыраулар дәвам итә»
Бухгалтер
Директор һәм сәнгать җитәкчесе
Патриот
Вафирә
Менә бездә шулай инде
Безнең кебек бул, Салават!
Соң түгел
Чегән монологы
Кемгә кыстыбый?
Төш
Мин ничек телгә кердем?
Хәбил хикмәтләре
Хәйлә кирәк
Коктейль
«Ә теш пастасы?»
Куабыз, имеш
«Сәер» концерт
Не вижүт инде
Минсез уволить иткәннәр
Бу язвылар булмас иде
Концерт
ГБ ЧКБ
Медаль турында
Астан өскә карап
Тутый кош
Яшәргә кирәк!
Кайда син, Хәмзин?
На-а, бахбай!
Гармун белән сөйләшү
Әлү, әлү
Музей
Ур-ра кычкырып
Митрәй
Ай югары, Ай югары...
Сабантуйлар җитәр тиздән!
Гайбәтләр
Бер мәхәббәт тарихы, яки...
Лифт ватылды...
Татар империясе

Литературно-художественное издание

***Хамзин*** *Алмаз Наилевич*

**Если хочешь жить долго...**

Казань. Татарское книжное издательство. 2007
На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

***Хәмзин*** *Алмаз Наил улы*

**Озак яшисегез килсә...**

Мөхәррире *Ф.М.Хафизов*
Рәссамы *Й.М.Вәлиәхмәтов*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *Н.П.Клипова*
Корректорлары *Г.Х.Сундукова, Г.М.Хәбибуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 30.07.2007. Форматы 70X90 1/32.
Офсет кәгазе. «Times» гарнитурасы. Офсет басма.
Шартлы басма табагы 6,44 + форз. 0,15. Шартлы буяу-оттиск 7,32.
Нәшер-хисап табагы 7,62 + форз. 026. Тиражы 2000 д. Заказ С-847.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.

**http://www.tatarstan.ru/books/**
**E-mail: tki@books.kazan.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ. 420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.